ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№06 (389)
ИЮНЬ 2024

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ
ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ГАИЛӘ КЫЙММӘТЛӘРЕ РИТМЫНДА

№06 (389)
ИЮНЬ 2024

16+

Редакция:
Адрес: 420066, Россия,
Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре: Руфия Фазылова, Николай Коновалов,
Евгения Чеснокова, Дмитрий Сивков
Авторлар: Олеся Бондаревская, Илдус Заһидуллин,
Николай Крушинин, Айдар Шәйхин, Луиза Янсуар
Фотографлар: Александр Ефремов, Ната Смирнова,
Лилиана Вәлитова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: 187 нче лицей укучылары директорларлы
Гөлнара Галиева белән. Ната Смирнова фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

ММЧ исеме: ТАТАРСТАН TATARSTAN

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек
буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы
ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә
мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция
җавап бирми.

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә
тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды. Адрес: 420066, Россия, Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: А-1222
Басарга кул куелды: 17.06.2024
Чыгу көне: 21.06.2024

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Коммерция директоры урынбасары:
Алина Майорова,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9033-132-741
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Ирина Захарова, irinamoroz10@mail.ru
Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

РЕДАКЦИЯДӘН

ТАТАРСТАН ГАИЛӘЛӘРЕ

Татарстан буйлап сәяхәт иткәндә бик күп кешеләр белән очрашырга туры килә. Яшьләре, җенесләре, һөнәрләре, холыклары, төскыяфәтләре төрле бу кешеләрдән уңышның, гаилә бәхетенең сере нәрсәдә булуы турында сораштырабыз, үрнәк-гыйбрәт булсын дип, бу хакта басмабызда да язып чыгабыз.

Әлбәттә, без барыбыз да юморист (яки реалист) белән тулысынча килешәбез: иң бәхетле гаиләдә хатын акчаны – тумбочкадан, ир ризыкны суыткычтан алына дип уйлый, ә балалар гомумән үзләрен кәбестә арасыннан тапканнарына ышана.

Ләкин башка серләр дә бар.

Кемдер бу серне буыннан буынга тапшыра, һәм безнең алда туганлык элемтәләре белән генә түгел, ә һөнәри яктан да берләшкән династияләр пәйда була.

Кемдер, гомер буе яшәү мәгънәсен эзләп, дөнья гизә һәм, бары тик өенә кайткач кына, аны гаиләдә таба.

Кемдер гаилә кыйммәтләрен хезмәттәшләренә сеңдерергә сәләтле, шул чакта коллектив эштә дә үзен өйдәге кебек хис итә, хезмәт урынында фикердәшләр җыелган җылы мохит урнаша.

Кемдер аралашучан, хәрәкәтчән туганнары белән яши, ә кемдер, киресенчә, тыныч холыклы, аралашырга яратмый торганнары белән. Ләкин бу туганлыкны юкка чыгармый, чөнки алардан башка гаилә тулы булмас иде.

Нәсел портреты – шәҗәрәне юкка гына агач рәвешендә ясамыйлар. Без агач ботаклары кебек: төрле юнәлешләрдә үссәк тә, тамырларыбыз, бер урынга берегеп,ербөтенне тәшкил итә бит.

Сезнең игътибарлы редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ
Адрес: 420097, Россия,
Татарстан Республикасы, Казан,
Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына ТРның барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин:
Индекс **П2381** – татар телендә ярты елга
Индекс **ПА468** – татар телендә бер елга

Индекс **П2378** – рус телендә ярты елга
Индекс **ПА471** – рус телендә бер елга

2024 елның ярты еллыгына ТР буенча язылу бәясе:
1212 сум 00 тиен китереп бирешле,
1175 сум 40 тиен соратып алганда.
2024 елга ТР буенча язылу бәясе:
2423 сум 92 тиен китереп бирешле,
2350 сум 66 тиен соратып алганда.

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» 103 ЯШЬ
ЖУРНАЛЫНА

ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре
бары ТИК ТАТАРСТАНДА

БРИКСИК – УЕННАР ТАЛИСМАНЫ

Казанда үтә торган БРИКС Уеннарының үз талисманы бар. Бриксик исемле сөйкемле каплан ул. Ни өчен каплан? Чөнки мәчеләр семьялыгына караган әлеге хайван җитезлек, көч, тизлек һәм ныклык символы булып тора. Чын чемпионнарга хас сыйфатлар, килешәсездер. Бриксик, тәүге БРИКС Уеннары кебек үк Азиядә туган, аннан соң турнир белән бергә үскән, ныгыган, диелгән ярышларның рәсми сайтында. Шат күңелле каплан белән беренче мәртәбә апрель аенда «Без бергә. Спорт» форумында танышкан идек. Татарстанның спорт министры Владимир Леонов талисманның пәйда булуын болай аңлатты: «Без Уеннарның символын, талисманын сайладык, аны Бриксик дип атадык. Барсик бар иде (Казан Универсиадасында), хәзер инде Бриксик та булачак». Хәер, җитәкче искә төшергәнә кар барсы иде, шуңа күрә безнең Бриксик, мөгаен, башка – 2014 елгы Сочи Олимпиадасы талисманының туганыдыр. Ул вакытта Уеннарның бер символы Барсик исемле каплан иде бит.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. Россиядә кайда яшәү уңайлырак
Татарстан тормыш сыйфаты рейтингында нинди урын били

6. Шәхси хуҗалыклар өчен акчалар
Шәхси хуҗалык ияләре нинди ярдәмгә өмет итә ала

8. Вакуумлы төргәктәге «икенче икмәк»,
яисә «Кырлай» ничек бәрәңге җәннәте тудыра ала

16. Партнёрлык финанслары инде экзотика түгел
Хәләл банк карталарын кайдан алырга була

18. Мәктәп бизнесы
Аксубай балалары ни рәвешле Сколковога барып җиткән

игелекле эшләр

24. Гамьле әңгәмә
Татарларда хор кайчан пәйда булган

30. Садыйковлар династиясе серләре
Берничә буын табиблар ничек туа

34. Фәнгә багышланган 400 ел
Күненекле галимнәр династиясенә кем нигез салган

36. Акыл, рәсем һәм акварель
Архитекторлар хәзинәсендә ниләр бар

38. Тарихка кереп калу форсаты
Көрәш буенча БРИКС Уеннарында җиңү кемгә эләгер

мәңгелек кыйммәтләр

56. Дәшми калмас өчен...
Ни өчен сугыш турында фильмнар төшерергә кирәк

59. Чегән гипнозы сере
Ничек аңа эләкмәскә

62. Тарихи сәхифә
Чистайның мәшһүр ишаны нинди мирас калдырган

66. Онытылмас исемнәр
Гомәр Галинең фаҗигале язмышы

74. Татар авыллары
Иске Камка ни өчен чишмәләргә бай

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: protatarstan.ru

Фото: ТР Спорт министрлыгы матбугат хезмәтеннән алынды

Акыллы гамәлләр



27.05

Абдулла Арипов, Үзбәкстан Республикасы Премьер-министры, – Ташкентта, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов белән очрашу вакытында:

« – Үзбәкстанның барлык төбәкләрендә Татарстан белән хезмәттәшлек итү теләге бар. Россия төбәкләре белән тәҗрибә уртаклашу кирәклеге турында сорау туганда, безнең барлык өлкәләр дә нәкъ менә Татарстан тәҗрибәсенә таянырга тели.

Игелекле эшләр

16.05

Гурбангулы Бердымөхәммәдов, Төрекмәнстан Халк маслахаты рәисе, – Казанда, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов белән очрашу вакытында:

« – Без төрле юнәлешләр буенча нәтиҗәле хезмәттәшлек итәбез, аерым алганда, нефть-газ тармагында, суднолар төзүдә, химия сәнәгатендә, авиация техникасы һәм йөк автомобильләре белән тәэмин итү өлкәсендә уңышлы эшләвебезне билгеләп үтәргә кирәк. Гуманитар өлкәдә, шул исәптән мәгариф, мәдәният һәм сәнгатьтә хезмәттәшлек тә Төрекмәнстан–Татарстан мөнәсәбәтләренең мөһим юнәлеше булып тора. Форсаттан файдаланып, Россия Федерациясе белән стратегик партнёрлык кысаларында тугандаш Татарстан белән күп тармаклы хезмәттәшлекне ныгытуга юнәлдерелгән актив эшчәнлекне дәвам итү ниятен кабат раслыйбыз.

Мәңгелек кыйммәтләр



21.05

Алексей Иванов, язучы[*], – ТР Милли китапханәсендә китап сөючеләр белән очрашу вакытында:

« – Казан ул – мавритан Петербургы, дияр идем. Шәһәрдә башкала тәкәбберлеге җете Көнчыгыш экспрессивлыгы бергә кушыла. Башкала менталитеты ниндидер аерым кыйбла аша тоемлана. Казан – Россия тарихында да, аның дәүләтчелеге тукымасында да чын-чынлап аерылып торган кала.

[*] «Географ глобус пропил», «Тобол», «Сердце Пармы», «Пищеблок» һ.б. романнар авторы.

Фото: ТР Рәисенең матбугат хезмәте, tatar-inform.ru

игелекле эшләр

акыллы гамәләр /

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Россиядә **кайда** яшәргә уңайлы

Авыл халкының эшлеклелек активлыгын **ничек** арттырырга

«Кырлай» **ничек** бәрәңге җәннәте тудыра ала

Беренче хәләл банк карталарын **кайдан** алырга була

Аксубай укучылары **ничек** Сколковога барып җиткән

ТОРМЫШ СЫЙФАТЫ РЕЙТИНГЫ*



!

Рейтинг нәтиҗәләре МСИ кысаларында эшләү өчен өстенлекләр формалаштыру һәм тарату максатында иң яхшы тәҗрибәләрне ачыклый. Интеграль күрсәткеч буенча иң алдынгы төбәкләр турында мәгълүмат ачыктан-ачык басылып чыга, һәр төбәкнең идарә итү командасына тапшырыла. Рейтинг нәтиҗәләрен анализлау ил буенча тарату өчен иң яхшы тәҗрибәләргә ия төбәкләрне ачыкларга мөмкинлек бирә.

Владимир Путин, РФ Президенты:

«Тормыш сыйфаты рейтингы төбәкләрдәге вазгыятьне бәяләү һәм иң яхшы тәҗрибәләрне уртаклашу мөмкинлеге биреп кенә калмый, ә идарә командаларына кешеләрдән кире элемтә алырга һәм аларны борчыган проблемаларны нәтиҗәлерәк хәл итәргә булыша».

Фото: РФ Президентының рәсми сайты

** Стратегик инициативалар агентлыгы тарафыннан төзелде*

РФнең ТОП-10 ТӨБӘГЕ

Тормыш сыйфаты рейтингы әйләнә-тирә мохитнең һәр кеше ихтыяҗына туры килә торган төп элементларын бәяләү нигезендә төзелә. Бу медицина хезмәте, мәгариф һәм үсеш, торак һәм инфраструктура, кулланучылык һәм ял итү, чисталык һәм экология, инклюзивлык һәм тигез мөмкинлекләр, дәүләт хезмәтләре һәм сервислары, хезмәт итү һәм үз эшеңне ачу мөмкинлеге.



Рейтинг россиялеләрнең тормыш сыйфатын яхшырту буенча төбәк һәм федераль чаралар комплексы – Милли социаль инициативаларны (МСИ) гамәлгә ашыру кысаларында эшли башлады. **МСИ максаты – кешеләрнең социаль хезмәтләрдән, төрле тормыш шартларыннан канәгать калуын яхшырту.**

Рейтинг нигезенә төбәк статистикасы күрсәткечләре, социологик сораштыру нәтиҗәләре һәм геоаналитика инструментлары ярдәмендә җыелган күрсәткечләр салына. **Бу – төбәкләрдә яшәү тирәлегенең сыйфатына комплекслы караш.**

МАРАТ ҖӘББАРОВ: «ШӘХСИ ЯРДӘМЧЕ ХУҖАЛЫКЛАР – АВЫЛНЫҢ НИГЕЗЕ»

Авыл халкының эшлеклелек активлыгын ничек арттырырга, шәхси ярдәмче хуҗалыкларны, авылда хуҗалык итүнең башка формаларын ничек үстерергә? Бу хакта Премьер-министр урынбасары – Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Азат улы Җәббаров белән сөйләштек.

Әхмәт Шакиров

УРТАК КАЗАНДА ШЯХ ӨЛЕШЕ ТУРЫНДА

– Марат Азатович, шәхси ярдәмче хуҗалыкларга ярдәм республика бюджетына күпмегә төшә?

– «Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларга дәүләт ярдәме турында»гы ТР Законы нигезендә ел саен бу максатларга ярты миллиард сумга якын акча бүлеп бирелә. Шәхси ярдәмче хуҗалыклар (ШЯХ) аграр тармакның мөһим өлешен тәшкил итеп кенә калмый, алар асылда бөтен авыл тормышының нигезе булып тора. ШЯХ ачкан кеше бер үк вакытта фермер да, авыл хуҗалыгы предприятиесе, хезмәт күрсәтү производствосы эшчесе дә, социаль хезмәткәр дә.

ШЯХлар китергән файда саллы. 2023 елда Татарстан Республикасының шәхси ярдәмче хуҗалыкларында 98 млрд сумлык авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерелде. Бу – республика аграрийлары җитештергән барлык продукциянең өчтән бере дигән сүз. Шәхси хуҗалыкларда, мәсәлән, барлык бәрәңгенең – 84 проценты, яшелчәләрнең 74 проценты үстерелде, итнең 22 проценты җитештерелде, сөтнең дә дүрттән бер өлеше диярлек алардан алынды.

– Шулай да бүген, әйтик, кайбер авылларда хуҗалыкларның бик сирәгендә генә сыер асрыйлар...

– Ел йомгакларыннан күренгәнчә, шәхси ярдәмче хуҗалыкларда мөгезле эре терлек саны 12,8 меңгә кимегән, шуларның 5,2 меңе – сыерлар. Монда, әлбәттә, демография мәсьәләсе дә роль уйный: сыер асрарлык яшьтәге кешеләр саны авылда, ни кызганыч, кими бара. Ләкин, карасагыз, шәхси хуҗалыкларда ел дәвамында сыерлар саны кимемәгән районнар да бар.

Димәк, кайбер муниципаль берәмлекләрдә тискәре үзгәрешләрне компенсацияли беләләр, башкаларында исә булган мөмкинлекләрне тулысынча куллана алмыйлар. Без, мәсәлән, һәр районда электрон хуҗалык китапларына (ЭХК) теркәлгән мәгълүматны анализладык һәм аларның, дөресен генә әйткәндә, кайчак чынбарлыкны чагылдырмавын ачыкладык: ЭХК мәгълүматларындагы шәхси ярдәмче хуҗалыкларда сыерлар саны ветеринария хезмәте саннарыннан (алар гадәттә бик төгәл) аерыла. Вактөякме? Алексеевск һәм Лениногорск районнарында ЭХКга берничә дистә сыер кертелмәгән. Димәк, аларның хуҗалары дәүләт ярдәме алмаячак. Шуннан соң алар үз хуҗалыкларында сыер асрарга теләрме?

Әйе, шәхси ярдәмче хуҗалык турындагы закон мәгълүмат бирүне иркле итеп куя, әмма бу барысын да үз көенә калдыру өчен сәбәп була алмый. Авыл җирлеге идарәсе ЭХК мәгълүматларын вакытында өйдән-өйгә йөреп чыгу юлы белән яңартып торырга тиеш. Ә район башлыклары ЭХКның алып барылуын контрольдә тотарга бурычлы, һәм бу искә төшкәндә генә башкарыла торган гамәл түгел.

Сүз уңаеннан, 1996 елның 1 гыйнварына республикадагы шәхси ярдәмче хуҗалыкларда 214 мең баш сыер булган, хәзер – 96 меңнән азрак. Тик менә уйланырлык башка мәгълүмат: барлык районнарда да ШЯХтагы сыерлар саны сизелерлек кимеде, ә балтачлылар бу өч дистә ел эчендә элекке санны саклап калу гына түгел, ә аны кырык процентка арттырды да.

Фото: tatar-inform.ru, ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының матбугат хезмәте

СӨТ САТЫП АЛУ БӘЯЛӘРЕ ТУРЫНДА

– Былтыр сатып алу бәяләренең түбәнлеге шәхси ярдәмче хуҗалыкларның тез астына сукты…

– Хәзерге көндә сатып алу бәяләре янә яхшырды, тик кайдадыр инде терлекләрнең баш саны кимергә өлгерде. Башкарма комитетлар азык әзерләү, продукция сатуны оештыру белән җитди шөгыльләнсә, базарда күзәтелгән тискәре хәлләрне дә минималь югалтулар белән узарга мөмкин. Алай гына да түгел, шул ук базар шартларында, мәсәлән, Минзәлә районының Кадрәк авылы җирлегендә сыерлар саны – 31 гә, ә Сарманның Кәүҗияк җирлегендә 25 кә арткан. Сарман районының Карашай-Саклау җирлегендә һәр хуҗалыкка 4 баш сыер туры килә. Авыл җирлеге башлыгы Вероника Хөсниева авылдашлары өчен үзе үк үрнәк булып тора – 22 баш мөгезле эре терлек, шул исәптән 6 сыер асрый. Вероника ханым үзәкләштерелгән азык әзерләү эшен оештырган, кооператив аша, район буенча уртача бәя белән чагыштырганда, ике сумга кыйммәтрәк хактан сөт сатуны җайга салган, халыкка дәүләттән ярдәм алырга булыша. 2015 елдан биредә 8 мини-ферма төзелгән. Мондый җитәкчеләрдән үрнәк алырга, аларның тәҗрибәсен үзләштерергә кирәк. Һәм тагын бер тапкыр кабатлыйм: ЭХК мәгълүматларын вакытында яңартып тору бик мөһим. Ул шәхси ярдәмче хуҗалыкларның эшчәнлеге турында бердәнбер документ, җир хокукларын теркәү өчен нигез булып тора.

ШЯХ ӨЧЕН СУБСИДИЯЛӘР

– Шәхси ярдәмче хуҗалыклар нинди субсидияләргә өмет итә ала?

– Шәхси ярдәмче хуҗалыкларга дәүләт ярдәме быел 546 миллион сум тәшкил итәчәк. Аның 350 миллионы – савым сыерлары санын саклап калу өчен субсидияләр. Бер сыер асраган өчен – 2 мең сум, ике сыерга – 3 мең, дүрт сыерга 4 мең сум акча алырга мөмкин. Ветеринария хезмәте өчен һәр сыерга 300 сум өстәп түләнә.

Мини-фермалар төзү программасына да халыкта ихтыяҗ бар. 2015 елдан әлеге программа кысаларында 2744 шәхси ярдәмче хуҗалык 696 миллион сум максатчан субсидия алды. Быел сайлап алуның беренче этабы нәтиҗәләре буенча 31 хуҗалыкка 13,5 миллион сум акча бирелде. Бу өлкәдә уңышлы бизнес алып баруга мисаллар җитәрлек. Аерым алганда, узган ел ахырында Чистай районыннан Марсель Хәммәдиев баш санын 5 сыерга арттыру шарты белән 22 сыерга исәпләнгән мини-ферма төзүгә субсидия алды. Бүген аның 42 баш эре терлеге, шул исәптән 22 сыеры бар. Көн саен 11 мең сумлык 400 литр сөт сата.

– Ә шәхси ярдәмче хуҗалык иясе яшелчә үстерүгә өстенлек бирсә? Бу очракта ярдәмгә өметләнеп буламы?

– Быелдан Татарстанда (федераль үзәк белән берлектә) шәхси ярдәмче хуҗалыкларда рәсми үзмәшгульләр тарафыннан, ШЯХның үзендә җитештерелгән очракта, ачык туфракта үстереп сатылган яшелчә һәм бәрәңгегә субсидияләр алу мөмкинлеге каралган. Бу максатларга 3,1 миллион сум акча бүлеп бирелә, шуларның 1,4 миллионы – бәрәңгегә, 1,7 миллионы – ачык туфракта үстерелгән яшелчәләргә.

Субсидия ставкалары ачык туфракта үстереп сатылган 1 кг яшелчә өчен – 10 сум, сатылган 1 кг бәрәңге өчен 9 сум тәшкил итә. ШЯХлар арасында дәүләт ярдәме белән аеруча бәрәңге һәм яшелчә эшкәртү кооперативлары кызыксына.

КООПЕРАТИВЛАРНЫҢ ПОТЕНЦИАЛЫ ТУРЫНДА

– Тагын шуңа да басым ясыйсым килә: шәхси хуҗалыкта терлек асрауга төп стимул – сатып алу бәяләре. Республика буенча сөт сатып алу хакы уртача 26,85 сум тәшкил итә: узган ел белән чагыштырганда, 8 сумга күбрәк. Әмма шактый районда сатып алу бәяләре түбән. Бәяләрне үстерүнең бер нәтиҗәле юлы – кооперативлар оештыру. Алар төзелгән урында сатып алу бәяләре продукция күләме, аны эшкәртү, мал азыгы әзерләү эшен җайга салу, шулай ук илкүләм проект аша алынган субсидияләр хисабына ике-өч сумга югарырак. Сатып алу бәяләре, сүз уңаеннан, Балтач, Кукмара, Биектау районнарында иң югарысы – 29 сумнан артык. Бу районнарда үз эшкәртү цехларына ия сөт кооперативлары оештырылган. Бу районнарда тотрыклы яхшы бәяләрне саклануында илкүләм проект субсидияләренең дә өлеше бар. 2023 елда Балтач районы гына да 50 миллион сумлык шундый субсидия алган.

– Кооперативлар өчен нинди субсидияләр каралган?

– Ел саен, илкүләм проект кысаларында, кооперативларга үз әгъзаларыннан авыл хуҗалыгы продукциясен сатып алу чыгымнары каплана. 2023 елда 74 кооператив һәм эшкәртүче 352,4 миллион сум субсидия алды. 13 майдан 31 майга кадәр 2023 елның IV кварталы һәм 2024 елның I кварталы өчен кооперативлар һәм авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртүчеләрнең чыгымнарын субсидияләүнең сайлап алу этабы узды. Субсидияләрнең еллык лимиты 215,6 миллион сум тәшкил итә. Сайлап алуга нәтиҗәләр ясала, акчалар хәзер үк тулысынча үзләштереләчәк. Моннан тыш, яңа эшкә керешкән һәм эшен дәвам итә торган кооперативлар өчен грант ярдәме каралган, июнь аенда конкурслар игълан итәргә планлаштырабыз.

Грантлар, әлбәттә, сүз өчен бирелми: дәүләт ярдәме белән авыл хуҗалыгы кооперациясе аеруча интенсив үсә, кооператив булып эшләүгә җәлеп ителгәннәр саны 17 мең кешегә җитә, акча әйләнеше күләме, бер ярым тапкыр артып, 14,6 миллиард сум тәшкил итә. Быел кооперативларга 2300 яңа әгъза җәлеп итү планлаштырыла.

«УҢЫШНЫҢ СЕРЕ – ЯХШЫ БЕЛГЕЧЛӘРДӘ»

Руфия Фазылова

Тукаебыз кайчандыр абыйсы белән «кара җирне сука белән ертып-ертып йөргән» кырларда бүген шаулап иген, бәрәңге үсеп утыра. Әлеге җирләр «Кырлай» агрофирмасына карый. Татарстанда җитештерелә торган бәрәңгенең 60 процентын биредә үстерәләр. Шуның белән бергә сөтчелек юнәлеше дә көчле. Авыл хуҗалыгы тармагына бер-бер артлы сынаулар килгәндә, «Кырлай» агрофирмасы ничек алдынгылыкны югалтмый?

ЭШЧЕ КӨЧЛӘР ҖИТМИ...

Агрофирманың тарихы 2003 елга барып тоташа. РФнең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, «Сервис-Агро» директоры Габделхәй Кәримов туган ягындагы авыллар таркалмасын дигән максат белән бу эшне башлый. Агрофирма бит ул беренче чиратта кешеләргә эш урыны дигән сүз. Әлбәттә инде, җирләргә хуҗа да булу. Ул чагында ук җитәкче аңлый: заманча алымнар кулланырга кирәк. Һәм шулай итә дә. Тик ни аяныч, Габделхәй Йосыф улы кинәт вафат була. Бәхеткә, башланган эш ярты юлда тукталып калмый: этиләренең эше балаларына күчә. Бүген «Кырлай» агрофирмасы иң заманча технологияләр белән эшләүче хуҗалыкларның берсе. Күрсәткечләр буенча районда беренче өчлектән төшкәннәре юк.

– Гаиләм белән Арчага күченеп кайттык, без хәзер чын авыл кешеләре, – диде «Кырлай» агрофирмасының хәзерге җитәкчесе Марат Кәримов. – Шәһәрдә туып-үскән егет булсам да, кечкенәдән эти-әни белән Арча районына кайтып йөрдек. Эти исән чагында ук агрофирма эшен миңа йөкләде. Дистә ел эчендә күп эшләр башкарылды дип, курыкмыйча әйтергә була: 2017–2020 елларга каралган капиталь төзекләндерү программасы буенча Иске Иябаш, Бирәзә авылларында 200 башка исәпләнгән сыер фермаларын яңарттык. Яңа Кырлайда бәрәңге саклау базасын төзекләндердек. Тагын да зур казанышыбыз – Иске Иябаш авылында 1800 башка исәпләнгән мегаферма төзедек. Анда бүген 1200 баш савым сыеры бар. Тәүлегенә бер сыер

Фотолар «Кырлай» агрофирмасыннан алынды. РЕКЛАМА

30 литрдан артык сөт бирә. Барысы да автоматлашкан.

Агрофирманың бүген 10 062 гектар җире бар. Шуның 70 проценты агрофирманың шәхси җирләре, калганы халыкның пай җирләре. (Арча районының ун авылы алар карамагында.) Хуҗалыкта 140 кеше көч куя, ә сезон вакытында тагын да арта. Читтән егермеләп «КАМАЗ» машинасы гына җәлеп итәләр.

«ЧӨГЕНДЕР, КИШЕРГӘ СОРАУ АРТТЫ»

«Кырлай» агрофирмасы сөтчелек белән бергә игенчелек, яшелчә үстерү белән дә шөгыльләнә. 1350 гектарда бәрәңге, кишер, кызыл чөгендер үсә, калганына исә иген, печән чәчелгән. Быел бәрәңге утырту май азагына кадәр сузылган, узган ел исә май уртасына эш беткән булган.

– Салкыннан куркып бәрәңгене утыртмый тордык, чөнки ул барыбер тишелми. Тәҗрибә шуны күрсәтте, - диде «Кырлай» агрофирмасы агрономы Рәмис Абдрахманов. – Ә менә иген культураларын салкында да чәчтек. Аллага шөкер, көзге бодай, арышлар да әйбәт кенә кышлады, язгылары да тишелде. Вакытында яңгырлар булсын инде, үз чиратында хәлдән килгәннең барысын да эшләдек.

Игенгә бәя түбән булгач, «Кырлай» хуҗалыгы быел рапсны 1000 гектар итеп чәчкән. Көнбагыш, горчица кебек культураларны да арттырганнар. Заманга яраклашырга тырышалар, башка чара юк.

– Дөресен генә әйткәндә, быел чәчүгә куркыбрак кергән идек, - диде Рәмис Абдрахманов. – Әйбәт кенә ерып чыктык. Марат Габделхәевич чәчүлек орлыкны да табыштырды, ягулыкны да кайтартты.

«Кырлай»лылар бәрәңге уңышын җыярга районда беренчеләрдән булып чыга, чөнки бик иртә өлгерә торган сортлар бар икән. Мең гектар җирдән узган ел 300 центнерга якын «икенче икмәк» җыеп алганнар. Заман таләпләренә яраклашып, биредә бәрәңгене, вакуумлап төреп, сатуга да чыгаралар.

– Кызганычка, яңа елдан соң бәрәңгегә сорау кими, ел да шулайрак була, – ди агроном. – Ә менә кишер, чөгендер яңа елга кадәр сатылып бетте. Болай булганы юк иде әле. Бәясе дә яхшы булды: бәрәңге 10 сумнан сатылса, кишернең килосы - 18, чөгендернеке 23 сумга кадәр менде. Әнә шулай итеп ярыйсы гына эшләп алдык. Авыл хуҗалыгы тармагында кайда отасың, кайда оттырасыңны белмисең шул.

– Чөгендер, кишергә караганда бәрәңге үстерү кыйммәткәрәк чыгамы? - дим.

– Әлбәттә, кишер, чөгендерне ике тапкыр эшкәртәсең, бәрәңгегә җидешәр тапкыр техника кирә: чүбен утыйсың, ашлыйсың, агулыйсың...

Агрофирманың 32 мең тонна яшелчә сыя торган базлары бар. Басулар су сибү агрегатлары белән җиһазландырылган. Соңгы елларда яңгырлар бик кинәндерми, су сибәргә туры килә.

– Су сибү агрегатлары төрле, - диде агроном. – Совет чорындагы кебекләре дә, чит илдән кайтарылганнары да бар. Әлбәттә, соңгылары бик көчле: бер урыннан икенче урынга күчереп йөртеп була. Яшелчә үсә торган 1350 гектар җирнең 800–900 гектарына шулай су сиптерә алабыз. Шулай булгач, корылыклы елда да уңышсыз калмаячакбыз, дип уйлыйм.

Агрофирма ел саен диярлек техниканы да яңартырга тырыша. Бер ел эчендә генә дә лизингка яңа комбайн, трактор, кукуруз чәчкеч, салам пресслый торган җайланма алганнар.

– Яңа төр техника эшне бик җиңеләйтә, – диде Марат Габделхәевич. – Мисал өчен, хәзер бер трактор бер көнгә 1000 рулон печән төргәкли, ә элек 100 рулоннан да артмый иде. Урып-җыю белән дә шул ук хәл. Шуның өчен, элеккеге белән чагыштырганда, хәзер язгы чәчүләр, көзге урып-җыюлар бермәбер тизрәк бара.

...«Кырлай» агрофирмасы бүген әнә шулай яшәп ята. Әлбәттә, аларның да үз проблемалары бар. Ләкин алар, җил-давылга карамыйча, гел алга бара: техникасын юнәтәләр, эшчеләрне кызыктырырдай хезмәт хакы тәкъдим итәләр. (Әле яшь гаиләләр өчен торак та каралган.) Алга таба да шул биеклектән төшмичә, киресенчә, авыл хуҗалыгы тармагында яңа үрләр яуларга язсын. Һәрхәлдә, «Кырлай» агрофирмасының моның өчен матди базасы, тәҗрибәсе, ә иң мөһиме – үз эшләренең осталары бар. Җитәкчелек тарафыннан: «Безнең белгечләр яхшы»,– дигән сүзне берничә тапкыр ишетергә туры килде.

AGRATOR DISK

AGRATOR DISK 9000
AGRATOR DISK 12000

ДИСКЛЫ ЧӘЧҮ КОМПЛЕКСЛАРЫ

Реклама

AGROMASTER

www.pk-agromaster.ru

Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы,
Мөслим авылы, Тукай ур., 33 а, e-mail: agromaster@mail.ru
тел: 8(85556)2-39-08, 2-43-59, сот.: 8-939-396-83-44

Авыл хуҗалыгы техникасы

Сервис һәм гарантия хезмәте күрсәтү

Запас частьләр

AGRO CLASS

Рәсми дилер

LEMKEN

КАЗАНЬСЕЛЬМАШ

J:C JIANGHE

Dondi

FJDynamics

Татарстан Республикасы,
Казан ш., Бохара ур., 4а

www.agroclass.ru
тел.: +7 (843) 255-50-32
e-mail: office@agroclass.ru

Реклама

STRONG OIL
PROFESSIONAL LINE
БИК КУӘТЛЕ ДВИГАТЕЛЬЛӘР
ӨЧЕН ИДЕАЛЬ ТУРЫ КИЛҮ
ДВИГАТЕЛЬНЕ ЮГАРЫ ДӘРӘҖӘДӘ САКЛАУ
ПРОФЕССИОНАЛЛАР ТАРАФЫННАН САЙЛАНУ
STRONG OIL
PROFESSIONAL LINE
STRONG OIL PROFESSIONAL LINE
AGRIMOT SDX
15W-40
«СТРОНГ ТЕХНИК» ҖЧҖ
8 (910) 610 60 97
8 (499) 653 62 99
www.strong-oil.ru
info@strongtehnik.ru
РЕКЛАМА

КУӘТЛЕ ТЕХНИКА ӨЧЕН ПРОФЕССИОНАЛЬ МАЙ

ТҮБӘНДӘГЕ КҮРГӘЗМӘЛӘРДӘ СТЕНДЛАРЫБЫЗНЫ КАРАГЫЗ:

Дон кыры көннәре

13.06 – 14.06. 24 ел.

Безне R31 стендында эзләгез

Ростов-на-Дону ш.,
«Донской» АФУ» ФДБФУ

Тамбов кыры көннәре

28.06 – 29.06.24 ел.

Безне А 4.6 стендында эзләгез

Тамбов ш.,
Лысые Горы авылы

Бөтенроссия Кыр көннәре

20.06 - 22.06.24 ел.

Безне 02.91 стендында эзләгез

Минеральные Воды ш.,
«МинводыЭКСПО» ХКҮ

Агроволга

03.07 – 05.07.24 ел.

Безне В409 стендында

Казан ш.,
«Kazan Expo» Халыкара күргәзмәләр үзәге

XV ХАЛЫКАРА ИКЪТИСАДЫЙ ФОРУМ:

14–19 май
«Казан Экспо» ХКҮ

ФОРУМ ВАКЫТЫНДА

120 дән артык килешүгә кул куелды

КАЗАН ФОРУМЫНА КИЛДЕЛӘР:

20 000 нән артык катнашучы

87 илдән

РФнең **87** төбәгеннән

«КАЗАН ЭКСПО» ҮЗӘГЕНДӘ:

125 тематик секция, лекцияләр, мастер-класслар һәм презентацияләр үтте

ФОРУМГА

40 тан артык дипломатия миссиясе

ВӘКИЛЛӘРЕ КИЛДЕ

МАРАТ ХӨСНУЛЛИН, РФ ПРЕМЬЕР-МИНИСТРЫ УРЫНБАСАРЫ, 2024 ЕЛГЫ ФОРУМНЫ ОЕШТЫРУ КОМИТЕТЫ БАШЛЫГЫ:
«Быел форум тәгаен уңышлы узды һәм ул төрле төбәкләрдән, илләрдән килгән төрле милләт, дин, юнәлеш вәкилләрен, үзара хөрмәт һәм ышанычка нигезләнеп, бер-берсе белән файдалы хезмәттәшлеккә һәм бергәләп үсү принципларына таянып берләштерә торган чын стратегик мәйданчыкка әверелде».

Фото: tatar-inform.ru

«РОССИЯ – ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ: KAZANFORUM-2024» ЦИФРЛАР ҺӘМ ФАКТЛАР

KAZAN HALAL MARKET

Форум мәйданчыгында узды:

КҮЧЕМСЕЗ МИЛЕК КҮРГӘЗМӘСЕ ҺӘМ ХӘЛӘЛ ПРОДУКЦИЯ ЯРМИНКӘСЕ

Форум кысаларында хәләл продукция экспортлау белән шөгыльләнә торган компанияләр белән хезмәттәшлек турында килешүләр имзаланды.

Фарсы култыгы, Көньяк-Көнчыгыш Азия илләренә, Иран һәм Казахстанга продукция чыгаруны арттыру планлаштырылды.

25 млн сум

ярминкә вакытында сатылган продукциянең гомуми күләме

Агросәнәгать паркында узган хәләл ярминкәдә

400 дән артык экспонент тәкъдим ителде

Россиянең **10** төбәгеннән **36** компания

7 илдән **10** дизайнер үз коллекцияләрен **ӘДӘПЛЕ МОДА ФЕСТИВАЛЕНДӘ** тәкъдим итте.

ХАЛЫКАРА СӘҮДӘ-СӘНӘГАТЬ ПАЛАТАЛАРЫ ФОРУМЫ

ФОРУМДА КАТНАШТЫЛАР:

18 чит ил палатасы

13 чит ил эшлекле ассоциациясе

40 Россия төбәге

ПАРТНЁРЛЫК ФИНАНСЛАРЫ: ХӘЕРЛЕ СӘГАТЬТӘ

«АВТОГРАДБАНК» КАЗАНДА ИСЛАМ ОФИСЫ АЧКАН ҺӘМ БЕРЕНЧЕ ХӘЛӘЛ КАРТАЛАР БИРГӘН

Евгения Чеснокова

Россиядә ислам банкингын кертү май уртасында Казанда узган «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» форумында үзәк темалардан берсе булды. Биредә 80 нән артык ил вәкиле җыелды. Партнёрлык банкингында эшләүнең төрле аспектларына багышланган доклад белән форумда «Автоградбанк» АҖ президенты Павел Сигал чыгыш ясады.

Исегезгә төшерәбез: Россиядә ислам банкингы буенча экспериментны башлап җибәргән федераль законга ярашлы рәвештә, Татарстан (Башкортстан, Дагыстан һәм Чечня белән бергә) илдә әлеге сынау үткәрелә торган дүрт төбәкнең берсе итеп сайланды. Үз чиратында «Автоградбанк» исә партнёрлык финанслары буенча экспериментта катнашучыларны билгеләүче Россия Банкы реестрына кертелгән җиденче кредит-финанс оешмасы (һәм өченче банк) булып тора.

KazanForumнан алган тәэсирләре һәм ислам банкингы буенча «Автоградбанк»та инде эшләнгән эшләр турында без Павел Сигал белән сөйләштек.

КЫЗЫКСЫНУ ИЛ ЭЧЕНДӘ ГЕНӘ ТҮГЕЛ

– Павел Абрамович, партнёрлык финанслары мәсьәләләре буенча форумда сез мөгаен коллегаларыгыз белән аралашкансыздыр...

– Әйе, форумда безнең үзебезнең стенд бар иде, күп кеше, килеп, безнең әлеге юнәлештә ниләр эшләвебез белән кызыксынды. Шул исәптән әлегә экспериментта катнашмаган мөселман төбәкләре (Кабарда-Балкар, Карачай-Чиркәс) вә-

килләре дә шактый иде... Әмма без анда әлегә эшли алмыйбыз, закон рөхсәт итми. Ә менә сынауда катнашучы Башкортстан, Дагыстан һәм Чечня инде актив кызыксына: без кайчан аларга киләбез, кайчан эшли башлаячакбыз? Минем белүемчә, аларда шулай ук партнёрлык финанслары буенча эш башлаган башка банкларның (Саклык банкы, «Тинькофф» һәм «Ак Барс Банк» – Ред.) ислам офислары юк.

Аралашу форумнан соң да дәвам итте: күптән түгел киңәшчеләремнән берсе Башкортстан премьер-министры чакыруы буенча Уфага барды, эш барышы белән таныштырды.

– Һәм инде сез әлеге төбәкләрдә ислам офислары ачарга әзерме?

– Нигездә әзер, әмма без әле эшнең башында гына. Май башында Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы безгә ислам исәп-хисап счетларын ачарга, хәләл карталар бирергә рөхсәт итте. Без Казанда ислам офисы ачтык. Банкка шәригать контролеры беркетелгән – Рөстәм хәзрәт Нургалиев, Голәмалар шурасы гыйльми сәркатибе һәм Казан ислам институты проректоры, ислам финанслары тармагында бик абруйлы белгеч. Ул безгә барлык бу продуктларны кертүдә ярдәм итәчәк. Шул рәвешле, эш әкренләп бара.

Тагын шунысын да әйтү зарур: Россия эчендә ислам банкингын үстерү турында сөйләгәндә, икенче мөһим юнәлеш – илгә ислам инвестицияләрен җәлеп итү хакында да онытырга ярамый. Мөселман банклары һәм фондларының Россиядә беренче тапкыр шәригать кануннары буенча эшләү мөмкинлеге пәйда була. Өстәвенә, экспериментта катнашучы барлык банклар арасыннан «Автоградбанк» кына санкцияләрсез эшли һәм бары тик безнең генә ислам инвестицияләрен кертү мөмкинлегебез бар. Программаны ил эчендә үстерү кебек үк, Россия өчен монысы да бик мөһим, чөнки көнчыгыш илләренең күбесендә нефть табыла һәм алар миллиардларча доллар акчага ия. Һәм хәзер, Россия шәрыкка таба юнәлгәч, бирегә ислам инвестицияләрен җәлеп итү мөмкинлеген кулдан һич ычкындырырга ярамый.

– Нинди илләр белән эшләүнең конкрет планы бармы инде?

– Форумдагы стендыбыз янына төрле мөселман илләре вәкилләре дә килде. Алар, сүз дә юк, биредә яңа мөмкинлекләр ачылуын хәтерләренә теркәп куйды. Әмма инвестицияләр – бик четерекле мәсьәлә бит ул. Шулай да әйтә алам: мин тиздән Мисыр банклары вәкилләре белән очрашачакмын, Индонезия банкларының да кызыксынуы бар. Эш башланды, әмма тәҗрибә күрсәткәнчә, әлеге процессның тизлеген алдан берничек тә фаразлап булмый.

БЕЛГЕЧЛӘРНЕ ӨЙРӘТҮ ЗАРУР

– Форумда партнёрлык банкингына бәйле проблемалардан берсе дип әзерлекле белгечләрнең булмавы аталды, аерым алганда, бу хакта Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та әйтте.

– Алар бөтенләй юк бит.

– Бу җәһәттән нәрсәләр эшләнә соң?

– Хәзер безнең белгечләр укый. Эш тәртибендә, үзләренең эш урыннарында, Голәмалар шурасын җәлеп итеп. Ихтыяҗ туса, аларны ислам университетына укырга җибәрербез. Чыннан да, белгечләр әзерләү зарур һәм тиз арада.

– Җитәкче буларак сез дә өстәмә белем аласызмы?

– Банк җитәкчеләре теорияне өйрәнү белән махсус шөгыльләнмәде, әмма без, билгеле инде, практик тәҗрибәне тәфсилләп өйрәнәбез.

– Банк белгеченә әлеге юнәлешкә күнегү катлаулымы?

– Юктыр, дип уйлыйм. Банк өчен бу стандарт продуктлар бит, бары тик билгеле бер кагыйдәләрне генә үтәү сорала. Әлбәттә, ислам кредитлары программасын тормышка ашыра башлагач, төрле нечкәлекләр ачыкланачак. Мәсәлән, ислам банкингында пени, штрафлар, судлар юк, бәхәсләр мәхкәмәсез генә хәл ителә. Практикада бу ничек булыр – вакыт күрсәтер.

КАРТА КЕМГӘ БИРЕЛӘ?

– Ә ислам кредитларын кайчан бирә башлаячаксыз?

– Әйткәнемчә, Казанда «Автоградбанк»ның ислам офисы эшли инде, без счетлар ача һәм хәләл карталар бирә башладык. Бүгенге көнгә инде 78 исәп-хисап счеты ачылган, 22 карта бирелгән һәм 56 сы тиздән әзер булачак. Хәзер автокредитлар, ипотека, кече һәм урта бизнеска кредитлар бирүне Голәмалар шурасы белән килештерү эше бара. Ике хәләл счет ачарга гариза бар – Казандагы Апанай мәчетеннән һәм «Иман» нәшриятыннан.

– Без банкның беренче катындагы ислам офисын карап чыктык. Бик матур, хәтта намаз бүлмәсе дә бар...

– Әйе, бусы мондый офис ачуның мәҗбүри шарты булып тора...

– Шулай да халыкта шәригать кануннары буенча эшли торган банк продуктларына ихтыяҗ бармы соң?

ИСЛАМ ФИНАНС МОДЕЛЕ МӨСЕЛМАННАРНЫҢ ИКЪТИСАДЫЙ ЭШЧӘНЛЕГЕНДӘ КАЙБЕР ТЫЮЛАР БУЛУНЫ ТАЛӘП ИТӘ. БУРЫЧКА БИРЕЛГӘН АКЧА ӨЧЕН ПРОЦЕНТЛАР АЛУ ТЫЕЛА – БУ РИБА САНАЛА. ИСЛАМ ФИНАНСЛАРЫН АЛКОГОЛЬ, ТӘМӘКЕ, ДУҢГЫЗ ИТЕ ҖИТЕШТЕРҮ ҺӘМ САТУДА КУЛЛАНЫРГА, УЕН БИЗНЕСЫНДА ФАЙДАЛАНЫРГА ЯРАМЫЙ. НИНДИ ЮЛ БЕЛӘН ТАБЫЛУЫ БИЛГЕСЕЗ БУЛГАН АКЧАДАН ФАЙДАЛАНЫП ЯКИ БИК ХӘВЕФЛЕ САНАЛГАН ТЕЛӘСӘ НИНДИ КЕРЕМ АЛУ ЫСУЛЫ ДА ТЫЕЛА.

– Хәзер безгә хәләл карта алырга теләүчеләрдән бик күп гариза килә. Сүз уңаеннан, аны алу өчен мөэмин-мөселман булу төп шарт түгел. Мәсәлән, картаны сез дә ала һәм аның белән түли аласыз, әмма процентлар өстәлмәячәк.

– Тагын бер тапкыр халыкта ихтыяҗ булу-булмау хакында сорыйсы килә – сез биредә зур перспективалар күрәсезме?

– Менә үзегез уйлап карагыз: хәзергә кадәр мөселманнар, банкка процентлар белән акча салырга ярамаганга күрә, байлыгын өендә саклый иде... Әмма реалист булырга кирәк: мөгаен, кешеләр моңарчы да, шәригать кануннарыннан тайпылмыйча, бер-берсенә бурычка акча биреп торгандыр, тик моны рәсми түгел, бәлки аерым бер тәртиптә генә эшләп булган. Хәзер исә аларның банклар белән эшләү өчен легаль мөмкинлеге пәйда була. Һәрхәлдә, без киңәшләшә торган Голәмалар шурасы вәкилләре моңа зур өметләр баглый. Алар әйтүенчә, ислам банкингы программаларына керергә теләүчеләр саны бик күп булачак.

Фотолар: Александр Ефремов, «Автоградбанк» АҖнән алынды. РЕКЛАМА

АКСУБАЙ БАЛАЛАРЫН СКОЛКОВО БЕЛӘН НӘРСӘ БӘЙЛИ?

Дмитрий Сивков

Татарстанда белем утравы бар… Балаларга тиңдәшсез, җитмәсә әле бушлай белем бирә торган «Мәктәп бизнес-старты» проекты ул чыннан да утрау кебек. Бу турыда проект җитәкчесе Елена Тихонова белән сөйләштек.

ТОРМЫШТА ҮЗ ЮЛЫҢНЫ ТАБУ МӨҺИМ

– Елена Петровна, проектның икенче сезоны төгәлләнде. Аның нәтиҗәләре бармы?

– Уку елы дәвамында республиканың 28 районында урта яшьтәге 11 мең мәктәп баласы эшкуарлык нигезләрен махсус программа буенча өйрәнде: эшкуар портретын төзеделәр, эшкуарлык хезмәтенең теория һәм практикасына төшенделәр, үз бизнесларын булдырдылар, продукцияләрен мәктәп ярминкәсендә саттылар, үз проектларын тәкъдим иттеләр, бизнес-кейслар чиштеләр һ.б.

Татарстанның 9 районындагы 12 бизнес-компания вәкиле булган иң нык һәм максатчан 120 бала финалга килеп җитте, анда чын эшкуарлар 3 җиңүче команданы ачыклады. Алар Мәскәүгә барачак, «Сколково» технопаркында да булачак.

– Бу балалар кайсы тармакларны үз иткән?

– Өч номинация иде: «Ватаныбызда җитештерелгән» – Чистай районыннан 2 нче лицей (үзеңә һәм якыннарыңа бүләккә чәй әзерләү); «Ел уңышы» – Аксубайның 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе (бәйләнгән эшләнмәләр җитештерү); «Киләчәк бизнесы» – Тәтешнең 1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе (полимер балчык белән бизәлгән кружкалар, тәлинкә, кечкенә магнитлар, чыршы уенчыклары ясау).

ИЛСУР ҺАДИУЛЛИН,
Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры:

– «Мәктәп бизнес-старты» кебек проектлар балаларга өстәмә белем һәм күнекмәләр бирергә тиеш, чөнки мәктәптә алган белем – классик белем ул, һәркемгә зарур. Бүген мобиль, креатив фикерле булу, тормышта үз урыныңны табу өчен төгәл һәм тиз гамәлләр кылу бик мөһим. Мондый проектлар балада чыннан да булган талантларны ачарга ярдәм итә. Мәктәптә укыган вакыт – иң файдалы чак, балалар күп нәрсә эшли белә, ә инде алар үз продукцияләрен сату мөмкинлеген тапса, киләчәктә моны үз һөнәренә әйләндерсә, бигрәк тә яхшы! Шунысы сөендерә: әлеге проект кысаларында балаларны яраткан эшләре белән шөгыльләнергә генә түгел, моңардан керем алырга да өйрәтергә сәләтле кешеләр бар.

Автор фотосы. РЕКЛАМА

ЭШКУАРЛЫК ҺӨНӘРЕ

– Проектта катнашучылар саны шаккатарлык: быел – 11 мең, былтыр – 12 мең. Балаларга үрнәк булырлык бизнес атлантлары кемнәр соң алар?

– Минемчә, монда һәркемнең үз факторы. Хәтта гаиләдә эшкуарлар булмаса да, тумыштан ук шуңа маһир балалар бар. Бәлки бу генетика белән бәйледер – кемнеңдер бабасы малтабар булгандыр, әмма аның турында мәгълүмат гаилә тарихында сакланмагандыр гына. Кайбер балалар аналитик акылга ия, шуңа бу аларга кызык тоела. Кемнедер исә уңышлы кешеләрнең казанышлары җәлеп итә, мәсәлән, Павел Дуров яки Илон Маскның биографияләре белән танышканнан соң шундый теләк туа.

– Ә «компания өчен генә» килүчеләр ничә процент тәшкил итә?

– Билгеле, башлап җибәргәндә, без мәктәпләрдәге административ ресурсны эшкә җигәбез. Аннары исә проектта чынлап торып кызыксынучылар һәм үз бизнесларының уңышлы буласына ышанучылар гына кала. «Эшкуар һөнәре турында белүчеләр бармы?» – дигән сорауга йөз кешенең күп дигәндә унысы гына уңай җавап бирә. Кызганыч ки, күп гаиләдә шундый стереотип яши: янәсе, эшкуарларга затлы машиналар һәм зиннәтле зур йортлар күктән ява. Безнең проектта балалар әлеге һөнәр белән таныша. Алар әкренләп шуны аңлый: беренче чиратта бу – үзенең ялкаулыгын, кимчелекләрен, наданлыгын җиңәргә сәләтле кешеләр. Беренче тапкыр барып чыкмаса, алар туктап калмый, өметсезлеккә бирелми, эшен яңадан башлый.

ЛИНАРА БОРҺАНОВА,
«Минем бизнес» эшкуарлыкка ярдәм үзәге җитәкчесе, ТР Эшкуарлыкка ярдәм итү фонды генераль директорының беренче урынбасары:

– «Минем бизнес» үзәге «Мәктәп бизнес-старты» проектын гамәлгә ашыруда аның беренче көннәреннән үк катнаша. Бу вакыт эчендә Казаннан гына түгел, ерак торак пунктлардан да килгән 23100 мәктәп баласы күп баскычлы укыту курсын үтте. Әлеге проектка бик мөһим миссия йөкләнгән. Бу – балаларда мәктәп елларыннан ук эшкуарлык компетенцияләрен тәрбияләү. Проектта катнашучыларның шактыеның үз идеяләре пәйда була, алар киләчәктә чын эшкуарлыкка әйләнергә мөмкин. Әлбәттә инде, үз эшен башлаучылар сыйфатында аларны «Минем бизнес» үзәге мәйданчыгында күрүебезгә без бик шат булачакбыз һәм проектларына бик теләп ярдәм итәчәкбез.

ДӘҮЛӘТТӘН ЗУР БҮЛӘК

– Спорттагы кебек үк, эшкуарлыкка да талант булу кирәкмимени? Белем яки күнекмәләр генә җитәрлек булмаска мөмкин бит.

– Дөрес. Җир шарында яшәүчеләрнең нибары 5–7 процентының гына бизнес өлкәсендә таланты бар, дип санала. Безнең үзебезнең статистика да шуны күрсәтә. Әлбәттә инде, «Мәктәп бизнес-старты» курсында һәр катнашучының сәләте һәм кызыксынуы төрле булу исәпкә алына. Әмма эшкуарлык күнекмәләре шуңа кызыклы да инде, чөнки алар кешене тормышның теләсә кайсы өлкәсендә үз хосусый компаниясен ачуга әзерли – медицинада яки фәндәме ул, төзелештә яки агросәнәгать комплексындамы, хезмәт күрсәтү сферасында яки кием-салым җитештерүдәме, җәмәгать туклануы тармагындамы яки мәгарифтәме... Вариантлар искиткеч күп – проектта катнашучылар моны күрә һәм аңлый, үз гомер траекторияләрен планлаштыра башлый.

Республика Рәисе Рөстәм Нургали улы Миңнеханов безгә яшь эшкуарлар булдыру түгел, бәлки балаларда эшкуарлык күнекмәләре формалаштыру бурычын куйды. Менә без формалаштырабыз да инде, киләчәктә исә хосусый клиника һәм юридик компанияләр, яңа җитештерүләр, кибетләр һәм сервис үзәкләре ачыла башлар, дип өметләнәбез.

– Сезнең бу эшне бик яхшы белүегез күренеп тора...

– Чөнки моның никадәр катлаулы юл булуын шәхси тәҗрибәмнән чыгып беләм. Үзем 40 яшемдә эшкуар булдым. Юрист булып эшләдем, карьера баскычыннан югарыга күтәрелдем, әмма берничек тә тормышка ашырмый калмаслык хыялым пәйда булгач, «эшкуар» һөнәренә өйрәнергә – китаплар укырга, бизнес-план төзергә, инвесторлар эзләргә, команда тупларга туры килде... Берничә тапкыр тырмага басып маңгаемны күгәрткәч кенә, нәрсәгәдер ирешә алдым. «Мәктәп бизнес-старты» балаларга вакытны янга калдырырга һәм нервларын саклап калырга мөмкинлек бирәчәк – аларны чын эшмәкәрләр укыта.

– Һәм әле бу бушлай да.

– Әйе, бу күп гаиләләргә зур ярдәм. Хәзер бер бизнес-тренинг уртача 60 мең сум торырга мөмкин. Безнең проект балаларны бөтен уку елы дәвамында җәлеп итә – катнашучылар өчен ул түләүсез. Ә алар бит төрле керемле гаиләләрдән, әмма һәркемгә тигез мөмкинлекләр бирелә. Күп ата-ананың, бигрәк тә авыл җирлегендә, баласын «ниндидер эшкуарлыкка» өйрәтергә башына да килмәс иде әле. Ә монда – рәхим итсеннәр. Әйе, бу дәүләттән бик яхшы бүләк.

НАТАЛЬЯ КОНДРАТОВА,
Татарстан Республикасы икътисад министрының беренче урынбасары:

– «Мәктәп бизнес-старты» проекты «Кече һәм урта эшкуарлык» илкүләм проекты кысаларында гамәлгә ашырыла, ул республика шәһәр һәм районнарында яшәүче мәктәп балаларының эшкуарлык күнекмәләрен һәм компетенцияләрен үстерүгә юнәлтелгән. Эшлекле уеннар аша белем бирү методикасы мәктәп балаларында кызыксыну уятырга мөмкинлек бирә һәм аларның эшкуарлык компетенцияләрен үстерүгә булыша. Мәсәлән, мәктәп балалары уен форматында эшлекле фикерләү, тәкъдим итү, дәлилләү, планлаштыру күнекмәләрен ала, боларның барысы исә аларга командаларда үз проектларын үстерү, тышкы аудитория каршында яклау һәм киләчәктә куллану мөмкинлеген бирә.

ҺӨНӘРНЕ ЯШЬТӘН САЙЛА

Дмитрий Сивков

«РАМПА» проекты өченче ел рәттән балаларны тормышның олыларча һөнәри ягы белән танышырга һәм киләчәктә үзләренә кирәкле дә, кызыклы да сукмак сайларга ярдәм итә.

ЯШЬ ТАТАРСТАНЛЫЛАРГА БӘХЕТ ЕЛМАЙГАН

Кайсы өлкәнең үзе өчен кызыклырак булуын бала ничек аңлый ала? Икмәк заводы, химия комбинаты яки тегү производствосының ничек эшләгәнен кайдан карый ала? Хәл итү юлы бар – һөнәрләр белән таныштыра торган экскурсияләр. «РАМПА» Балаларны һәм яшүсмерләрне үстерү үзәге» автономияле коммерциячел булмаган оешмасы үз алдына нәкъ шушы бурычны куйган. Эшли генә башлаган әлеге оешма балаларның, әти-әниләрнең һәм актив мәктәп укытучыларының күңелен тиз яулап ала.

«РАМПА» мәктәп укучылары өчен Татарстанның әйдәп баручы предприятиеләренә экскурсияләр оештыра. Максат – балаларны җитештерүләр һәм хәзерге вакытта ихтыяҗ зур булган һөнәрләр белән таныштыру. Узган ел оештырылган 61 экскурсиядә 1520 укучы һәм студент катнашкан. Алар үзләре өчен кызыклы, ә кемнәрдер өр-яңа дөнья ачкан. Быелның биш аенда 2000 мәктәп укучысы 57 экскурсиядә булырга өлгергән.

Мондый экскурсияләргә ихтыяҗ зур, ләкин бу алай җиңел эш түгел. Балалар белән эшләү нормаларын да исәпкә алырга, компанияләрнең гамәли эшчәнлегенә зыян салмый гына катнашып китәргә дә кирәк. Алга таба проектның географиясен киңәйтү – Татарстан Республикасының муниципаль район территорияләрен кертү дә, төрле тармакларда эшли торган предприятиеләр белән хезмәттәшлек итү дә күздә тотыла. Шулай ук комплекс-

ФИКЕР АЛЫШУ

Дарья Санникова, Казан шәһәренең Туризмны үстерү комитеты директоры:

– Балалар өчен сәнәгать туризмы – дәүләт, туризм өлкәсе һәм сәнәгать предприятиеләренең үзенчәлекле синергиясе. Аның максаты бер – Казанга гади туристларны гына түгел, булачак студентларны да, ә бәлки, киләчәктә шушында яшәп калучыларны да җәлеп итү. Даими системалы эшләү әлеге проектны кунакчыллык өлкәсендә генә түгел, ә уку йортлары, шулай ук Татарстан Республикасы сәнәгатенең төрле тармакларында эшләүче предприятиеләр өчен дә нәтиҗәле итәргә булыша.

Елена Шилова,«РАМПА» ЖЧЖ җитәкчесе:

– Проектыбызның максаты – балаларга үз тормыш юлыңны дөрес сайлауның никадәр мөһим булуы турында сөйләү. Без укучыларга чын җитештерүне күрсәтәбез, завод белгечләре белән очрашулар уздырабыз. Балалар сәнәгать оешмаларының нинди булуын үз күзләре белән күрә, хезмәткәрләргә сораулар бирә. Шул рәвешле алар өчен офыкларны киңәйтәбез, төрле профессияләр турында шул һөнәр ияләренең үзләреннән белешергә мөмкинлек бирәбез. Безнең проект мәктәп укучыларына үз юлларын табарга һәм уңышка ирешергә ярдәм итү өчен оештырылды.

Автор фотолары. РЕКЛАМА

лы маршрутлар булдырырга да ниятлиләр. Мондый маршрутлар Россиянең башка төбәкләрендә яшәүче меңләгән булачак абитуриентка Татарстандагы югары уку йортлары һәм компанияләре белән танышырга, күпләргә яхшы югары белем алырга, Казанда, республикабызда лаеклы эшкә урнашырга перспективалы мөмкинлекләр тудырачак.

ПРОЕКТНЫ ОЕШТЫРУЧЫЛАРНЫҢ МАКСАТЫ

Экскурсияләрне оештыруның төп максаты, әлбәттә, үсеп килүче яшь буынның кызыксынуын басу һәм аң-белемен арттыру түгел. Хәер, монысын да сызып ташларга ярамый. «РАМПА» дүрт төрле юнәлештә эшли. Образлы итеп әйтсәк, болар оешманы тотып торучы дүрт багана.

Беренчесе – үзебездә эшли торган җитештерүчеләргә ярдәм итү, гомуми урта белем бирү учагы белән эшкә урнашырга булыша торган үзәкләрнең үзара хезмәттәшлеген ныгыту. Предприятие белән танышу экскурсиясе Татарстан компанияләренең абруен күтәрә, аларның кыйммәтен күрсәтә, ышанычлы эш бирүче брендын булдыра.

Икенчесе – яшьләрнең игътибарын милли брендларга юнәлтү. Бу брендларны чит илләрдә дә таныйлар. Татарстан предприятиеләре җитештергән продукциянең сыйфаты чит илнекеләр белән ярышырлык дәрәҗәдә. Бу хакта әйтергә һәм күрсәтергә кирәк. Мондый экскурсияләрне уздыру төбәкнең мөмкинлекләрен ача, Татарстан Республикасының милли брендын таныта.

Өченче бурыч – техник белгечлекләрне популярлаштыру. Эшче һөнәрләр белән уңышка ирешеп һәм перспективалы киләчәккә өметләнеп булмый, дигән стереотип яши. Югыйсә кулы эш белгән һәм башы эшләгән белгечләр алтынга тиң, алар теләсә кайсы предприятиедә югары бәяләнә. Экскурсияләрдә «РАМПА» шуны күрсәтергә омтыла да. Карьера ул әле ак күлмәктән йөрү генә түгел, беренче чиратта ул – җәмгыятькә файда китерү.

Дүртенче максат – һөнәр сайларга булышу. Предприятиеләрдә булып, балалар һәм яшүсмерләр төрле һөнәрләрнең нечкәлекләрен белә, аларның фикерләве үсә, үзенең киләчәген сайлый ала.

«РАМПА» ПРОЕКТЫНДА ҖИТЕШТЕРҮЧЕ КОМПАНИЯЛӘРНЕҢ РОЛЕ ТУРЫНДА

Җирле предприятиеләр кызыксынмаса һәм күтәреп алмаса, бу проектны оештыру мөмкин булмас иде. Ике як өчен дә файдалы хезмәттәшлекнең асылы ачык: предприятиеләргә квалификацияле һәм эшләргә теләге булган яшь кадрлар кирәк.

Сәнәгать өлкәсендә «РАМПА»ның фикердәшләре: «Туполев» ГАҖ филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводы, «Казан вертолёт заводы» АҖ, «А.М. Горький исемендәге Яшел Үзән заводы» АҖ, «КМТБ» АҖ, «Казан Оргсинтез» ГАҖ, «Казан дәүләт казна күкерт заводы» федераль казна предприятиесе, яхта һәм катерлар төзүче Velvette Marine предприятиесе.

Бу предприятиеләр мәктәп укучыларына нәрсәсе белән кызыклы? Әйтергә кирәк, бөтен яктан да: вертолет заводында балалар предприятиенең бай тарихы белән таныша, вертолёт төзелешенең тулы циклын үз күзләре белән күрә, төрле модификацияләрнең үзенчәлеген белә. Яшел Үзәндәге суднолар төзү заводында төрле максатларда кулланыла торган диңгез һәм елга корабларының ничек төзелгәнен күрә, аларны швартовка сынавына әзерләүләре белән таныша. «Казан Оргсинтез»да нефть-химия процесслары турында сөйлиләр, балалар мобиль экология лабораториясендә һаваның сыйфатын тикшерү өчен үрнәкләр алуда катнаша.

«РАМПА»ның партнерлары арасында шулай ук Б. Рәмиев исемендәге IT-парк, Данилов мануфактурасы, 3 нче Казан икмәк заводы, Иннополис шәһәре, «Казан» Халыкара аэропорты, Г.Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры, ТР Милли китапханәсе, Республика яшүсмерләр китапханәсе, Казан дәүләт яшь тамашачы театры, «Ак Барс» Банк та бар.

Балалар монда нәрсә белән шөгыльләнәме? Әйтик, Данилов мануфактурасына экскурсия вакытында алар җептән оекбашлар бәйләгәнне күрә. 3 нче икмәк заводында оеткы оету турында белә, чәкчәк пешерү серләре белән таныша. Ә Кариев театры балаларга серле пәрдә арты дөньясын: тегү һәм бутафория цехларының, тавыш яздыру студиясенең, грим ясау һәм костюмнар бүлмәсенең ишекләрен ача.

Венера Апачева, 24 нче мәктәпнең 8 нче «В» сыйныфы җитәкчесе:

– Бар да кызыклы һәм кирәкле булды. Иң мөһиме: күпләр авиация юнәлешендәге һөнәр сайлау турында уйлана башлады.

Дмитрий Корнев, 6 нчы гимназиянең 8 нче «Г» сыйныфы укучысы:

– Бүген «Казан Оргсинтез»да булдым, миңа бик ошады. Полиэтиленның ничек ясалганын белдем, һәм хәзер үземне шушы өлкәдә сынап карарга телим!

Ксения Хромова, Казан вертолёт заводының кадрлар сәясәте һәм социаль программалар бүлеге җитәкчесе урынбасары:

– Мондый экскурсияләрнең максаты – яшь, перспективалы кадрларны үзебезнең заводка эшкә җәлеп итү, яшьләрне эшче һөнәрләре белән таныштыру һәм шулай ук яшь буынны тәрбияләү. Ә һөнәрләр белән таныштыруны мөмкин кадәр иртәрәк, карьера үсешенең үз траекториясе булсын өчен, 9 сыйныфтан түгел, 5 сыйныфтан ук башларга кирәк.

Сергей Райхель, Velvette Marine верфе директоры:

– Балалар – киләчәгебез, һәм җәмгыятебезнең үсеше аларның профессиональ кызыксынуларын, омтылышларын никадәр уңышлырак ачыклавыбыздан тора.

АГРО ВОЛГА 2024

ХАЛЫКАРА АГРОСӘНӘГАТЬ КҮРГӘЗМӘСЕ

3–5 июль Казан

«Казан Экспо»
Халыкара күргәзмәләр үзәге

agrovolga.org

Реклама

акыллы гамәлләр
игелекле эшләр
мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Татарда хор сәнгате **кайчан** барлыкка килгән

Ни өчен Садыйковлар табиблыкны сайлаган

Салиховларның фәнни династиясенә **ничә** яшь

Айдаровлар династиясенә **кем** нигез салган

Сәлаховларның көрәшче династиясен **кем** дәвам итә

Фото: Александр Ефремов

«МИССИЯМ – ТАТАР МУЗЫКАСЫ БЕЛӘН ТАНЫШТЫРУ»

Руфия Фазылова

Сер түгел: без, татарлар, күбрәк үз казаныбызда кайныйбыз. Шуның өчен дә руслар, башка милләтләр безнең язучы, җырчыларның кайберләрен генә белә. Ә менә Миләүшә Тәминдарова исеме һәркемгә таныш. Белемле, кыю, хор белән генә түгел, хәтта армия белән идарә итәрдәй көч-куәт бар аңарда. Үзе белән очрашкач, моңа янә бер кат инандык.

Татарстан дәүләт камера хоры җитәкчесе, Татарстанның халык артисты, быелгы Тукай премиясе лауреаты Миләүшә Әмир кызы Тәминдарова бүген – редакциябез кунагы.

– Миләүшә ханым, сез зыялы мохиттә, педагоглар гаиләсендә үскәнсез. Кайсына күбрәк игътибар бирелде: әдәбияткамы, әллә инде музыка сәнгатенәме?

– Алай аерып карау булмады. Әнием – филолог, ТРның атказанган укытучысы иде. Күп еллар Казанның 80 нче мәктәбендә белем бирде. Совет чорында ук укучыларга эстетика дәресләре укытты. Мин кечкенә чагымда ук Гёте, Боттичеллиның кем икәнен белеп үстем. Әни Яңарыш чоры турында бик яратып сөйли иде. Шул рәвешле авыр гаиләләрдә үскән күпме баланың фикер сөрешен, аңын үстерде. Әни чын мәгънәсендә гаҗәп кеше иде, бик матур тавышлы да. Мәсәлән, Лермонтов иҗатына багышланган дәрестә «Ак җилкән» шигырен көйгә салып

сөйләгән. Әтиемнең әтисе дә бик матур җырлаган. Аның сеңлесе Рәшидә Тәминдарова танылган җырчы, опера һәм балет театры солисты булган. Ә аның җәмәгате Сәид Булатов театр училищесы директоры һәм Камал театрында режиссёр булып эшләгән. Кыскасы, бала чактан ук җыр сәнгате, әдәбият белән тыгыз бәйләнештә үстем. Шуның өчен дә барлык баскычларны уздым: музыка мәктәбе, училище, консерватория… Стажировканы профессор Семен Казачков классында үттем. Аннан соң мөгаллимлек эшчәнлегем башланды…

– Хор жанры татарлар өчен яңарак дисәм дә була. Һәрхәлдә, сез җитәкләгән Татарстан дәүләт камера хоры оешканчы, аңа игътибар юк иде кебек. Әллә мин ялгышаммы? Бүген бит сезнең хор иң мәртәбәле чараларда чыгыш ясый…

– Хорны татарлар үзләренең сәнгате дип санамый, һәм моңа аптырыйсы түгел. Татарларда җырчы гел үзе генә чыгыш ясаган. Хор сәнгате исә элек-электән күбрәк чиркәүгә бәйле саналган. Баштарак шактый тәнкыйть сүзләре ишеттем: «Бу татарча түгел», – дип тә әйтәләр иде.

Татарстан дәүләт камера хоры 2007 елда оешты. Яшермим: баштагы концертларга халыкны залга көчләп диярлек алып керә идек. Апам Әлфия бөтен туганнарны, танышларны өндәп чыга иде. Алар исә аклана: «Гафу ит, килә алмыйм, тегендә, монда барасым бар», – диләр… Һәм моңа беренче чиратта үзем гаепле дип саныйм.

– Ни өчен гаепле? Башта тамашачыга нәрсә кирәген аңламадыгызмы?

– Татарстан дәүләт камера хорын җитәкләгәнче, Казан хор мәктәбендә җырладым. Аннан соң Н. Җиһанов исемендәге консерватория каршында опера студиясе ачтым. Һәм үзем дә сизмәстән дәүләт хорын да шул юнәлештә алып киттем. Ә бу зур ялгышлык. Бала үскәч, ата-анасыннан мөстәкыйль, үзенчә яшәргә тиеш бит. Монда да шулай. Хормейстер ул сәнгатьнең аерым төре. Кулына уен коралы алгач, кеше уйный, ә хормейстер композитор язганны фәкать ишарәләр белән аңлата. Бу бик абстракт әйбер. Син аны ике кул белән дә, бер кул белән дә күрсәтә аласың. Шул ук вакытта бу үтә җаваплы эш: җырчылар нинди көй чыгара, авызын ничек ача, гәүдәсен ничек тота – барысы да синнән тора. Без, хормейстерлар өчен, музыка училищесында укытучы ничек әйтте, шулай булырга тиеш. Ә бу очракта сиңа ничек үз кыйбланңны, өслүбеңне табарга соң? Нинди дәрәҗәле хорларда эшләсәм дә, алар җәмгыятьнең заманча таләпләренә туры килми, дип таптым. Менә шуннан соң үз юнәлешемне булдырырга кирәклеген аңладым. Холкым шундый: тамашачының мәхәббәтен, игътибарын тулысынча яулыйсым килә. Сәхнәдә барысы да «Афәрин!» дип кычкырмаса, күңелем булмый. Алга шул максатны куйдым: без җырлаганда тамашачы еларга, уйланырга тиеш, җырларыбыз каз тәне чыгарырлык тәэсирле булсын. Әгәр болар юк икән, димәк, концерт уңышлы үтмәгән.

Концертларыбызда бөтен кешегә сәхнәгә чыгып җырларга һәм биергә мөмкинлек бирәм. Бер генә концертта да халык тик утырмый: тормасалар, урындыкларыннан үзем тартып чыгарам. Еш кына мәктәпләрдә дә чыгыш ясыйбыз. Укучыларны алдан кисәтеп куям: «Балалар, әгәр читтә оялып кына утырсагыз, өегезгә кайткач үкенәчәксез. Мин үзем гомерем буе эшләгән өчен түгел, эшләмәгән өчен үкендем. Оялуыгызны менә монда, хәзер җиңсәгез, әйтеп бетергесез канәгатьлек хисе алачаксыз». Һәм шулай була да: концерттан соң кочаклашып йөрибез.

– Ә карап торышка сез шактый кырыс кеше күренәсез…

– Ышанасызмы-юкмы – миндә тәкәбберлек беркайчан булмады. Аллаһы Тәгалә ул начар сыйфаттан арындырган. Әлбәттә, үз хокукларымны яклап тавыш күтәрә алам, әмма анысы икенче мәсьәлә бит. Кыю булырга кирәк, монысы белән килешәм. Укучылар янына баргач та гел әйтәм. Безнең татарларда ул проблема бигрәк тә сизелә. Әтинең

бер сүзе бар иде: «Яхшы кылан». Аз гына артистлана башласам, шул сүзне кабатлар иде, мәрхүмкәем. Ләкин бернигә дә карамыйча, миндәге бунтарь холык бер үзенчәлек булып формалашкан. Үз фикере, үз кыйбласы булган кеше тормышта күп нәрсәгә ирешә.

Әле менә күптән түгел бер мәктәптә чыгарылыш кичәсендә булдым. Балалар шигырь сөйләде, йөзләрендә ник бер мимика булсын. Биергә чыккач кына, күзләрендә нур барлыкка килде. Балаларны бер калыпка салырга ярамый. Андый чыгышларны карарга куркыныч!

– Миләүшә ханым, бу урында бер фикерем белән бүлешәсе килә: ике кызым да музыка мәктәбендә укый. Концертларына еш йөрим. Һәм гел шуңа игътибар итәм: музыка мәктәбендә укучы ул балалар чыгыш ясаганда ник бер елмаеп карасын! Сәхнәдә куырылып киләләр, димме шунда. Аларның максаты – укытучы биргән әсәрне дөрес уйнау, ә калганы мөһим түгел...

– Килешәм сезнең белән. Мин аларны «кечкенә картлар» дим. Һәм моңа укытучы гаепле! Әгәр музыка уен коралында уйнау яки аңа кушылып җырлау балага рәхәтлек бирми икән, димәк, техник бирем куймаска кирәк. «Бармакны болай гына куй, менә болай гына утыр», – дип, яшь музыкантны бер калыпка кертергә тырышу хәтта җинаять дияр идем! Укытучыларга бер киңәшем бар: берәр дәрес балага кисәтү ясамыйча карагыз – уйнасын үзенчә рәхәтләнеп. Уен коралын яратып, сөенеп уйнасын. Менә шунда баланың чын талантын, чын йөзен күрерсез. Музыка мәктәбен тәмамлаучылардан гел бер фикер ишетәм: безнең өчен ул чор куркыныч бер төш кебек! Монда кем гаепле? Әлбәттә, укытучы! «Кечкенә картлар» үстерәбез бит...

– Сезнең милли җанлы кеше икәнегезне бик яхшы беләбез. Татар милләтенең мәдәниятен башка халыкларга да күрсәтү өчен бик күп эшлисез. Шулай да... ана телебезне тагын да камилрәк белергә теләр идегезме?

– Яхшы сорау. Татар телен өйрәнәчәкмен, бу бары тик вакыт эше. Хәер, мин аны хәзер дә беләм: барлык сүзләрне дә аңлыйм, сөйли дә алам. Тик фикеремне рус телендә формалаштыру җиңелрәк. Әлбәттә, татар телендә рәхәтләнеп сөйләшә алмавыма кыенсынам. Тик икенче яктан караганда, әйтегез әле: милли сәнгать турында сөйләшкәндә, сезгә кайсы телдә аңлатуым мөһимме? Сез бит рус телен дә аңлыйсыз, башка татарлар да аңлый. Соңгы вакытта шуңа төшендем: миңа зур миссия йөкләнгән – русларга, ана телен белмәүче милләттәшләргә татар музыкасын җиткерү бурычы. Ә бу гаять зур һәм җаваплы эйбер...

– Сез быел Татарстанның мәртәбәле дәүләт бүләге – Тукай премиясен алдыгыз. Кандидатлар исемлегендә үзегезнең фамилияне күргәч, премияне бирерләр дигән өмет-ышаныч булдымы? Андый хыял бар идеме?

– Әлеге премияне хезмәтемә иң зур бәя дип саныйм. Кызыл мәйданда җыелган халыкны бер хор итеп җырлатканда, дирижер буларак, минем өчен бу уңышның иң зурысыдыр, дип уйлаган идем. Бүгенге көндә иң зур казанышым дип, Тукай премиясен атый алам.

Әлбәттә, «Татар хор музыкасы антологиясе»н эшләргә алынганда премия турында уйламадым. Сүз уңаеннан, аңа татар композиторларының 100 ел эчендә язылган иң әһәмиятле хор әсәрләре керде. Антологияне әзерләгәндә күпме йокысыз төннәр үткәрдем, күз яшьләре түктем. Дөресен әйтим, моңа кадәр бер генә программаны да бу кадәр катлаулы эшләгәнебез юк иде. Тере тавышка җырлау бер хәл, ә менә хорны яздыру – ул бик катлаулы шөгыль, техник якны күз алдында тотып әйтүем. Хорны аерым өлешләргә бүлеп яздырып булмый, без башта алай да эшләп карадык. Акапелла тоны ул башка, бер җырчының авыз ачып торуы түгел. Тын да алмыйча, җырны тулысынча бер сулышта башкарырга кирәк. Ә бу безнең кебек зур коллектив өчен шактый катлаулы. Сәхнәдән җырлаганда җиңелрәк: анда тамашачы артистның йөзенә, киеменә, дирижерга карый. Ә яздырганда боларның берсе дә күренми.

Иң үкенечлесе – Горкий урамындагы тавыш яздыру студиясе бүген юк, аның урынында – «Шаян ТВ». Һәм безнең кебек коллективка җыр яздырырдай студияләр Казанда калмады. Бәхеткә, Салмачы бистәсендә бер музыкантны табып, альбомны аның студиясендә яздырдык. Тагын бер кат кабатлап әйтәм: бу бик җитди, авыр эш булды. Аллаһка шөкер, дим, без моны ерып чыктык.

– Миләүшә ханым, репертуар турында да сөйләшәсе килә. Аны ничек сайлыйсыз? Элек бит худсоветлар бар иде...

– Иҗатчы – үзенә үзе сәнгать советы... Бу четерекле мәсьәлә. Әлбәттә, Мәдәният министрлыгы кебек дәүләт оешмалары, җәмгыятьнең ихтыяҗын тоемлап, худсоветлар оештырса, начар түгелдер. Хәер, алар андый таләпне куя да. Мисал өчен, безгә пролог, йомгаклау өлеше булырга тиеш, дигән катгый таләп куела. Ләкин музыканың нинди булырга тиешлеген без үзебез хәл итәбез. Бу яктан ашаган белми, тураган белә бит. Бәлки, бу дөрестер дә.

Миңа калса, Татарстан турында талантлы җырлар аз. Алар күп, ләкин алар чүп. «Мин яратам сине, Татарстан» кебек бөтен халык белгән җыр тагын бармы? Юк бит. Безгә менә шундый җырлар җитми.

– Аида Гарифуллина, Альбина Шаһиморатова кебек дөнья аренасында танылган җырчыларыбыз бар. Сез дә аларны яхшы беләсез. Ә сез кайсы укучыларыгыз белән горурлана аласыз?

– Хор артистларымның күбесе белән горурланам, дип әйтә алам. Әйе, алар Вена опера сәхнәләрендә җырламый, ләкин минем өчен бу мөһим түгел. Һәркемнең кимчелеген табарга мөмкин. Данлыклы сәхнәдә җырлау ул әле даһи дигән сүз түгел, бары тик алар тиешле вакытта тиешле урынга туры килгәннәр. Минем өчен безнең сәнгатьтә бер генә бөек кеше бар – Федор Иванович Шаляпин. Бетте. Ә, тагын әле Лучано Павароттины әйтер идем.

– Миләүшә ханым, хатын-кызның яшен сорамыйлар, әлбәттә. Әмма сездәге энергия торган саен арта бара кебек. Моның берәр сере бармы? Яшәү рәвеше, туклану, дигәндәй...

– Беренчедән, шуны әйтим: мин бүген һәр көнгә сөенеп яшим. Карагыз нинди заманда яшибез: Казан ничек үзгәрде, бөтен җирдә чисталык, зәвык... Нindидер икенче дөньяга эләккән кебек, яңа тормыш белән яши башладык. Әлхәмдүлилләһ, дим. Ә яшьләр нинди? Алар бүген бөтенләй икенче: тәрбияле, талантлы, белемле. Ә мин бит икенче заманнарны да хәтерлим. Хор белән концертларга баргач, коллектив исереп бетә иде. Бүген исә безнең арада бер генә эчүче кеше дә юк.

Бүген гармониядә яшим. Тормышымны яңабаштан барладым: бөтен начар гадәтләрдән баш тарттым. Нәтиҗәдә, үземне бәхетле дип әйтә алам. Улым, кызым белән яхшы мөнәсәбәтләр, аңлашу барлыкка килде. Ә бу хатын-кыз, ана кеше өчен бик мөһим. Улым да минем юлны сайлады, музыкант, гаиләсе белән Казанда гомер итә. Ике оныгым бар. Алар өчен сөенеп яшим. Кызым исә финанслар буенча аналитик. Бәхет тынычлыкны ярата, шуның өчен мактанасым килми. Шуны гына әйтәм: Аллаһы Тәгаләмә барысы өчен дә мең рәхмәтлемен, намазларымда да гел шуны кабатлыйм.

2024 ГАИЛӘ ЕЛЫ

ТАТАРСТАН ДИНАСТИЯЛӘРЕ

Профессиональ династияләр искиткеч күренеш: бу гаиләләрдә һөнәргә мәхәббәт, тугрылык буыннан буынга күчә бара. «Татарстан» үз укучыларын Татарстанның иң зур династияләре белән таныштыра башлый. Бу гаиләләрдә табиб, галим, архитектор, көрәшче булу, сайланган һөнәри юлны дәвам итеп, нәсел эшенә тугры калуны аңлата.

Бүген бездә кунакта:

1. **ТАБИБЛАР династиясе – Садыйковлар**
2. **ГАЛИМНӘР династиясе – Салиховлар**
3. **АРХИТЕКТОРЛАР династиясе – Айдаровлар**
4. **КӨРӘШЧЕЛӘР династиясе – Сәлаховлар**

ТАБИБЛАР ДИНАСТИЯСЕ – САДЫЙКОВЛАР

Бүгенге интернет заманында «булыш һәм зыян китермә» принципларына нигезләнгән Гиппократ антын искә алу урынлыдыр, чөнки кайсы гына социаль челтәрне ачма, анда бөтенесе киңәш бирә: теге яисә бу чирдән ничек котылырга, ничек ябыгырга, яшь калырга... Медицина вузын тәмамлаучы яшь белгечләр кешеләргә файдалы булырга, ә иң мөһиме – зыян китермәскә дип ант бирә бит. Ә инде табиблыкны гомерлек һөнәре итеп сайлаучылар, тәҗрибәләре белән бергә, әлеге язмыш йомгагының очын да буыннан буынга тапшыра. Шул рәвешле династияләр пәйда була.

Татарстанда иң танылган медицина династияләреннән берсе – Садыйковлар. Татарстанның сәламәтлек саклау министры булып эшләгән Марат Садыйков, кызганычка, безнең арабызда инде юк, әмма аның гаиләсе бүген дә татарстанлыларның сәламәтлеген саклый.

Фотолар Садыйковлар гаиләсе архивыннан.

ГАИЛӘ БАШЛЫГЫ

– Медицина өлкәсендә династияләр шактый, безнең Марат та бу чылбырны өзмәде, – ди Марат Наилевичның әтисе Наил Сәлах улы Садыйков. – Мин дә, хатыным да – табиблар. Хатыным Ленин стипендиаты, укуын кызыл диплом белән тәмамлады. Әле дә хәтерлим, Марат югары уку йортына керер алдыннан: «Әгәр әни кызыл диплом белән тәмамлаган икән, мин дә кызыл диплом белән тәмамлаячакмын!» – диде. Сүзендә торды да. Әйткән сүзендә тора иде – бу сыйфат аның һәр гамәленә хас булды. Әлбәттә, һөнәр сайлаганда аңарда бернинди икеләнүләрне күрмәдек. Эш өстәлендә һәрвакыт медицина әдәбияты ятар иде. Ул еш кына минем белән мәгълүмат уртаклашты, шул ук вакытта киңәшләште. Барысына да тиз төшенә, аңлап ала һәм киләчәктә кешеләр белән аралашканда, эшендә аларны куллана белде. Үз тирәсенә фикердәшләрен, хезмәтенә һәм туган иленә, республикасына тугры кешеләрне туплый алды. Аның УЛЫМ булуы белән мин бик горурланам.

– Медицина өлкәсендә династияләр шактый, безнең Марат та бу чылбырны өзмәде, – ди Марат Наилевичның әтисе Наил Сәлах улы Садыйков. – Мин дә, хатыным да – табиблар.

– Ә һөнәр сайлауга килгәндә, икеләнүләр булмады: әти кебек, әни кебек, абый кебек – табиб, – ди Гүзәл Наил кызы Садыйкова.

ТУГАННАР ЮЛЫННАН

Марат Наил улының сеңлесе – Гүзәл дә туганнары юлыннан китә. Бүген ул – Марат Садыйков исемендәге 7 нче хастаханәдә физиотерапия бүлеген җитәкли.

– Әти-әниебез ихтирамга лаек табиблар булды, бездән кеше өзелмәде, – дип сөйләде Гүзәл Наил кызы. – Алар, чын табиблар буларак, авыруларга ярдәм күрсәтүдән беркайчан да баш тартмадылар, төнлә килүчеләр дә еш булды. Без шуны күреп үстек, мөгаен, шуңа күрәдер дә әти-әниебезнең кешеләргә карата мәрхәмәтле мөнәсәбәтен үзебез өчен үрнәк иттек. Марат абыем гомер буе шундый булды: игелекле, ачык, бөтенләй таныш булмаган кешеләргә дә ярдәмгә килергә һәрвакыт әзер. Ул минем дә зур таянычым иде. Кирәк булганда, кәефне күтәрә белде. Һәрвакыт аның яклавын-саклавын тоеп яшәдем. Хәтта мәктәпкә дә җитәкләп йөртте – адым саен мине кайгыртты!

Әти-әниебез белән мөнәсәбәтләребез бик җылы булды. Марат алар өчен борчыла иде, аларга зур хөрмәт белән карады, тормыш ыгы-зыгыларыннан, мәшәкатьләрдән араларга тырышты. Әти-әни фикере аның өчен бик мөһим булды! Әни белән аны, гомумән, ниндидер күзгә күренми торган җепләр бәйләп торды. Алар бер-берсен ярты сүздән аңлап яшәде. Марат әнине гел нәрсә белән булса да сөендерергә тырышты. Ел саен, үзенең туган көнендә, ул, иртә таңнан әнигә шалтыратып, улы тууы белән котлый, ә аннары зур чәчәк бәйләме белән үзе килә. Командировкага киткән чагы туры килсә дә, әнигә һичшиксез зур чәчәк бәйләме җибәрә иде!

Мин һәрвакыт аңа тартылдым, үрнәк алдым. Абыем бишлегә генә укыганга, мин дә шундый булырга тырыштым. Аның йөзенә кызыллык китерә алмый идем, чөнки ул минем өчен шулкадәр мөһим булды! Ә һөнәр сайлауга килгәндә, икеләнүләр булмады: әти кебек, әни кебек, абый кебек – табиб.

Маратны бүген бик юксынам. Ул озакка сузылган командировкага киткән һәм тиздән әйләнеп кайтыр кебек... Килеп керер дә, һәрвакыттагыча елмаеп: «Ну, ничек хәлләр? Чәегезне куегыз, мин сезне бик сагындым», – дияр төсле.

ИҢ БЕРЕНЧЕ УРЫНДА – ЭШ

– Без институтның беренче курсында таныштык, – дип сөйли Марат Наилевичның хатыны Динара Садыйкова. – Аннары ике ел рәттән төзелеш отрядына бардык. Институтны тәмамлагач өйләнештек. Марат минем этидә укыды, ул КДМУның балалар авырулары пропедевтикасы кафедрасы доценты иде. Хәтерлим әле, эти: «Минем төркемдә шундый яхшы егет укый, игътибар ит әле!» - диде. Бу сүзләрне гаилә бәйрәмнәрендә еш искә ала идек. Институтта яшьләр алмашуның махсус программасы бар иде. Бишенче һәм алтынчы курслардан соң без Марат белән Брауншвейгка бардык. Анда өлкән яштәге немец гаиләсе белән дуслаштык, алар эш тәкъдим итте. Ул вакытта чит илгә китү яшьләрнең бик зур хыялы. Марат катгый рәвештә баш тартты. Ул чын патриот иде, илдән китү турында уйламады да. Ул эш дип яшәде, үзен аямый эшләде.

Бер очракны хәтерлим: танышым үзенең дусты турында сөйләде. Табиблар, туачак баласының җитди проблемалары бар дип, йөклелекне өзәргә үгетли икән. Марат моны ишеткәч: «Экспертка барырга кирәк!» - диде. Һәм шунда ук кешесен дә тапты. Ханым сау-сәламәт бала тудырды. Марат чын мәгънәсендә кечкенә генә бер гомерне саклап калды. Иң мөһиме – ул сорамасалар да, кешеләргә ярдәм итә башлый иде. Тормышыбызда мондый хәлләр шактый булды.

Табиб һөнәренең асылы – теләсә кайсы шартларда кешеләргә ярдәмгә килү. Кайда гына булсак та, Марат һәрвакыт ярдәм кулы сузды.

Ул һәрвакыт телефонда иде. Төн җитте исә, бала табабыз, дәвалыйбыз, киңәш бирәбез... Ул шулкадәр ачык, кешелекле иде – аңа төнлә дә, иртүк тә, бәйрәмдә дә, ял көннәрендә дә шалтыраталар. Коронавирус вакытында бик күп кешене коткарды, чөнки халык куркынычны аңлап бетермәде, бигрәк тә өлкән яштәгеләр. Мәсәлән, кайвакыт сүз арасында берәрсе: «Әти дә авырып тора әле», – ди. Марат шунда ук: «Ничә яшь?» – дип сорый. «76». «Булды, хастаханәгә салабыз!» Ул күпме дус-танышның әти-әнисен коткарды...

– Һөнәр сайлау безнең өчен авыр булмады, чөнки икебез дә медицина хезмәткәрләре гаиләсеннән, – ди Динара Садыйкова. – Барысы да тугач ук безгә салынган, хәл ителгән.

Марат минем һәр эшемне хуплап торды. Без бер-беребезгә һөнәри яктан үсәргә мөмкинлек бирә торган мөнәсәбәтләр кора алдык.

Һөнәр сайлау безнең өчен авыр булмады, чөнки икебез дә медицина хезмәткәрләре гаиләсеннән. Барысы да тугач ук безгә салынган, хәл ителгән. Балаларыбызның да медицина юлыннан китүен теләдек. Ләкин улыбыз башта дипломатия юлын сайларга уйлаган иде. Әмма гаилә башлыгы улыбызның фикерен үзгәртә алды: «Медицинада да дипломат булырга кирәк», – диде ул. Кызыбызның музыка буенча зур уңышлары бар иде. Һөнәр сайлау мәсьәләсе тугач, танылган дирижер Спиваков белән очраштырдык. Камилә үз юлын сайлаганда озак уйланды, әмма барыбер медицинага өстенлек бирде.

Марат чыннан да үз эшенең фанаты иде. Шуңа күрә һәрвакыт яхшы нәтиҗәләргә иреште. Мәсәлән, ул министр вазифасында эшләгәндә, күпме яңа дәвалау учреждениесе төзелде. Әлбәттә, бу тагын күп кенә кешеләрнең, министрлыкларның тырышлыгы, республика Рәисе Рөстәм Нургали улы Миңнехановның шәхсән казанышы булды. Марат аны чиксез хөрмәт итте һәм аның йөзенә кызыллык китермәскә тырышты. Ул барысын да контрольдә тотарга омтылды. Барысына да үзе шалтырата, элемтәләрне җайлый, шуңа күрә бөтен процесслар яхшы барды. Гел уртак нәтиҗәне кайгыртты.

Маратның бер хыялы бар иде. Минем этинең, дусларның әти-әниләренең бик каты авыруы моңа этәргеч булгандыр. Хәер, дусларныкы гына түгел. Гомумән, олы яштәге авыру кеше белән нишләргә? Балалары эшли. Хастаханәгә алмыйлар, кайгыртучан персоналны да һәрвакытта да табып булмый. Марат геронтология үзәге булдыру турында хыялланды. Картлар йорты түгел, ә өлкән яштәге авыру кешеләрне карау, аларга даими медицина ярдәме оештыру үзәге турында. Әлегә һәр гаилә бу мәсьәләне ялгыз хәл итә: кемдер эшеннән китәргә мәҗбүр, кемдер «сиделка» яллый. Ул бу проблеманы хәл итү турыда җиде еллап уйланды, әле министр булганчы ук. Коронавирустан соң ул бу идеяне тормышка ашыруга җитди рәвештә алынды. Бу проектның аналоглары юк.

Ул шулай ук педиатрия хезмәтен үстерү өчен күп нәрсә эшләде. Бу юнәлеш аның өчен һәрвакыт өстенлекле булды. Ул җитәкчелектә чакта балалар онкологиясе, гематология һәм хирургия үзәге ачылды, Казанның 7 нче шәһәр клиник хастаханәсе территориясендә перинаталь үзәк һәм башка күп кенә объектлар төзелә башлады. Алай гына да түгел, ул иң алдынгы технологияләрне куллануга зур игътибар бирде. Һәрвакыт: «Иртәгеге өчен төзергә кирәк. Киләчәкне күздә тотып. Югыйсә, төзелеш тәмамланганчы, барысы да искерергә өлгерәчәк», – ди иде. Мин бервакыт аңардан: «Сиңа болар барысы да нигә кирәк?» – дип сорадым. «Кешеләргә калачак», – дип җавап бирде Марат.

– Әти безнең медицина факультетында укуыбызны теләде, – ди Марсель Марат улы Садыйков. – Гаилә эшен дәвам итсеннәр дип. Камилә консерваториягә керергә хыяллана иде, ә мин – МГИМОга. Әтигә безнең белән аңлату эше алып барырга туры килде…

«КАЕНДА АЛМА ҮСМИ!»

– Әти безнең медицина факультетында укуыбызны теләде, – ди Марсель Марат улы Садыйков. – Гаилә эшен дәвам итсеннәр дип. Камилә консерваториягә керергә хыяллана иде, ә мин – МГИМОга. Әтигә безнең белән аңлату эше алып барырга туры килде…

– Әти мине танылган дирижерга алып барды, сайларга теләгән һөнәрнең барлык нечкәлекләрен аңлатсын өчен, – дип дәвам итә Марсельнең сеңлесе Камилә. – Сөйләшүдән соң табиблыкны сайладым.

– Минем белән дә унынчы сыйныфта сөйләшү булды, – дип искә ала Марсель. – Нәтиҗәдә медицина университетында белем алдым. Хәзер мин әтигә бик рәхмәтле, һөнәрем үземә ошый. Әтием – минем Укытучым. Ул минем Остазым.

– Һәм безнең шәхси Табиб та, – дип өсти Камилә. – Бервакыт дачада «Чылбыр-чылбыр» уйнаганда, асфальтка башым белән егылып, иремнемне ярдым. Хәтта берничә мизгелгә аңымны да җуйганмын. Әни шунда ук әтигә шалтыратты. Күземне ачуга, иң беренче әтиемнең куркынган күзләрен күрдем: «Кызым, кызым, син нихәл?» – дип сорады ул миннән. Ә аннары: «Асфальт төзәтеп булырлык хәлдә түгел!» – дип мәзәкләп тә алды. Үзе рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Аның көлүе миңа хәл кертте. Медицина вузында уку җиңел түгел. Без тырышабыз. Имтиханны яхшы тапшырабыз да әтигә шалтыратып мактанабыз. Ә ул горурланып: «Шәп булган, шәп. Каенда алма үсми!» – ди иде.

– Бервакыт самолетта ялдан кайтып киләбез. Бер ханым аңын җуйган – ярдәм сорадылар, – ди дәвам итте Марсель. – Әти белән әни шунда ук беренче ярдәмне күрсәттеләр. Бераздан бу турыда «Бизнес-онлайн» газетасында язып чыктылар, күрәсең, кемдер әтине таныган. Әти бик озак кәефсезләнеп йөрде. Ул үзен күрсәтергә яратмый иде: «Бу минем бурычым», – дия иде.

– Мин дә бер шундый очракны хәтерлим, – диде Камилә. – Әни белән дачада эштән соң килергә тиешле әтине көтәбез. Ул юлда барганда авария күргән. Әтием кабыргасы сынган ханымны үз машинасында хастаханәгә илткән. Шуннан соң гына дачага килде. Әти безне кешегә ярдәм итәргә өйрәтте, үзе шундый иде.

БОРЫННЫ САЛЫНДЫРМАСКА! ТЫНЫЧЛАНЫРГА ҺӘМ АЛГА!

Бу династиянең тагын бер вәкиле – Айрат Зыятдинов – Динара Садыйкованың энесе, «Республика балалар клиник хастаханәсе»нең баш табибы.

– Марат Динара апам белән очраша башлаганда, миңа 12 яшь иде, – дип искә ала Айрат. – Без бик тиз дуслаштык. Мин койрык кебек гел алар артыннан ияреп йөрдем. Без бер гаилә идек. Бергә бәрәңге казыдык, асфальт салдык, түбә яптык – мине һәр җиргә үзе белән йөртте, эшкә өйрәтте. Ул барыбызны да үз тирәсенә берләштерде, контрольдә тотты. Әмма бу бервакытта да киеренкелек тудырмады. Мондый кайгыртучанлыкны аңлап яшәдек. Ул үзенә дә, башкаларга да таләпчән булды. Эштә дә туганы дип тормады.

Динараның кулын сорарга килүен хәтерлим: барыбыз да дачада, апа белән җиләк чүбе утыйбыз. Марат иске «Волга» машинасында килеп туктады, карбыз да алган. Машинадан чыкты, карбызны өстәл өстенә куйды һәм бездән Динараның кулын сорады... Шул хәлдән соң дачадагы бөтен түтәл миңа калды. Гомумән, Марат холкы буенча яңалык тудыручы иде. Аның фикер сөреше киң, шуңа күрә сәламәтлек саклау өлкәсен үстерүдә аның өчен вак-төяк булмады. Ул эшебезне табиб буларак та, җитәкче буларак та аңлый иде. Ә оештыру сәләте – Аллаһыдан!

– Ул үзенә карата да, башкаларга карата да бик таләпчән булды. Эштә дә туганы дип тормады. Кайвакыт каты итеп орыша да алды, яхшы сүз белән күңелне дә күтәрә белде, – ди Айрат Зыятдинов.

Марат яхшы эти булды – балалар аны үлеп яратты. Кайгыртучан ир һәм ул иде. «Каенана – кияү» турында әллә нинди мәзәкләр сөйләсәләр дә, әни белән мөнәсәбәтләре бик яхшы булды, үзара аңлашып яшәделәр.

Миңа биргән киңәше һәрвакыт истә: эшләргә, үсәргә, борынны салындырмаска, тынычланырга һәм алга атларга!

ГАЛИМНӘР ДИНАСТИЯСЕ – САЛИХОВЛАР – ГАБӘШИЛӘР

Евгения Чеснокова

Архивларда эшләгәндә ТР ФАнең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры Радик Салихов XVII гасырда яшәгән Юныс Иванайның үзенең ерак бабасы булуын ачыклый. «Юныс Иванай – татарларда рәсми рәвештә танылган беренче галим, – дип аңлата Радик Рим улы. – Ул үзен тарихта да, математикада да, дин фәннәрендә дә таныта». Шул рәвешле безнең династия моннан 400 ел элек башланган дип исәпләргә була...

Россия икътисад мәктәбе профессоры, Сколково университеты доценты Марат Салихов һәм МГИМОның юридик факультеты магистранты Рәшит Салихов.

ТР ФАнең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры Радик Салихов.

Бала чагында уйнарга уенчыкларның аз булуын искә ала Радик Салихов. Әнисе – башлангыч сыйныф укытучысы, әтисе – аспирант, хезмәт хаклары мактанырлык түгел. Мамадышта кечкенә агач йортта яшиләр. Илдә торгынлык чоры хөкем сөрә... Ул чагында совет интеллигенциясе үз балаларына нәрсә бирә ала иде соң?..

КИТАП ДӨНЬЯСЫ

Чынлыкта, бик күп нәрсә бирә ала иде. Бөтен дөньяны. Китапларга яшеренгән дөньяны. Әйе, бүлмәдә уенчыклар җитми, аның каравы, дивар китап киштәләре белән тулган. Һәм бу теләсә нинди уенчык машинадан һәм йомшак аюдан яхшырак иде, ди Радик Рим улы. Бу китаплар аша аның белән татар классиклары – Габдулла Тукай да, Әмирхан Еники дә, башка бик күпләр әңгәмә кора.

Әтисе Рим Гариф улы Салихов филолог, татар әдәбияты белгече була. Һәрвакыт күзлектән, һәрвакыт каләм-кәгазе кулында, һәрвакыт нидер яза... Чын галим! Кандидатлык диссертациясен яклагач, гаилә Алабугага күченә. Аннан соң Рим Салихов фәннәр докторы, профессор була һәм күп еллар Алабуга педагогика институтында татар филологиясе кафедрасын җитәкли.

– Кунакка галимнәр, этинең хезмәттәшләре килгәч, аларның татар әдәбияты һәм тарихы турында сөйләшкәннәрен бик яхшы хәтерлим, – дип искә ала Радик Салихов. – Ул вакытта барысын да ачыктан-ачык сөйләп булмый иде бит. Мәсәлән, Алтын Урда, Идел буе Болгарстаны темалары галимнәр өчен ябык чак. Тыелган язучылар да бар, мәсәлән, Гаяз Исхакый. Ә галимнәр менә шундый очрашуларда гына бу турыда үзара фикер алыша иде. Татар телен саклау, хәзерге татар әдәби процессы турында да бик күп сөйләшәләр иде. Бу бик кызыклы, бай эчтәлекле тормыш, татар әдәбият белеменең күтәрелеш чоры булды.

ТАТАР СӘҮДӘГӘРЛЕГЕНЕҢ ЧЫН ТАРИХЫ

Яшь чагында Радикның галимнәр династиясен дәвам итәргә кирәк дип уйлаганы булмый. Ләкин аны татар халкының тарихы бик кызыксындыра, ул үз милләтенең тамырларын, чишмә башын табарга тели. Ләкин этисе укыр-

Фотографияләр Салиховларның гаилә архивыннан алынды

га тарих факультетына түгел, филологиягә керергә киңәш итә.

– Аның миңа: «Филологияне тәмамлаган ир – һәрвакыт алтын бәясе», – дигәне исемдә, – дип көлә Радик Рим улы.

Ләкин бүгенге Тарих институты директоры филолог белеме алуына үкенми. Казан дәүләт университетының филология факультеты укытучылары аны анализларга, чагыштырырга, фикерләргә өйрәтә. Болар исә соңыннан аңа бик ярап куя.

Ул шунда ук фән юлын сайламый. Башта Казан мәктәпләренең берсендә рус теле һәм әдәбияты укыта. Ибраһимов исемендәге Тел һәм әдәбият институтында ТАССР тарихы һәм мәдәнияте һәйкәлләре җыентыгын төзү өчен яңа программа буенча түләүле нигездә укырга җыя башлаганнарын да очраклы рәвештә генә ишетә. Бу юнәлешне профессор Юрий Смыков җитәкли. Татар тарихы белән шөгыльләнергә теләгән яшь филолог укытучы аның янына килә. Профессор Салиховка Иске Татар бистәсен өйрәнү белән шөгыльләнергә тәкъдим итә.

Шул ук вакытта Радик Рим улы ТӘһСИгә аспирантурага укырга керә. Һәм инде татар шигъриятендә лирик герой турында диссертациясен язып та бетерә диярлек. Ләкин бу өлкәнең үзе өчен туры килмәвен аңлап ала. Ул инде милли тарих дөньясына чумган була.

– Иске Татар бистәсе йортларын, аларны кем төзегәнен, анда кемнәр яшәгәнен өйрәнә башладым. Шунда минем өчен бөтенләй башка дөнья ачылды, – дип искә ала Радик Салихов. – Беренчедән, татар мәдәнияте күбрәк авылныкы дигән стереотипка карамастан, революциягә кадәр халкыбызда бик бай шәһәр мәдәни тормышы булганын аңладым. Икенчедән, «татар эшкуарлыгы» дигән төшенчә совет чорында бөтенләй юк иде. Ә хәлле татар сәүдәгәрләре яки хәзрәтләре байлар, кан эчүчеләр, искелек калдыклары дип кенә каралды. Югыйсә бу гаять зур тарихи күренеш булган бит! Авылдан чыккан, дөньяви белемнәре булмаган кешеләр, табигый сәләт, тапкырлык һәм тырышлыкларын эшкә җигеп, бик зур акчалар таба алган. Чыннан да гаять зур акчалар! Әмма шул ук вакытта алар шактый тыйнак тормыш алып барган, байлыкларының шактый өлешен мәчет-мәдрәсәләр төзүгә, фәкыйрьләргә ярдәмгә сарыф иткән. Һәм, сүз уңаеннан, бу кешеләр без бүген «гаилә кыйммәтләре» дип атаган төшенчәләргә тугры булып яшәгән. Әйе, ул сәүдәгәрләрнең, мөселман кануннары буенча яшәп, берничә хатынга өйләнеп, матди яктан аларны тәэмин итү мөмкинлеге дә булган. Ләкин гадәттә яшь чакта сайланган бер хатын белән гомер кичергәннәр.

Татар эшкуарлыгы тарихы фән сукмагына баскан галимне 1990 нчы еллар ахырында Татарстан Фәннәр академиясе структурасында ачылган Тарих институтына алып килә. 90 нчы елларда фән юлына басу, әлбәттә, кыю адым була. Галимнәр өчен авыр чор иде, дип искә ала Радик Салихов, гаиләне тәэмин итү өчен һәрвакыт кайдадыр өстәмә эшләргә туры килә. Аның каравы шул вакыттан бирле ул үзе өчен кызыклы эш белән шөгыльләнә: туган халкының тарихын өйрәнә.

СОЛТАН КЕЛӘМЕ ҺӘМ ФӘННИ ГЕННАР

Радик Салиховның ике улы да тормышларының аерым бер чорында математика һәм информатика белән кызыксына башлый. Әти кеше аптырап кала: гуманитарийлар гаиләсенә каян килгән нәрсә бу? Әмма акрынлап фәнни геннарны җыю җиңел түгеллеге ачыклана төшә. Өстәвенә яшь буын Салиховларда (тарихка тагын бер экскурс ясап алыйк) әниләре ягыннан да өйрәнү-тикшеренү омтылышы өчен җаваплы геннар бик көчле. Бабалары Рөстәм Габәшев – Татарстанның танылган археологы, неолит чоры белгече, тарих фәннәре кандидаты. Рөстәмнең этисе Солтан Габәши беренче татар профессиональ композиторы һәм музыка теоретигы була, милли фольклорны өйрәнә. Ә Солтанның этисе Хәсәнгата Габәши XX гасыр башында татарларда иң абруйлы дин әһелләренең һәм шул ук вакытта тәүге татар тарихчыларының берсе санала. Аның «Төрки халыкларның гомуми тарихы китабы» бөтен Шәрык дөньясында танылa. Төрек солтаны Габделхәмид бу китабы өчен авторга асылташлардан ясалган тәсбих һәм келәм бүләк итә. Бу келәмнең калдык-постыкларын Радик Салихов та хәтерли, алар бабасының балконында яткан...

Менә шундый нәселдәнлек җилләре кече Салиховларга балачактан ук тәэсир иткән. Олы уллары Маратның, ВМК тәмамлап, күпмедер вакыт программист булып эшләгәннән соң, кинәт кенә фән дөньясы белән кызыксынып китүенә гаҗәпләнәсеме? Ул Россия икътисад мәктәбе магистратурасына укырга керә, аннары Франциядә, Сингапурда халыкара аспирантурада укый. Икътисади фаразлау өлкәсендә диссертация яклый. Берникадәр вакыт Йель университетында (АКШ) эшли, ә аннары туган иленә кайта. Хәзер ул – Россия икътисад мәктәбе профессоры һәм Сколково университеты доценты. Үз эшен бик ярата, икътисадтагы математик ысуллар өлкәсендә илебездәге фәнни мәктәпнең киләчәге бик өметле дип саный.

Кече уллары Рәшит Казанда физика-математика мәктәбен тәмамлап, юридик факультетка укырга керә, хәзер Мәскәү дәүләт халыкара мөнәсәбәтләр институтының юридик факультеты магистратурасын тәмамлый һәм аспирантурага керергә ниятли. Төрле мәкаләләр яза һәм фәнни конференцияләрдә катнаша. Яше дүрт йөз елга якын булган династия эше әнә шулай дәвам итә.

Соңыннан Рим Салихов фән докторы, профессор була һәм күп еллар Алабуга педагогика институтында татар филологиясе кафедрасын җитәкли.

Галина һәм Равил Айдаровлар оныклары Арина белән.

АРХИТЕКТОРЛАР ДИНАСТИЯСЕ – АЙДАРОВЛАР

Евгения Чеснокова

«Минем сайлау мөмкинлеге булмады», – дип көлә Татарстанның атказанган архитекторы, КДАТУның график модельләштерү кафедрасы профессоры Равил Айдаров, ни өчен архитекторлыкка укырга баруы турында сөйләгәндә.

Аның этисе Сәйяр Айдаров – архитектор, КДАТУ (ул вакытта – Казан төзелеш институты) профессоры, Татарстанның Архитекторлар берлеге рәисе, республиканың реставрацияләү мәктәбенә нигез салучы булган. Иҗади мохиттә үскән, рәсем төшерүгә сәләтенә ия Равил үзеннән-үзе этисенең юлыннан китә.

Равил Сәйяр улының хатыны Галина архитектура факультетында булачак ире белән бер төркемдә укыган һәм каенатасын үзенең остазларының берсе дип саный. Галина ханым үзе дә архитектура докторы, профессор, КДАТУда архитектура теориясе һәм тарихы кафедрасын җитәкләгән.

Әле буталып бетмәдегезме? Алайса менә тагын бер факт: «Улыбызның да һөнәр сайлау мөмкинлеге булмагандыр, – ди Галина Айдарова-Волкова. – Без аннан сорап та тормадык – архитектура буенча укыячагы билгеле бит инде...»

Әйе, Равил Сәйяр улы белән Галина Николаевнаның улы Руслан Айдаров – шулай ук архитектор. Мәскәүдә бик билгеле белгеч, Мәскәү янындагы күп кенә шәхси йортларның проект авторы.

Әлегә Айдаровларның оныклары гына бу сафлардан төшеп кала. Хәер, Арина, яшь булса да, модалы дизайн өлкәсендә актив эшли. Артур музыка буенча китәргә ниятли. Алай дисәң, монда да нәсел тамырларын чамаларга була...

Фотолар Айдаровларның шәхси архивыннан алынды.

МИЛЛИ МОТИВ

Архитекторлар династиясенә нигез салган Сәйяр Ситдыйк улы Айдаров иҗади гаиләдә туып үскән. Әтисе Ситдыйк Айдаров – татар театр мәктәбенә нигез салучыларның берсе, опера җырчысы. Әнисе Галия Кайбицкая да күренекле актриса һәм җырчы булган (менә сезгә гаилә хорында музыка темасы). Казанның Айдаров һәм Кайбицкая урамнары алар хөрмәтенә шулай дип аталган.

Әти рәсем төшерүгә оста, өстәвенә фәнни фикерләү сәләтенә ия иде, дип искә ала Равил Сәйяр улы. Һәм бу аның архитекторлык язмышын да билгеләгән.

– Архитектурага бу дәрәҗәдә тугры һәм мөкиббән кешене очратканым юк иде әле, – дип сөйли Галина Айдарова. – Аның республиканың архитектура мирасын саклауга керткән өлеше бәяләп бетергесез.

Сәйяр Айдаров Татарстанда һәйкәлләрне реставрацияләү, торгызу һәм саклау мәктәбен оештыручы булып тора.

– Ул эшләгән елларда бөтен дөнья архитектурасында милли юнәлеш модада түгел иде, – дип искә ала Галина Николаевна. – Барысы да интернациональ стильгә йөз тотты. Ә Сәйяр Ситдыйк улы, үз сүзендә нык торып, проектларына «милли» теманы кертә иде.

Гамәлгә ашкан шундый проектларның берсе – Казанның Окольная урамындагы Рамазан мәчете. Тик өлкән Айдаров тәкъдим иткән милли китапханә бинасы төзелмичә калган. Төзелеш өчен Черек күлнең төньяк яры күздә тотылган. Көнчыгыш традицияләрендә төзелергә тиешле мәһабәт бина проекты, күрәсең, зур чыгымнар таләп иткән...

Аның каравы, Болгар, Свияжск, Казан Кремлендәге күп кенә һәйкәлләр аның катнашында төзекләндерелгән. Ул Кремльгә Кол Шәриф мәчетен кайтару концепциясенең башында торган кеше дә. Сәйяр Айдаровның идеяләрен аның күпсанлы шәкертләре дәвам итә – ул бит ярты гасыр дәвамында КДАТУда архитекторлар әзерләгән шәхес.

АКВАРЕЛЬ ТӨСМЕРЛӘРЕНДӘ

– Әти, әлбәттә, уникаль белгеч иде, – дип искә ала Равил Сәйяр улы. – Минем студент чакта эшләгән проектка күз сала да: «Менә бу сызыклар параллель түгел», – ди. Ничек инде параллель түгел, алай булуы мөмкин түгел! Ә күпмедер вакыттан соң күрәм: аерма ярты гына миллиметр, әмма бар бит...

Равил Айдаров, әтисе эзеннән китеп институтны тәмамлаганнан соң, озак еллар Казанның Вахитов районында баш архитектор, шәһәрнең баш рәссамы булып эшли, үзенең архитектура остаханәсен тота. Һәм тагын ул Казанның агачтан төзелгән йортлары турындагы хәтерне саклаучы да булып китә.

– Мин эшләгәндә, Вахитов районы гел агачтан төзелгән йортлардан тора иде. Күрәсең, язмыш миңа ул урамнардан фотоаппарат тотып узарга кушкандыр. Шулай итеп, Казанның агач йортлары турында шактый тулы мәгълүмат бирә торган архив тупланды.

Соңрак ул Казанның агач йортларына багышланган диссертация яклый. Шулай ук хатыны белән бергәләп, шул фотографияләргә нигезләнеп, үзе дә урыннарга барып ясап, акварель буяулар белән төшерелгән иллюстрацияләрдән торган берничә китап чыгара. Ул рәсемнәр башкалабызның уникаль агач архитектурасын бик вак детальләренә кадәр кабатлый, хәзер инде Казан урамнарында, кызганыч, алар калмады диярлек. Әмма Айдаровның картиналарында иске йортлар гүя терелеп баса да элеккечә күңелне сөендерә...

Сынлы сәнгать – аның яраткан шөгыле. Бүген, мәсәлән, КДАТУ холларының берсендә (Равил Айдаров бүген дә анда укыта – шулай ук әтисе юлыннан) аның акварельләренең күргәзмәсе белән танышырга була.

Сүз уңаеннан, Равил Сәйяр улының төпчек энесе Ильяс хезмәт юлын архитектор буларак башлаган, соңыннан исә танылган рәссам булып киткән, хәзер Россия сәнгать академиясе әгъзасы.

– Аннан дәресләр алырга телим, – ди Равил Айдаров. – Холкым шундый: гел ниндидер яңа нәрсә белән шөгыльләнәсем килә...

ТАРИХИ НОКТА

Галина һәм Равил Айдаровлар инде 50 ел бергә гомер кичерә. Якын кешең белән сөйләшер өчен уртак темалар булуы – бәхет, ди Равил Айдаров. Гәрчә аларның һөнәри кызыксыну даирәләре күпмедер дәрәҗәдә аерылса да. Галина Николаевна архитектура теориясе һәм тарихы белән шөгыльләнә, Урта Идел шәһәр төзелеше өлкәсендә мәдәниятләрнең үзара йогынтысын өйрәнә.

Тикшеренү предметларының берсе – Сөембикә манарасы. Аның пәйда булуы турында төрле карашлар яши, ди Галина Айдарова. Төзелеш вакыты – XV гасыр–XVII гасыр ахыры дип тә фаразлана. Әйтергә кирәк, Сәйяр Айдаров манара руслар тарафыннан төзелгән дигән фикерне яклаган. Ә менә Галина Николаевна, 23 критерий буенча җентекле стилистик анализ ясаганнан соң, анда готика һәм роман стильләре эзләрен таба, ә бу исә манараның элегрәк төзелүенә дәлил булып тора, ягъни ул Казан ханлыгы Россиягә кушылганчы ук башкаланы бизәп торган булырга мөмкин.

Әлбәттә, хәзер заманча ысуллар да бар, ди тикшеренүче. Мәсәлән, радиоуглеродлы анализ ярдәмендә Кремльнең авыш манарасының яшен билгеләп булыр иде. Ләкин ни өчендер әлеге ысуллар Сөмбикә манарасына карата кулланылмый.

– Ул заманча ысуллар белән тикшергәннәрен көтеп алыр, дип уйлыйм, – ди Галина Айдарова. – Көтеп ала алсын инде берүк...

Руслан Айдаров, архитектор, Мәскәү.

Ильяс Айдаров, хезмәт юлын архитектор буларак башлаган, соңыннан танылган рәссам булып киткән, хәзерге вакытта Россия сәнгать академиясе әгъзасы.

Радик Сәлахов үзенең беренче тренеры – әтисе Сурен Сәлахов белән.

БАТЫРЛАР ДИНАСТИЯСЕ – СӘЛАХОВЛАР

Дмитрий Сивков

Зәй районының Сармашбаш авылында уза торган Сабан туенда милли көрәштә батыр калу һәрвакыт аерым бер мәгънәне аңлата. Җиңүченең иңнәренә тәкә салу белән генә бетми, батыр грек-рим көрәше буенча СССР чемпионына күрсәтелгәндәй мактау-хөрмәткә ия була анда. Хәер, авылда андый чемпионнар да булган.

Болгар. 19 май. Идел буе Болгарстаны дәүләтендә рәсми рәвештә Ислам дине кабул итү уңаеннан уздырыла торган «Изге Болгар җыены». Бәйрәм программасында – көрәш буенча халыкара ярышлар. Бу турнирда көч сынашырга дип, 17 ил вәкиле килгән. Төп бүләк Lada Granta автомобиле кемгә эләгер? Ул иң авыр үлчәүдәге чемпионны көтә.

Һәм менә суперфиналдагы көндәшләр, келәмгә чыгарга үз чиратын көтеп, бер-берсеннән ерак түгел генә чираттагы көрәшне күзәтә.

Азәрбайҗаннан килгән Хурал Азимов пляж королен хәтерләтә: озын буйлы, мускуллары уйнаклап тора (кулларын күкрәгенә куйса, беләгендәге мускуллары күлмәк җиңен ертыр кебек тоела), җилкәләре төз, ияген чөебрәк куйган, карашы горур...

Татарстаннан Радик Сәлахов аннан һәрьяклап калыша кебек: көндәшеннән ярты баш түбәнрәк, гәүдәсендә атлет чалымнары да сизелми диярлек...

Читтән карап торган берәүдән җиңүче кем була дип сорасалар, ул ике дә уйламыйча, беренчесенә төртеп күрсәтер иде. Әлеге текстның авторы да шулай дияр иде, әгәр дә берәр сәгать элегрәк сорасалар. Ул вакытта мин катнашу-

Автор фотосы

чыларның иң мәгърур кыяфәтлесеннән машина ачкычының хуҗасы кем булачак дип сорарга өлгергән идем. Миңа, һичбер икеләнүсез, Радик диделәр. Сәлахов Хурал Азимовны тәгәрәтеп кенә йөртте диярлек. Эш таблода янып торган 7:3 исәбендә дә түгел. Азәрбайҗанның келәмдә яткан батырына көрәшнең тәмамлану турындагы командадан соң карап торырга да кызганыч иде.

«БЕЗНЕ ӘТИЛӘР БИРЕГӘ КУЛДАН ҖИТӘКЛӘП АЛЫП КИЛӘ»

– Син кайдан? – дип сорады Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Радикка Lada Granta ачкычын тапшырганда.

– Чаллыдан, – дип, кыска гына җавап бирде батыр.

Чыннан да, хәзер ул Яр Чаллыда яши, әмма ул вакытта сөйләшеп торырга вакыты булса, ул үзенең Зәй районы Сармашбаш авылыннан икәнлеген дә әйтер иде. Әмма бүләкләү тантанасы тиз уза, боларын ук сөйләшергә вакыт калмый. Аның каравы соңыннан чемпионның «Татарстан» журналы белән иркенләп сөйләшергә вакыты табылды.

Көрәш буенча соңгы ике елда дөнья, биш тапкыр Россия чемпионын беренче тапкыр авылның көрәш залына әтисе Сурен Хәмит улы җитәкләп алып килә. Үзе беренче тренеры да була. Алты яшьлек малайның көрәшче булыргамы-юкмы дип сайланып тору мөмкинлеге дә юк – аларның нәселендә буыннан буынга көрәшчеләр үсә. Тик барысы да диярлек авыл Сабан туйларында гына көрәшә.

Сабан туенда батыр калу бик мактаулы санала. Көндәшлек тә зур – утызга якын көрәшче катнаша. Өстәвенә, сүз батырлары белән данлыклы авыл турында бара. СССРның грек-рим көрәше буенча ике чемпионын – абыйлы-энеле Мансур белән Илсур Минһаҗевларны үстереп биргән авыл бу. Сабан туе батырларына да мактау-хөрмәт ким түгел анда. Сәлаховлар нәселендә андый мактауларга лаек булган батырлар бер генә буында түгел. Аз дигәндә, Радик Хәмит бабасы, әтисе турында белә, үзе дә өч-дүрт тапкыр батыр калган.

КӨРӘШТӘ ТИЗ ӨЛГЕРӘ ТОРГАННАР БУЛМЫЙ

Сурен Сәлахов үзе спортта әллә ни үрләр яуламаган – район дәрәҗәсеннән югарырак күтәрелмәгән. Аның каравы Әлмәттә физкультура техникумын тәмамлаган, туган авылына кайтып, лаеклы ялга киткән тренерын алыштырган. Төрле дәрәҗәдәге үрләр яулаган йөзләрчә спортчы тәрбияләгән, берсе 2022 һәм 2023 елларда дөнья чемпионы исеменә дә лаек булган. Кызганыч, тренер үзе бу турыда белми калган.

– Әтинең безнең арадан китүенә дүрт ел инде, әмма ул күкләрдән минем уңышларымны күреп сөенәдер, дип ышанам. Мин аны һәрвакыт янымда кебек сизәм һәм җиңүләремне дә гел аңа багышлыйм, – ди Радик.

Сурен Сәлахов исеме бу дөньяда да һәрвакытта да улы белән янәшә йөри. Көрәшчеләрдә шулай кабул ителгән: алар һәрвакыт ике тренерны күрсәтә – беренчесен һәм хәзергесен. Хәзерге вакытта чемпион «Витязь» спорт клубында Илнур Хәйбуллин җитәкчелегендә шөгыльләнә. Металл җыю компаниясендә демонтаж буенча мастер булып эшли. Атнага 4–5 тапкыр тренировкага йөри. Югыйсә чемпион була алмыйсың. Шулай да ничек итеп барысына да өлгерүен күз алдына китерү җиңел түгел.

– Белмим, ияләштем инде, – ди 30 яшьлек батыр тыйнак кына.

Авырлыгы 128 килограмм, бернинди махсус диета тотмый, энисе Ләйсән яки хатыны Алия нәрсә әзерли, шуны ашый. Хатыны белән Райан исемле кыз үстерәләр, аңа бер яшь инде. Көрәшче традицияләрен тапшырырга варис та кирәк әле, дип елмая эти кеше. Улына булса да остаз булыр, әмма менә тренерлык эшенә теләге юк. Әтисенең үрнәгендә тренер булуның ни икәнен яхшы белә: күпме көч, вакыт, киеренкелек таләп итә торган хезмәт...

– Тренерлык талантым да юк минем. Әйбәт спортчының барысы да әйбәт тренер була дигән сүз түгел. Үземне алдарга теләмим, – ди Радик.

Шулай да бер кешегә искәрмә ясый – төпчек энесе Рөстәмне өйрәтә. Анысы әлегә «икенче-өченче» булып йөри. ТР чемпионатында икенче булды менә.

– Әлегә алтыны юк әле аның, әмма аның да чемпион булуын телим. Вакыт бар әле, Рөстәмгә 25 яшь, ә көрәштә тиз өлгерә торганнар булмый. Ир-ат көче керергә тиеш, – дип, энесенең хыялын әйтеп сала абыйсы.

Журналның бу саны басмага әзерләнгәндә, Россия җыелма командасы әгъзасы Анапада җыенда булды, Пермьдә Россия чемпионатында катнашты. Аннан инде ул алтынчы тапкыр ил чемпионы булып кайтты. Чиратта – БРИКС Уеннары. Радик Сәлаховның андый титулы әлегә юк. Гомумән, берәүнеке дә юк. Исемен тарихка теркәп кую өчен форсат чыгып тора.

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Радикка Lada Granta машинасы ачкычын тапшыра.

МӘКТӘП БЕЛЕМЕ ГАИЛӘ РИТМЫНДА

Җәй. Каникуллар. Ә мәктәп тулы бала...

Мәктәп янына балаларын көтеп торучы әниләр җыелган.

Менә бер малай үзен алырга дип килгән әтисе янында еламсырап басып тора – мәктәптән кайтып китәсе килми икән...

Мондый күренешләр күп профильле 187 нче лицейда инде гадәтигә әверелгән.

– Балалар монда үзләрен өйдәге кебек хис итә, кунып калырга да риза, – дип елмая лицей директоры Гөлнара Галиева. – Без монда тату бер гаилә булып яшибез. Ә гаиләбез бик зур – балалар гына да 1816! Тагын әле укытучылар, техник хезмәткәрләр, аш-су осталары, сакчылар, клининг хезмәте хезмәткәрләре...

ГАИЛӘ БАШЛЫГЫ

Тагын әле «Ритм» лицеенда гаиләчелек һәр яклап хуплана. Монда гаилә парлары эшли. Һәр сыйныфта, һәр параллельдә бертуганнар укый. Монда укытучы әниләр белән укытучы әтиләр үз балаларын һәм оныкларын укырга алып килә. Дәресләрне сәбәпсез калдырып кара!

Бу зур мәктәп гаиләсенең башлыгы Гөлнара Габбас кызы Галиева әлеге җәмгыятьнең һәр әгъзасы турында сәгатьләр буе сөйли ала: ул аларның һәрберсен исемләп белә, кемнең ничек укыганыннан һәм кем кемгә ничек туган икәненнән хәбәрдар.

Ә директор кабинетында балалар үз куллары белән ясаган бүләкләр бик күп, ул аларны кадерләп кысага урнаштырган. Мәсәлән, беренче сыйныф укучысы Ралинаның басмабызда бирелгән рәсеме кебек. Анда әниләр таҗ кигән, араларында Гөлнара Габбасовна да бар – башында – таҗ, күкрәгенә исә зур алсу йөрәк ясалган...

Сигезенче сыйныф укучысы Савелий И. акварелендә лицей директоры алга омтылган паровоз рәвешендә сурәтләнгән. «Алга» дигән язуы да бар. Татарстанда бу сүзне берниндир телгә дә тәрҗемә итеп торасы юк – һәркем аңлый. Балаларда менә шундый ассоциация туа.

Ә менә Роберт Т. исемле чыгарылыш сыйныф укучысыннан бүләккә органайзер: ул аларны барлык укытучыларга истәлек итеп ясаган һәм һәрберсенә аерым язу да язган. Яраткан директорына Капицаның сүзләрен куйган: «Җитәкчелек итү – яхшы кешеләргә эшләргә комачауламау ул».

Фото: Ната Смирнова. РЕКЛАМА

ХЕЗМӘТ УКЫТУЧЫСЫН НИЧЕК ҖӘЛЕП ИТӘРГӘ

Лицейда ике гаилә пары эшли. Икесе дә монда гадәти булмаган һәм хәтта гаҗәеп юл белән килгән. Мәсәлән, Ләйсән Камил кызы белән Валерий Иванович Абакаевлар Алабуга районыннан күчкән. Валерий Иванович – технология укытучысы, 8 нче инженер сыйныфында сыйныф җитәкчесе. Ә Ләйсән Камил кызы - татар теле һәм әдәбияты укытучысы һәм милли белем бирү буенча директор урынбасары, шулай ук «Заман» фольклор ансамбле һәм «Мирас» театр коллективы кураторы.

Ләйсән Камил кызы үзенең резюмесын Совет районы мәгариф бүлеге сайтында калдыра һәм аны «Ритм»га чакыралар. Ул вакытта хезмәт стажы буенча пенсиягә чыккан һәм мәктәптә бүтән эшләргә уйламаган да ирен Ләйсән Камил кызы 187 нче лицейга станоклар белән кызыктырып китерә.

– Без элек эшләгән мәктәптә технология кабинетында гадәти токарь, агач эшкәртү станоклары куелган иде, – дип аңлата Ләйсән Камил кызы. – Ә монда югары технологияләр! Ул «булачак» кабинетына кергәч, барысын да күргәч, бастион җимерелде! Һәм: «Хәзер миңа яңадан укырга кирәк булачак», – диде.

Шул вакыттан бирле ел саен Мәскәүдә укый, шуннан соң лицей укучылары технология буенча төрле конкурс һәм конференцияләрдә җиңүче һәм призер булалар.

– Күптән түгел аның Хәят исемле укучысы технология буенча мәктәп укучылары олимпиадасының республика этабында җиңүче булды, – ди Ләйсән Камил кызы. – Олимпиадада малайлар арасында ул бердәнбер кыз иде һәм җиңде! Эшли башлаганнан бирле Валерий Иванович технология буенча призерлар әзерли.

– Чынлыкта монда эшләү шулкадәр кызыклы, без өйгә йокларга гына кайтабыз, хәер, кабинетларда диваннар да өйдәге кебек, – дип көлә Ләйсән Камил кызы. – Балаларыбыз искиткеч, бер-беребезгә карата дустанә мөнәсәбәттә. Мин – лицеебызның беренче чыгарылышының сыйныф җитәкчесе. Тәүге 11 нче сыйныф укучылары – минекеләр. Шулкадәр ияләшенгән, бер дә җибәрәсем килми, дөресен генә әйткәндә, йөрәк елый.

ДӨРЕС ФОРМАЛАШТЫРЫЛГАН ХЫЯЛЛАР ТОРМЫШКА АША

Икенче гаилә пары – физкультура укытучылары: Миндания Рәшит кызы белән Николай Александрович Шмыковлар.

– Алар безгә узган уку елында килде. Спорт залында хуҗа һәм хуҗабикә табылуын бик теләгән идем, хыялым шундый иде, – дип сөйли Гөлнара Габбас кызы. – Хыялым тормышка ашты. Әлеге гаилә парының укучылары – физик культура буенча Республика мәктәп укучылары олимпиадасы җиңүчеләре һәм призерлары, физик культура буенча Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының муниципаль этабы призерлары.

– Бәхет ул – иртән – эшкә, ә кич өйгә кайтырга теләгәндә, диләр бит әле, – ди Миндания Рәшит кызы. – Ә эшеңә өеңә караган кебек карый аласың икән, бу икеләтә бәхет. Без өйдә дә, эштә дә бергә, беркая ашыгырга кирәкми, бары тик баланы бакчадан алырга ашыксаң гына. Балабыз да тиздән беренче сыйныфка барачак, шуңа күрә бөтен гаиләбез белән бергә булачакбыз.

– Хатыным белән тулысынча килешәм, – дип өсти Николай Александрович. – Без эшкә түгел, ә бер өйдән икенче өебезгә йөрибез кебек, ягъни бернинди киеренкелек юк. Ун еллап физрук булып эшләдем, эшемне алыштырырга кирәк дигән уйлар да кергәли башлаган иде. Узган ел барысын да үзгәртте. Бәлки, хатыным белән бергә эшли башлаганга һәм гаиләдәй җылы командага эләккәнгәдер, хезмәтемне дөньядагы иң яхшы эш дип кабул итә башладым. Безнең лицей быел Россия Олимпия комитеты президенты Станислав Поздняков җитәкчелегендәге «Олимпия патрулен» каршы алырга лаек дип табылды. Араларында бокс буенча Олимпия чемпионы Евгений Тищенко һәм нәфис гимнастика буенча Олимпия чемпионкасы Анастасия Назаренко да бар иде. Балалар бу очрашуга бик шатланды, чөнки шундый зур йолдызларны үз күзләре белән беренче күрүләре иде. Әле кайда мәктәпкә Олимпия чемпионы килә! Әле кайда алар йолдызлардан автограф ала!

Кунаклар тәҗрибәләре белән уртаклаштылар, карьераларын ничек төзегәннәре турында сөйләделәр. Бу балалар өчен бик яхшы үрнәк, юл күрсәтүче йолдыз!

ИКЕЛӘТӘ КҮЗӘТҮ АСТЫНДА

Лицейда укытучы балалары гына түгел, ә башка хезмәткәрләрнекеләр дә укый: клининг компаниясе, сак хезмәте, ашсу осталары, администрация…

– Моның бернинди начарлыгы юк, – дип Гөлнара Габбас кызы. – Димәк, алар мәктәбебезгә ышаныч күрсәтә. Балаларың янәшәдә укыганда, алар өчен уңайлырак, чистарак, тәмлерәк булсын дип тә тырышасың бит әле. Тагын шунысы да бар: бала икеләтә - укытучы белән ата-ана күзәтүендә белем ала. Яисә туганнар күзәтүендә, чөнки лицейда бер гаиләдән бер-бер артлы килүче балалар да күп укый.

Адилә Гасыймова, 9 нчы сыйныф:

– Мин монда быел гына күчендем, әмма шунда ук үземне тату гаиләгә эләккән кебек хис иттем. Монда өлкәннәр кечерәкләргә ярдәм итә, укытучылар, эти-әни кебек, безне кайгырта, яклый, тәрбияли. Энем дә биредә белем ала.

Мин үзем лицейның спорт тормышында актив катнашам, мәктәп өчен чыгышлар ясыйм. Шулай ук төрле бөтенроссия һәм халыкара конференцияләрдә катнашам, призлы урыннар алам. Ә күптән түгел без «Мирас» театр төркеме белән 1 млн сум күләмендә мэр грантын оттык. Акчаның бер өлешен Нәҗип Җиһановка багышланган музей экспозициясенә тотачакбыз, чөнки лицеебыз бу танылган татар композиторы исемен йөртүче урамда урнашкан, ә бер өлеше милли костюмнар сатып алуга китәчәк.

Раилә Сәгъдиева, 11 нче «Б» сыйныфы:

– Барысы да безнең лицей зур гаилә кебек, диләр, минем өчен дә бу гади метафора гына түгел. Бөтен гаиләм диярлек монда. Минем белән бергә 11 нче сыйныфта игезәк сыңарым укый. Әнием дә монда татар теле укытучысы булып эшли. Киләсе елда энекәшем укырга киләчәк. Барыбыз бергә монда. Гомумән, лицейда бик җылы мохит урнашкан. Сыйныфташларым арасында да, театр төркемендә дә дусларым күп. Театр миңа күп яңа хисләр бүләк итте, репетицияләрне һәм 11 нче сыйныф имтиханнарына әзерлекне бергә алып бару җиңел булмаса да. Ләкин барысына да өлгердем!

Булат Хәлиуллин, 11 нче «Б» сыйныфы:

– Минем өчен лицей гаиләмнең бер өлеше шикелле. Чын-чынлап. Минем бу лицейда ике энекәшем укый: берсе – сигезенчедә, икенчесе әле беренчесе сыйныфта гына. Лицей миңа энергиямне үземне кызыксындырган, үземә ошаган якка юнәлтергә ярдәм итте. Һәм лицей ярдәмендә мин экология буенча Бөтенроссия укучылар олимпиадасының йомгаклау этабында призер булдым.

Арина Смирнова, 11 нче «Б» сыйныфы, лицейның беренче президенты:

– Мин монда 2020 елда лицей ачылгач килдем. Безгә 14 яшь иде, бу – күчеш чоры, авыр вакытларны без укытучылар, директор белән бергә үткәрдек. Безгә һәрвакыт ярдәм иттеләр: укуда да, имтиханнарга әзерләнүдә дә, һөнәр сайлауда да. Безгә үзебезне төрле өлкәләрдә сынап карау өчен бик күп мөмкинлекләр бирелде. Биредә психология-педагогика сыйныфы да, физика-математика сыйныфы да, метрология сыйныфы да, төрле стажировкалар да бар. Һөнәрләр бик күп – кайсын сайларга?.. Һәм лицей нинди юнәлештә барырга кирәклеген күрсәтте. Әгәр дә барысы да мин уйлаганча барып чыкса, продюсер булачакмын. Әдәбиятны менә 100 баллга тапшырдым. Шундый остазларым һәм лицеем булу белән мин бик бәхетле.

Камилла Михайлова, 10 нчы «Б» сыйныфы:

– Монда үзеңне күрсәтү өчен мөмкинлекләр, төрле юнәлешләрдә үсү өчен фикердәшләр күп. Мәсәлән, «Олы тәнәфес», «Алдынгылар хәрәкәте» буенча остазлар бар. Монда укуны да, ниндидер җәмәгать эшләрен дә җиңел генә берләштереп була. Узган ел мин «Росатом» дәүләт корпорациясенең «Белем бозваткычы»нда Төньяк полюска экспедициядә катнаштым. Планетабызның нуленче ноктасы тирәли дөнья буйлап иң тиз сәяхәт оештырдык. Шулай ук мин 2024 елда «Сириус»та Бөтендөнья яшьләр фестивалендә катнаша алдым, анда бөтен дөньядан делегатлар килгән иде.

Минем бер гадәтем бар: кайда гына булсам да, Татарстан флагы белән фотога төшәм һәм татар телендә Казан турында җыр җырлыйм.

Камил Рөстәм улы Абдулвахобов, уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары:

– Мондый мәктәптә укырга теләр идемме? Әлбәттә! Ләкин укыганда сыйныфташларыңның сине аңлавы, үзеңне өйдәге кебек хис итү, сиңа уңайлы, укытучыларың белән мөнәсәбәтләрнең яхшы булуы мөһим. Биредә боларның барысы да бар. Үзем укыган елларда минем дә барысы да бар иде, шуңа күрә мәктәп еллары турында иң яхшы хатирәләр генә сакланган. Әмма өлкәннәр күзлегеннән караганда, лицей укучыларының үз сәләтләрен тормышка ашыру өчен мөмкинлекләре күбрәк. Бигрәк тә Фәнни-технологик үсеш елында!

МЕТРОЛОГИЯ БУЕНЧА БЕЛЕМ БИРҮ

– Күптән түгел бездә «Метрология» юнәлеше барлыкка килде, – дип сөйли Гөлнара Габбас кызы мәктәпнең белем бирү челтәренә чираттагы яңалык кертелүе турында. – Аны лицейның мәгълүматлаштыру буенча директор урынбасары Анна Николаевна Яблонская җитәкли. ВНИИР җитәкчесе урынбасары Иосиф Израилевич Фишман белән тиз арада уртак тел таптылар, аларга Ольга Юрьевна да кушылды. Һәм алар безнең 10 «А», 11 «А» һәм булачак 5 «М» – метрология сыйныфларын җитәклиләр.

Иосиф Израилевич Фишман:

– Росстандарт, метрологлар әзерләүнең зарурлыгын аңлап, Россиядә метрология кластеры булдыру турында боерык чыгарды, һәм без аны гамәлгә ашырдык. Һәм менә йомгаклау чарасында 10 нчы сыйныф метрологиягә үз мөнәсәбәтен бик иҗади рәвештә күрсәтте. Димәк, бу укучыларның күңеленә нәрсәдер кереп калды. Балалар югары уку йортын сайлаганда инженерлык юнәлешенә өстенлек бирәчәкбез, диделәр. Алга таба язмыш кайларга илтер, әмма без аларны начар нәрсәгә өйрәтмибез.

Ольга Юрьевна Сладовская, «Д. И. Менделеев исемендәге БМФТИ» ФДУП филиалы – ВНИИР гыйльми секретаре, техник фәннәр кандидаты:

– Безне үз гаиләсенә кабул иткәне һәм метрология кластеры булдыру идеясен хуплаганы өчен лицейга рәхмәт. Балалар кызыксынып киттеләр, барысы да барып чыкты. Бишенче сыйныф укучылары белән дә эшне дәвам итәчәкбез. Без алар белән дүртенче сыйныфта бераз гына эшләп карадык, хәтта кечерәк сыйныфларга да бу юнәлеш кызыклырак булуын аңладык, югары сыйныф укучылары белән чагыштырганда, аларның күзләре күбрәк яна.

Ирина Юрьевна Николахина, башлангыч сыйныф укытучысы:

– Иң беренче бурычыбыз – баланың мәктәпне яратуына ирешү. Чөнки алар иртәнге сигездән кичке алтыга кадәр лицейда: монда дәресләр дә, бассейн да, түгәрәкләр дә, секцияләр дә бар. Алар үзләрен өйдәге кебек хис итсен дип тырышабыз: иркәлибез дә, ачуланабыз да, кирәккәндә, кочаклап та алабыз... Мин үзем дә бу лицейга эләгүемә шатмын. Оныгым да биредә укый.

Марина Валериевна Успенская, укытучы-методист, инженерлык сыйныфлары кураторы:

– Лицейда сигез инженерлык сыйныфы бар, шуларның җидесе – башлангыч мәктәптә. Иртәнге якта балаларга гомуми белем бирү дәресләре куелган. Аннары алар йоклыйлар, ял итәләр, аннары кейслар буенча шөгыльләнәләр. Балалар монда яши дип әйтергә була. Аларның шәхси шкафлары да, киемнәре дә, яраткан китаплары да бар. Йоклап торганнан соң, мәктәп буйлап пижамада йөрергә дә мөмкиннәр. Алай да була кайчак. Шуңа алар балалар бит инде.

Ә менә олылар үз мәктәпләрен ничек искә ала соң? Дәресләрне түгел, ә нинди дер чаралар, походлар, бәйрәмнәрне, ягъни укытучылар һәм ата-аналар тудырган атмосфераны. Һәм укытучылар, балалар һәм ата-аналарның берләшеп эшләве безнең лицейны тату бер гаилә итә дә.

Ильмира Радик кызы Фәйзуллина, башлангыч сыйныф укытучысы:

– Эшкә килгәндә, яшь белгеч буларак, куркуларым шактый иде: беренче дәресләрем ничек узар, укучыларым, коллегаларым белән ничек аралашырмын... Әмма миңа юлымда искиткеч остаз – Марина Валериевна очрады, ул тәүлекнең теләсә кайсы вакытында ярдәм итә. Без аның кызлары кебек, ул үзе дә безне яратып «кызымки» дип атый.

Балалар мәктәпкә бик рәхәтләнеп йөри. Мин үзем дә иртән эшемә, хәзер укучыларымны күрәм, дип ашыгам...

Гөлфия Радик кызы Гыйльманова, тәрбия эше буенча директор урынбасары:

– Бу лицейда нәкъ өч ел эшлим. Өч ел яшим дә. Чөнки лицей минем өчен икенче гаилә. Беренчеләрдән булып килеп, иң соңыннан китәм. Эшем бик күп. Бу куркынычсызлык мәсьәләләре дә, мәдәни, рухи-әхлакый тәрбия дә, патриотизм да, тәртипкә кагылышлы сораулар да... Шатлык та, кайгы да – барысы да минем аша уза.

Чулпан Шамил кызы Насыйбуллина, Өстәмә белем бирү үзәге җитәкчесе:

– Мин биредә үземне бик уңайлы хис итәм. Бу минем икенче йортым. Олы кызым да монда белем ала, икенче кызым сентябрьдә беренче сыйныфка барачак.

Ата-ананың төп максаты – баланы үстерү. Көннең икенче яртысында алар сайланган юнәлеш буенча шөгыльләнә. Бездә 6 юнәлеш эшли: гуманитар, табигать фәннәре, социаль, техник, туристлык-туган якны өйрәнү һәм спорт. Бик күп түгәрәкләргә йөрергә тәкъдим итәбез! Бездә 27 төр берләшмә ачылган, аларда өстәмә белем бирүнең берничә төркеме бар. Әти-әниләр дә, балалар да бик канәгать, беркая да барырга кирәкми, барысы да монда, лицейда, күзәтү астында эшли.

СҮНМӘС ЙОЛДЫЗЛАР

Ксения Сёмина

Казандагы 187 нче «Ритм» күп профильле лицеенда «Совет районы мәгарифе» музее ачылды. Музей буйлап виртуаль экскурсиябездә сез педагогларның шәһәребез, республикабыз, илебезнең бүгенгесен һәм киләчәген ничек итеп тәрбияләве белән танышырсыз.

БИРЕДӘ САМОЛЕТЛАРНЫ ОЧАРГА ӨЙРӘТӘЛӘР

«Хезмәт тәрбиясе» стенды

Роботның йөкне автоном илтеп тапшыруы өчен система кодын проектлаштырырга һәм язарга кирәкме? Бик җиңел бирем бу! Россиянең иң абруйлы чемпионатында югары уку йортлары командалары белән беррәттән дрон-рейсинг үтәргәме? Бик рәхәтләнеп! Казанның Совет районы өлкән сыйныф лицейчылары үзләренең инженерлык күнекмәләре буенча бик еш көч сынаша һәм ил күләмендәге ярышларда җиңә. Аларның әзерлеге бүгенге иң алдынгы технологияләргә җавап бирә, илебез сәнәгатенең киләчәге алар кулында. Болар барысы да ул чакта укыту-җитештерү комбинаты белән җитәкчелек иткән Гөлсинә Шәфигуллина инициативасы белән 90 нчы елларда республикада беренчеләрдән булып эшләтеп җибәрелгән профориентация программаларыннан да башлана. 2014 елда һөнәри әзерлек традицияләрен 110 нчы лицейда дәвам итәләр – анда WorldSkills чемпионатына күнекмәләр үткәрү базасы булдыралар. Аннары Венера Хәйретдинова җитәкләгән Лицей-инженерлык үзәге трендны эләктереп ала һәм яңа дәрәҗәгә күтәрә. Аның җитәкчелегендә эшләгән Гөлнара Галиева, үз чиратында «Ритм» лицее директоры итеп билгеләнгәч, инженерлык белеме традицияләрен 187 нче лицей программасына кертеп җибәрә. Лицей-инженерлык үзәгендә һәм «Ритм»да хәзер самолетларны гына түгел, иң заманча лазер двигателенә ия космик иярченнәрне дә очарга өйрәтәләр.

Фотолар «Совет районы мәгарифе» музееннан алынды

187 НЧЕ ЛИЦЕЙ БАЗАСЫНДА ЕЛ САЕН «ТЕЛ САГЫНДА – ИР-ЕГЕТЛӘР» ПЕДАГОГИК УЕН-БӘЙГЕСЕ ҮТКӘРЕЛӘ.

ТЕЛЕН БЕЛГӘН ИЛ АЧАР
«Милли мәгариф» стенды

2000 нче еллар уртасында республикада рус телле төркемнәрдә татар теленә өйрәтүнең нәтиҗәлелеге хакында уйлана башлыйлар. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы педагогларга татар телен чит тел буларак укыту системасын булдыруны йөкли. Әлеге бурычны составына 141 нче гимназиянең татар теле укытучысы Фирая Фәизова да кергән авторлар коллективы башкарып чыга. Педагоглар материалларның тулы бер комплексын булдыра: дәреслек, укытучы өчен кулланма, дәрес планнары, тестлар, өй эше дәфтәрләре һәм аудиокассеталар ярдәмендә дәрес үткәрү бик ансатлаша. Бүген инде Фирая Сафа кызы пенсиядә, әмма ул да эшләшкән тиңдәшсез укыту-методика комплекты республика мәктәпләренең кайберләрендә һаман кулланыла әле. Татар телен укытуга актив, иҗади, җаваплы якын килү – Совет районы педагогларының визит карточкасы ул. Тел дәресләренең башка фәннәр белән көндәшлеге шартларында алар укытуның лаеклы дәрәҗәсен саклый, һөнәри бәйгеләрдә җиңә, грантлар ота, фәннигамәли конференцияләрдә катнаша. Һәм яңа йолдызлар кабыза – аларның укучылары арасында татар теле һәм әдәбияты буенча олимпиаданың республика этабы җиңүчеләре артканнан-арта бара.

УҢЫШ МУЗЫКАСЫ
«Өстәмә белем бирү» стенды

Районда өстәмә белем бирә торган 13 учреждениенең һәркайсының үзенчәлеге бар. «Дәрвишләр» үзәгендә сәламәтлеге чикле балалар өчен түгәрәкләр эшли, «Танкодром»да хәрби-патриотик һәм экологик тәрбия белән шөгыльләнәләр, «Балалар академиясе»ндә хореография һәм вокал укыталар. Моның никадәр кирәкле һәм мөһим эш булуы хакында анда йөрүчеләрнең күплеге үзе сөйли: район балаларының өчтән бере диярлек өстәмә белем ала. Моның сере нәрсәдә икән соң?

– Бүген креатив фикерләү, аралашу осталыгы, иҗади якын килү һәм системалылык югары бәяләнә. Өстәмә, шул исәптән музыкаль белем бирү исә нәкъ менә шул сәләтләрне үстерүгә булыша. Ата-аналар моны яхшы аңлый, балалар исә сөенеп яңа белем ала, – ди 21 нче балалар музыка мәктәбе директоры Анна Смирнова. Аның 14 укучысы Казан мэрының исемле стипендиясенә лаек булган, бу шәһәр буенча иң югары күрсәткечләрнең берсе.

– Безнең тәҗрибә шуны күрсәтә: әгәр педагогка эшләве рәхәт икән, ул таулар күчерергә һәм теләсә нинди кыенлыкларны җиңеп чыгарга әзер, – ди Анна Смирнова. – Укытучы – бәхетле һөнәр ул, чөнки тормышта бала белән аралашудан да рәхәтрәк һәм рәхмәтлерәк нәрсә юк.

РОМАН ФӘТХЕТДИНОВ, Казанның Совет районы хакимияте башлыгы:

– Безнең балаларда мөгаллим һәм остазларга хөрмәт тәрбияләү бик мөһим. Музей экспонатлар һәм яңадан-яңа тарихлар белән гел тулыланып торачак әле! Районыбыз үсә, яшәрә. Балалар саны арта, мәгариф оешмаларының җитәрлек булуы, белем бирү сыйфатының гел яхшыра баруы таләп ителә. Мәгълүматка бик бай һәм актив ритмлы заманыбызда укытучы, әлбәттә инде, трендлардан калышмаска һәм яшьләр белән бер дулкында булырга, шул ук вакытта, үз тәҗрибәсен һәм дөрес кыйммәтләрне сеңдереп, үсеп килүче буынны якларга һәм тәрбияләргә дә тиеш.

СОВЕТ РАЙОНЫНЫҢ МЕТОДИКА КАБИНЕТЫ РӘСМИ РӘВЕШТӘ РЕСПУБЛИКАДА ИҢ ЯХШЫЛАРДАН САНАЛА. БУ – МЕТОДИК ЭШНЕҢ ЯҢА ФОРМАЛАРЫ ТУА, ЯҢА ПЕДАГОГИК ТЕХНОЛОГИЯЛӘР, АВТОРЛЫК ПРОГРАММАЛАРЫ ӨЙРӘНЕЛӘ, ЯҢА ПРОЕКТЛАР БУЛДЫРЫЛА ТОРГАН ИҖАТ ҮЗӘГЕ.

КЕШЕЛЕКЛЕЛЕК ДӘРЕСЕ

«Профсоюзлар» стенды

Киң Идел, ярлардагы искиткеч матур табигать күренешләре, Чебоксар белән Түбән Новгородта тукталыш һәм экскурсияләр. Көндез – осталык дәресләре, кичен – концерт, биюләр. Һәм, әлбәттә инде, бик күп рәхәт аралашу, бусы пенсионерларга аеруча кадерле. Мондый елга круизлары – Совет районы педагоглары профсоюзы өчен традиция. Аларны һәм ветераннар өчен башка бик күп чараларны оештыру белән Гомумроссия мәгариф профсоюзлары Татарстан республика оешмасының район бүлеге рәисе, музейны төзүчеләрдән берсе Венера Нуриева шөгыльләнә. Район мәктәпләре арасында дустанә мөнәсәбәт булдыру, җылы иҗади мохит тудыру – педагогларны һөнәри талчыгудан саклауның бер ысулы. Венера Нурмөхәммәт кызы һәркемнең кадерен белә. 1990–2000 елларда ул Совет районы мәгариф бүлеген җитәкләгән, һәм нәкъ менә аның тырышлыгы белән район мәктәпләренә искиткеч директорлар билгеләнгән. Аларның исемнәре бүген республикада яхшы мәгълүм – хәзер инде педагог буларак кына түгел, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклеләре сыйфатында да.

ВАТАНПӘРВӘРЛЕК – ГАМӘЛ УЛ

«Алар Ватан өчен сугышты» һәм «Хәрби-патриотик тәрбия» стендлары

Районнан Бөек Ватан сугышы фронтларына китүче укытучыларның нибары 17 се генә кире әйләнеп кайта алган. Һәм алар мәгариф фронтында эшләвен дәвам иткән.

– 1940 нчы елларда Татарстан мәктәпләре эшләүдән туктамаган. Көнне төнгә ялгап фронт өчен эшләгән кырыс тыл шартларында укыту һәм балаларны якты киләчәккә рухландыру – кешелеклелек үрнәге һәм һөнәри батырлык ул, – ди музейны оештыручылардан берсе һәм аның директоры Альберт Газизов.

Татарстан фронтовикларының исемнәре онытылмый: республиканың Бөек Ватан сугышында катнашуы турында Совет районының берничә мәктәбе һәм лицеенда ачылган кадет сыйныфларында, шулай ук яшь армиячеләр өчен чараларда сөйлиләр.

– Безнең мәктәп этнография музеенда Бөек Ватан сугышына бәйле экспонатлар бар, мәсәлән, бер солдатның Казандагы әнисенә язган хаты. Бу чын реликвия. Башлангыч сыйныфлар өчен музейдагы тарих дәресләрен без үзебез үткәрәбез, – дип сөйли Казанның 110 нчы лицееның 11 нче сыйныф укучысы һәм мәктәпнең президенты Артем Горностаев. – Минем өчен ватанпәрвәрлек – нәрсәнедер яхшы якка үзгәртү омтылышы, мәктәп, район, ил үсешенә үз өлешемне кертү ул.

МУЗЕЙНЫ ОЕШТЫРУ – УРТАК ЭШ. ЭКСПОНАТЛАРНЫ ПЕДАГОГЛАР, «РИТМ» КУНАКЛАРЫ, УКУЧЫЛАРНЫҢ АТА-АНАЛАРЫ БҮЛӘК ИТӘ. СТЕНДЛАРНЫ БАСТЫРУНЫ ДА БЕР УКУЧЫНЫҢ ӘТИСЕ АЛЕКСЕЙ КОСТЫЛЕВ ОЕШТЫРГАН. МУЗЕЙ ТОРМЫШЫНДА БАЛАЛАР ДА КАТНАША. ӘЙТИК, УНБЕРЕНЧЕ СЫЙНЫФ УКУЧЫСЫ ТИМУР ВӘГЫЙЗОВ КАЗАН МЭРЫНЫҢ 100 МЕҢ СУМЛЫК ГРАНТЫН ОТКАН ҺӘМ АНЫ МУЗЕЙ ХАҖӘТЛӘРЕНӘ ТАПШЫРГАН.

ГӨЛСИНӘ ШӘФИГУЛЛИНА,
Казанның Совет районы ветеран педагоглары советы рәисе, музейны оештыручылардан берсе:

– Мин Совет районы мәгариф системасына 1984 елда килдем һәм 34 елдан артык эшләдем. Бездә йолдызлар шулкадәр күп иде! Район мәктәпләре һәм укучылары өчен күп яхшылык эшләүчеләрнең һәркайсының исемен кадерләп саклыйсы килә. Димәк, безнең эш башлана гына әле. Планда – музейны интерактив итү, аның онлайн-ресурсларында директорлар, аларның урынбасарлары, укытучылар турында мөмкин кадәр күбрәк мәгълүмат урнаштыру.

КАПИТАННАР ҺӘМ АЛАРНЫҢ КОМАНДАСЫ

«Директорлар» стенды

Узган гасырның 90 нчы елларында илдәге икътисадый һәм сәяси кризис чорында укытучыларга айлар буе хезмәт хакы түләнми, шунлыктан директорның иң төп бурычларыннан берсе педагогик коллективны саклап калу була. Чын топ-менеджерлар кебек, белем бирү оешмалары җитәкчеләре ул чакта хәйриячеләр эзли, мәктәпне ничек тә саклап калырга тырыша. Хәзер инде мондый проблемалар юк. Әмма бурычларның мөһимлеге һәм күплеге, югары дәрәҗәдәге җаваплылык мәктәп директорларыннан бүген дә квалификацияле педагог та, компетентлы җитәкче дә булуны таләп итә. Мондый белгеч булып җитешү өчен буыннарның тәҗрибә алмашуы зур әһәмияткә ия.

– Безнең район директорларының бердәм команда булуы бик шәп. Алар тату, бер-берсенә ярдәм итәргә һәрвакыт әзер. Биредә сөенечләр дә, хәсрәтләр дә уртак. Мондый җылы, кешелекле мөнәсәбәтләр – лаеклы алмаш тәрбияләүнең нигезе ул, – ди Совет районы мәгариф бүлеге мөдире Эльмира Арысланова. – Райондагы күп мәктәпләрнең бүген дә уңышлы булу сере алдагы буын директорларыннан калган идарә итү традицияләренең һаман саклануында. Үзебезнең очрашуларга без ветераннарны да чакырабыз, алар үз мәктәпләренең уңышларына сөенеп кенә калмый, катлаулы хәлләрдә киңәш белән дә булыша ала.

ГӨЛНАРА ГАЛИЕВА,
Казанның Совет районы 187 нче («Ритм») күп профильле лицее директоры:

– Безнең лицей – райондагы иң яңа мәгариф оешмаларыннан берсе, һәм шуңа күрә без баштан ук белем бирүнең иң яхшы традицияләренә нигезләнергә ниятләдек. Татарстан Республикасы территориясендәге мәгърифәт һәм мәгариф тарихына багышланган музей проекты – «Ритм» төзелгән концепциянең бер өлеше. 2023 елда Татарстан Милли музее гыйльми хезмәткәрләренең махсус безнең өчен әзерләнгән проекты буенча «Музей аллеясен» ачтык, ул Идел буе Болгарстаныннан башлап республикабыз территориясендә булган мәгариф системалары тарихы белән таныштыра. «Совет районы мәгарифе» музее – әлеге инициативаның дәвамы. Экспозиция 1930 нчы еллардан башлап безнең көннәргә кадәрге тарихны колачлый. Экспонатларның бер өлешен 175 нче гимназия тапшырды, үз вакытында анда да шундый музей булдырылган иде. Музей концепциясен гамәлгә кертүнең өченче этабында «Ритм»да күренекле татар композиторы Нәҗип Җиһановка багышланган экспозиция ачылачак, чөнки безнең лицей нәкъ Җиһанов урамында урнашкан.

СОҢГЫ СҮЗ УРЫНЫНА

Визуаль материалдан тыш, музейда татарстанлыларның 50–60 нчы, 70–80 нче, 90 нчы, 2000 нче еллардагы мәгарифе һәм көнкүрешенә бәйле экспонатлар, әйберләр дә күп. Зал уртасына иң борынгы экспонатларның берсе – агач парта куелган. Анда утырып укучылардан соң укытучы һәм укучыларның әллә ничә буыны алмашынган инде. Уку процессы да тамырдан үзгәрде һәм үзгәрүен дәвам итә. Әмма «Ритм»дагы музей үткән дәвер, бүгенге көн һәм киләчәкне бер идея белән берләштерә. Яхшы белем бирү педагогның үз эшен һәм үз укучыларын яратуына нигезләнә. Ә ярату исә беркайчан да онытылмый.

СОВЕТ РАЙОНЫНДА БЕРЕНЧЕ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ 1989 ЕЛДА АЧЫЛГАН, БҮГЕН ИСӘ БИРЕДӘ БАРЛЫГЫ 85 МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ ИСӘПЛӘНӘ.

УЕННАР ИМИНЛЕГЕ САГЫНДА

Июнь аенда Казанда БРИКС Уеннары узачак, аңа дөньяның 60 иленнән спортчылар чакырылган. Уеннарның спорт программасы (0+) БРИКС илләрендә иң популяр 29 спорт төрен үз эченә ала. Турнирда иминлекне тәэмин итәчәк предприятиеләр исемлегендә Казанның «Контр-Юниверсити 2» сак компанияләре төркеме дә бар.

– БРИКС Уеннары, һичшиксез, белебездә бу җәйнең иң колачлы спорт чарасы булачак, – дип белдерде РФ Хөкүмәте Рәисе урынбасары Дмитрий Чернышенко. – 14 көн дәвамында Казанда 4,5 меңнән артык спортчы үз төрендә көч сынашачак.

Ярышларны карарга бөтен Россиядән һәм чит илләрдән 100 меңнәрчә тамашачы киләчәк. Ярышларда 18 спорт объекты, шулай ук дистәләгән кунакханә эшкә җигеләчәк.

Катлаулы халыкара вазгыять шартларында спортчыларның һәм тамашачыларның иминлеген тәэмин итү мәсьәләсе беренче урынга куела. «Контр-Юниверсити 2» компанияләр төркеме бу мөһим миссия ышанып тапшырылган ширкәтләр исемлегенә керә. Ул сак хезмәтләре күрсәтү белән 2010 елдан бирле шөгыльләнә һәм бүген Татарстан белән Удмуртиядә бу тармакта алдынгы компанияләр сафында йөри. Йөкләрне озата бару, предприятиеләрне һәм шәхси затларны саклау бөтен Россия киңлекләрендә алып барыла.

БРИКС Уеннары объектларын саклау мәсьәләләре белән предприятиедә Руслан Җамалиев шөгыльләнә. Аның тәҗрибәсе хәттин ашкан: төрле объектларның иминлеген тәэмин итү юнәлешендә 10 елдан артык хезмәт куя. Ул мәгариф учреждениеләрен, муниципаль оешмаларны, сәнәгать предприятиеләрен, спорт инфраструктура объектларын саклау эшен оештыра.

– БРИКС Уеннарында рәсми һәм спорт чараларының иминлеген тәэмин итүдә катнашу безнең өчен яхшы тәҗрибә булып тора, – дип билгеләп үтә Руслан Рамил улы. – Беренчедән, мондый зур вакыйгада эшләү үзенчә кызыклы. Югары дәрәҗәдә сак хезмәте күрсәтү өчен барлык көчосталыгыбызны мизгел эчендә бергә туплап эш йөртү таләп ителә.

Казан илнең спорт башкаласы исемен хаклы рәвештә йөртә. Тиздән узачак БРИКС Уеннары – моның тагын бер дәлиле. Үз чиратында җаваплылык та югары. Спорт объектларын саклау, ярышлар вакытында тамашачылар һәм спортчыларның иминлеген тәэмин итү – төп бурыч. «Контр-Юниверсити 2» – бу бурычны уңышлы хәл итү ышанып тапшырылган ширкәтләрнең берсе. Бу эш аукцион нәтиҗәләре буенча төзелгән дәүләт һәм муниципаль контрактлар кысаларында, шулай ук заказчылар белән турыдан-туры контрактлар һәм килешүләр нигезендә тормышка ашырыла.

ФАКТЛАР

- Уңышлы эшнең иң мөһим шарты – хезмәткәрләрнең профессиональлеге, дип саныйлар «Контр-Юниверсити 2» ширкәтендә. Сакчылар Сак эшчәнлеге белән шөгыльләнү өчен рөхсәт лицензиясе алу, квалификация имтиханнарын тапшыру белән бергә сакчылар утлы корал куллану шартларында даими тикшерүләр дә узалар. Мондый имтиханнар билгеле бер ешлыкта оештырылып тора. «Контр-Юниверсити 2» үз хезмәткәрләрен пилотсыз очу аппратлары белән көрәшкә дә өйрәткән.
- Сак предприятиесе заказчылары исемлегендә РФ нефть эшкәртү һәм нефть чыгару тармакларының әйдәп баручы предприятиеләре, спорт һәм мәгариф учреждениеләре, төзелеш, авыл хуҗалыгы, сәнәгать компанияләре, хакимият органнары бар.
- Предприятие хезмәткәрләре төрле концертларны, күчмә тамашаларны саклау, иң югары вазыйфаларны биләүче рәсми затларны, артистларны һәм башка танылган шәхесләрне озатып йөрү белән дә шөгыльләнә. «Контр-Юниверсити 2» компанияләр төркеме БРИКС Уеннары объектларының бер өлешендә иминлекне тәэмин итү бурычын үтәргә дә алына.

Фотография «Контр-Юниверсити 2» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

игелекле эшләр

акыллы гамәлләр

мәңгелек кыйммәтләр /

Бу санда тәкъдим итәбез:

Сугыш турындагы фильмнар **ни өчен** кирәк

Чегән гипнозына **ничек** эләкмәскә

Чистайның мәшһүр ишаны **кем** булган

Гомәр Галине **нинди** фаҗигале язмыш көткән

Иске Камка авылында **нигә** чишмәләр күп



«Татарстан» журналының махсус проекты

«ТАТАРСТАН» ТАРИХЛАРЫ

Тирә-юньдә кызыклы хәлләр булып тора. Алар безне һәр яклап урап алган. Төрле почмаклардан, иске сандык төпләреннән, фотосурәтләрдән, өебездәге өстәл өсләреннән безгә карап торалар сыман. Аклы-каралы фотосурәтләр, антресольдә тузанланып яткан кадерле әйберләр, кулдан ясалган уенчыклар, архивта, хатлар арасында игътибарыбызны көткән документлар безгә әллә нинди кызыклы яңалыклар ачар төсле.

Чыннан да аларның барысына да ниндидер тарих, кызыклы хәл яшеренгән. Хәтта кайберләренең тарихы әдәби әсәр сюжетларыннан да катлаулырактыр. Ләкин һәрвакыт кызык. Еш кына гыйбрәтле. Кайвакыт бик соклангыч. Уйларга-уйланырга һәм хәтта фикер сөрешен үзгәртергә мәҗбүр итәрлек…

Бары тик аларны күрергә, ишетергә, тыңларга, язарга кирәк. Бүген сезгә шундый тарихлар турында берничә бәян тәкъдим итәбез.

1. ТӘҮГЕ ШЕФ*

беренче эшкә урнашу хакында инде онытыла язган тарих

2. «ЗАБЫТЫЕ»*

күптәнге бер сугыш турында документаль-уен фильмы тарихы

3. ТАНИТА

чын чегән кызының искиткеч тарихы

*«Онытылганнар»

ТӘҮГЕ ШЕФ

беренче эшкә урнашу хакында инде онытыла язган тарих

Татьяна Челышева

Югары уку йортларын хәзер тәмамлаучылар эшкә мәҗбүри бүленешнең нәрсә икәнен белми дә торгандыр инде. Бу хәл соңгы тапкыр үткән гасырда, 1992 елда булган иде. Ул чакта без – Казан университетының журналистика факультетын тәмамлаган дүрт кеше – мәҗбүри бүленеш буенча Яр Чаллыга, яңа гына ачылган телерадиотапшырулар редакциясенә килеп эләктек.

Анда безне телерадиокомпания директоры Рахман Галим улы Шәфигуллин үз туганнарына сөенгәндәй кочак җәеп каршы алды. Чаллы мэры белән таныштырды, шәһәр буйлап экскурсия үткәрде – һәм шуннан көн төнгә ялганды! Радиода да, телевидениедә дә, гомумән өлкәннәр тормышында да бернәрсә аңламаган кечкенә студентларны кырларга, абруйлы түрәләр кабинетларына, туры эфирларга, рейдларга җибәрделәр... Тормыш кызыклы эш һәм мәгънә белән тулды – без беренче идек, без шәһәр телерадиотапшыруларын иң беренче булып оештырдык. Шуннан бирле 32 ел вакыт сиздерми генә үткән дә киткән икән!

ТИЗ ҺӘМ ДӨРЕС

– Тиз һәм дөрес булсын! – дип өйрәтә башлады беренче эш көненнән үк үз корреспондентларын Рахман Галим улы. Һәм «Чаллы-ТВ» телекомпаниясе бүген дә шул сыйфатларына тугры.

– Шәһәр тормышы сюжетларга гаять бай ул, – дип тә ышандырды ул безне. Һәм без, микрофоннарыбызны һәм бик авыр «Репортер» аппаратын асып, йә вокзалга, йә дачаларга, йә КАМАЗ тулай торакларына юнәлә һәм һәркайда үз тапшыруларыбыз өчен кызыклы сюжетлар таба идек.

– Буш кайтмагыз! – дип куркыта иде ул безне. Һәм без юлыбызда очраган бөтен нәрсәдән кызык табарга өйрәндек. Мәсәлән, чеган таборында эни турында моңлы җыр сузуларын төшергән идек, искиткеч сюжет килеп чыкты – аңардан соң шәһәр халкы сукбайларга мәрхәмәтлерәк була башлады.

ӨЧ ҮЛЧӘМЛЕ КРЕДО

– Безнең кредо өч үлчәмле, – дип кабатларга ярата иде Рахман Галим улы, әлеге фикерне безнең яшь башларга сеңдерергә тырышып. – Мәгълүмат бирү, мәгърифәт чәчү һәм күңел ачтыру. Әмма күңел ачтыру эчтәлексез һәм мәгънәсез түгел, ә тәрбияви булырга тиеш. Шуларны үтәсәгез, телевидениенең югары модасына тәңгәл киләчәксез.

Һәм без тәңгәл килергә тырыша идек – үз телевидениебезне булдырдык, ә телевидение безнең үзебезне камиллэштерде.

ГОМЕР ҮТӘ...

Хәзер инде ул вакыттагы яшь журналистларның узган гасырның 90 нчы елларындагы аклы-каралы фотолардагыдай ихлас күзләре

Фото Рахман Шәфигуллин архивыннан

генә үзгәрми калган, җыерчыклар һәм тәҗрибә исә шактый өстәлгән... Безнең һәркайсыбызның үз гаиләсе, балалары, оныклары бар... Һәркайсыбыз төрле гаммәви мәгълүмат чараларында – газета, журнал, телевидение, радио редакцияләрендә эшләп чарланган... Хәзер инде үзебез дә, аксакаллардай, студентларны эшкә өйрәтәбез, ә инде алар бик юньсез булып тоела башласа, узган гасырдагы үзебезне, бик тә сабыр остазыбыз Рахман Галим улы Шәфигуллинны искә төшерәбез дә, «аксакалларча» тәкәбберлегебез шундук юкка чыга.

ИКЕЛӘТӘ БУРЫЧ

Ул чакта Рахман Шәфигуллинга икеләтә бурыч йөкләнә – беренче шәһәр телерадиокомпаниясен оештыру һәм әлеге компаниядә эшләүчеләрнең үзләрен дә профессионалга әйләндерү. Ул әлеге максатларның икесенә дә ирешә. Телерадиокомпания белән без параллель үстек. Соңыннан тормышыбызда нинди генә хәлләр булмасын, анда эшләгән вакытыбыз хәтеребезгә мәңгегә уелды.

«МИНЕМ ШӘХСИ БАТЫРЛЫГЫМ»

– Минем журналистикага юлым озын һәм катлаулы булды, – дип искә ала Рахман Галим улы.

Һәм, аның язмыш сикәлтәләре белән тулырак танышкан саен, үзебезгә ничек уңай туры килгәненә сөенергә генә кала: без шундук яхшы кешегә һәм яхшы шартларга килеп эләктек бит, бары тик иҗат ит кенә, башка барысын да – аппаратура юнәтүдән алып компаниянең статусын яклауга кадәр бөтен нәрсәне – җитәкчебез эшләгән булып чыга.

– Һәр кешенең тормышында аеруча илһамланып, рухланып, бөтен җанын биреп башкара торган эше була, – ди Рахман Галим улы. – Минем гомерем исә – Яр Чаллыда телерадиокомпания оештыруга бәйле иксез-чиксез мәшәкатьләр ул. Мактанып әйтүем түгел: үз вакыты өчен бу чын батырлык иде. Идеяне әйтүе генә җиңел бит аны, ә тормышка ашыра башлагач, меңнәрчә каршылык пәйда була! Әмма инде эшкә алынгансың икән – ничек тә үтә! Тормыш шулай өйрәтә. Миңа һәр адымымда үземне аңлаучылар, ярдәм кулы сузучылар очрап торды, аларга рәхмәтем чиксез.

«ВОРКУТАНЫ ОНЫТМАМ!»

– Шәхсән минем тарих ерак Воркутадан башланды, – дип исенә төшерә Рахман Галим улы. – 15 яшемдә абыем янына килдем. Техниклар мәктәбендә белем алдым, электр слесаре һөнәрен үзләштердем. Дүрт ел «Воркутауголь» комбинатында эшләдем.

Тулай торакта яшәдек. Кемнәр генә юк иде анда! Халык илнең төрле төбәкләреннән җыелган иде... Төрле милләт вәкилләре белән якыннан аралашу минем фикер-карашларыма, әйләнә-тирәдәгеләргә мөнәсәбәтемә гаять зур йогынты ясады, бу чын тормыш мәктәбенә әйләнде. Гаепсез сөрелгәннәрнең ачы язмышы белән танышу журналист һөнәрен сайлауга этәргеч булды. Анда, «Молодежь Севера» газетасы каршындагы яшь хәбәрчеләр мәктәбендә, мин беренче журналистлык белемемне алдым. Мәкаләләрем кече ватанымда – «Татарстан яшьләре» газетасында, Балык Бистәсенең «Октябрь юлы» район газетасында, «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә») журналында басылды.

МИНА КУЮЧЫДАН – ХӘБӘРЧЕГӘ

1969 елның көзендә Рахман Шәфигуллин Совет Армиясе сафларына чакырыла. Ерак Көнчыгышта 1113 нче аерым саперлар батальонында мина куючы, соңрак 192 нче мотоукчылар дивизиясенең «Во славу Родины» газетасында хәрби корреспондент була. Армиядән соң өлкән сержант Шәфигуллин Балык Бистәсенең «Октябрь юлы» район газетасына хәбәрче булып урнаша. Казан дәүләт университетының журналистика факультетына укырга керә, аннары Ленинград югары партия мәктәбендә укый. «Леннаучфильм» киностудиясендә өч ел электрик булып эшләү дәверендә фильмнар төшерергә өйрәнә, монтаж серләренә төшенә. Укуын тәмамлагач, гаиләсе белән Яр Чаллыга кайта.

ЧУЛМАНДАГЫ ЯШЬ КАЛА

– Бу Чулмандагы яшь каланың гөрләп үскән чагы иде. КАМАЗ үзе генә дә ни тора! – дип сокланып тасвирлый Рахман Галим улы яшьлеге шәһәрен. – Һәм без әлеге куәтле агымга килеп кушылдык. Автокалада илнең төрле төбәкләреннән килгән яшьләр күп иде.

Җиде ел «Якты юл» газетасында эшләгәннән соң мине Телевидение һәм радиотапшырулар буенча ТАССР дәүләт комитетының Яр Чаллыдагы корпункты җитәкчесе итеп куйдылар. Җирле яңалыклар республика матбугатында тиз арада һәм тиешенчә яктыртылсын өчен, КАМАЗ янәшәсендәге районнардан тәүлек буе кайтып кермәскә кирәк иде. Эфир вакыты чикле булганга, иң мөһим вакыйгаларны гына сайлап бирергә туры килде. Мин беркайчан да гайбәт эзләмәдем. Без гел позитив юнәлештә эшләдек...

ЗАМАНАДАН КАЛЫШМЫЙЧА

Мин илдәге барлык тарихи чорларны һәм ТАССРдагы үзгәрешләр дәверен Чаллы телевидениесе белән бергә үттем. 1990 нчы еллардагы СССР таркалу сәясәте төбәкләрдә киеренкелек тудырды. Боларның барысын да халыкка аңлатырга кирәк иде. Ә ничек итеп?

Халыкка мәгълүмат җиткерү өчен газета-журналлар, радио һәм телевидение булу зарур. Дөресен әйткәндә, әлеге тармакта эшләүче белгечләр булмаганга, ул чакта телерадиокомпания оештыру хакында уйлаучы да юк иде.

Мин Яр Чаллыда телерадиокомпания оештыру белән актив шөгыльләнә башладым. Оештыру-техник чаралар, штат туплау, кирәкле аппаратура сатып алу планнары, чыгымнарны исәпләгән һәм башка документлар белән мин шәһәр җитәкчелеген таныштырдым, әмма алар тарафыннан кызыксыну сизмәдем.

Бары тик 1990 елның июлендә генә комиссия тәкъдиме буенча президиум утырышында «Чаллы төбәк эфир телевидениесен оештыру турында» карар кабул ителде.

1992 елның 15 апрелендә мин сессиянең көн тәртибенә «Яр Чаллы шәһәр советы һәм хакимиятенең телевидение һәм радио редакциясен оештыру турында» тәкъдим керттем. Мине хупладылар. Ул чакта илдә әле бер генә муниципаль телерадиокомпания дә юк иде.

Бу яңалык та, минем шәхси батырлыгым да булды. Әмма нинди дер карар нигезендә генә федераль каналда кушымта эшләтеп җибәрүгә кем рөхсәт бирер соң? Әлбәттә инде, Татарстан Президенты. Мин әлеге проблеманың уңай хәл ителәсенә ышандым. Моның кирәкле һәм игелекле эш булуын аңлауларына ихластан ышана идем.

Яр Чаллыдагы ретранслятор республикага буйсына. Казан Россия Элемтә министрлыгына буйсына. Мин Мәскәү – Казан юлын таптарга керештем.

Чаллы телерадиокомпаниясенең эше дә үткәргечле радиодан башланды. Безгә мэриянең беренче катындагы китапханә бинасын бирделәр. Төзелеш кайнаганда, без яңалыкларны «Идел» магнитофонына яздырып, аларны 4 нче комплексның элемтә бүлегеннән халыкка җиткерә идек... Радиостудия монтажчылары булып Гүзәлия Сәлахова, Наил Ягъфәров, Земфира Бәширова эшләде. Зөлфия Хисмәтуллина, Әнисә Курамшина, Җәүдәт Әхмәтов һәм Земфира Хәсәнова диктор-журналист вазыйфаларын башкарды. Казан университетын яңа гына тәмамлаган журналистлар Лилия Сәлахиева, Татьяна Челышева, Фирүзә Харрасова килеп кушылды... Әкренләп яңа стационар магнитофоннар сатып алынды, тапшырулар турыдан-туры үзебездән китә башлады...

БОЛГАНЧЫК ЕЛЛАР

Барысы да менә шулай башланды. Аннары исә без дә бөтен Чаллы халкы белән бергә туксанынчы еллар зәхмәтен кичердек – илдә тормыш бик катлауланды, автокалада вазгыять бик киеренкеләнде ул чакта. Кайчандыр КАМАЗ төзергә килүчеләр кире китә башлады. Завод-фабрикаларда, төзелеш мәйданчыкларында эш туктады. Хезмәт хакы он, сабын, аракы, төзелеш материаллары белән түләнде. Читтән товар ташучылар Чаллыны зур базарга әйләндерде. Вазгыять кискенләште.

Без радиода туры эфирлар үткәрдек. Шәһәр халкы сорауларына мэр һәм аның урынбасарлары өчәр сәгать буе җавап бирде. Көн саен! Бу эшкә милли җәмгыятьләр рәисләре җәлеп ителде – алар тынычлыкка өндәде. Радиотапшыруларга футбол буенча ил чемпионы – «КАМАЗ» командасы вәкилләре килгәндә, тыңлаучыларга аеруча ошый иде. Шуның өчен Николай Бех безгә биш репортер магнитофоны бүләк итте, бу безгә сюжетларны урамда да яздыру мөмкинлеген бирде. Балалар бакчаларында тәрбияләнүчеләрнең чыгышлары да радионың абруен арттырды. Безнең бәләкәй артистларның җырлавы йөрәкләрне җылыта иде. Чаллы радиосы каладагы 160 мең фатирда сөйләп торды.

Халык телетапшырулар да карасын өчен, VHS форматындагы видеокамера сатып алдык. «Чаллы-ТВ» дигән матур табличка пәйда булды. 1992 елның августында беренче тапшыруларны төшерү өчен студия булдырдык. Миңа исә эфирга федераль канал буенча чыгу мөмкинлеген табарга кирәк иде. Һәм мин республика радиотелевидение үзәгенә, ТР Министрлар Кабинетына чыгып киттем... Минем әлеге сәфәрләремне тасвирлау бик озакка сузылыр иде. Әмма төп нәтиҗә сөендерерлек – могҗиза булды!

ЗУР ҖИҢҮ

Бу зур җиңү иде! Радиотелевидение тапшырулары үзәге (РТПЦ) белән җирле телерадиокомпания арасында Россиядә беренче һәм соңгы килешү! Безне Яр Чаллы халкы тәүлек буе котлады. Ул чакта телевидение бик абруйлы иде әле.

Безнең беренче тапшыруларыбыз: «Итоги. Йомгак», «Ачыктан-ачык сөйләшү. Откровенный

разговор», «Энҗе бөртекләре» («Жемчужины») балалар концерты…

Безнең эшебез белән танышырга теләүчеләр саны һаман арта барды. Мэр кунакларны Яр Чаллы белән таныштыруны телестудиядән башлый иде. Ә без аларга автокала турында видеофильмнар, артистларыбызның җырларын, Сабан туе яздырылган кассеталар бүләк итәбез...

Ул чакта «Яр Чаллы» телерадиокомпаниясендә минем мәктәпне үтүчеләр бүген Мәскәү, Казан, Яр Чаллыдагы гаммәви мәгълүмат чараларында эшләвен дәвам итә...

СӨЕНЕЧ ХИСЕ

...Мин киләчәк, үсеш турында даими уйландым һәм гел алга бардым. Телевидение һәм радио өчен ешлыклар алырга кирәк иде. Бары тик яхшыга гына өметләнеп, тагын эшкә керештем.

Без алырга тиешле 51 нче канал самолет очышларына комачауламыймы, хәрби оешмаларга зыян китермиме? Боларны ачыклауга алты ай кирәк булды. Аннары тагын бер проблема туды: тапшыргычларны кайда урнаштырырга? Тагын тикшерүләр, тикшеренүләр... Ниһаять, бер елдан соң Мәскәүдә ешлыклар бирә торган конкурс комиссиясе утырышы узды. Анда миңа Яр Чаллы өчен телевидениенең бик кирәк булуын дәлилләргә туры килде. 1995 елның маена бөтен эшләр төгәлләнде. Радио – 67,79 мГц, телевидение – 51ТВК.

Сөенечтән башым күккә тиде...

ТӘГӘРМӘЧКӘ ТАЯК ТЫГУЧЫЛАР

Минем телевизион тормышымда тәгәрмәчкә таяк тыгучылар да, мине яраткан эшемнән аерырга теләүчеләр дә шактый күп очрады. Мин хәтта берара Менделеевск шәһәренә китеп тә эшләп алдым.

Әмма минем өчен иң мөһиме – яраткан эшем. «Сабыр иткән морадына җиткән» дигән мәкаль бар. Уйламый гамәл кылырга ярамый. Барысына да кул селтәп, ташлап китәсе килгән чаклар да булды, әмма үземә ышанган кешеләрне уңайсыз хәлгә куярга теләмичә, мин үземдә яңа көч таба һәм алга баруымны дәвам итә идем. Кайчан да булса тарих һәркемгә гадел бәя бирер, шуңлыктан начарлык эшләүчеләргә вакыт әрәм итеп тормаска кирәк.

ЯҢА ИСКЕ ЭШ УРЫНЫ

Шулай килеп чыкты ки, миңа яңа иске эш урыныма кире кайтырга туры килде.

Яңа проектлар, тапшырулар пәйда булды. Аларның берсе кышкы бакчада төшерелә торган «Хәерле иртә, Чаллы! Доброе утро, Челны!» иде. «Ты не один» исемле ток-шоу үзенә күрә компаниянең визит карточкасына әйләнде. Ул без ташландык бинада җиһазландырган павильонда төшерелә иде. Биредән, ягъни Яр Чаллыдан, Казан һәм Мәскәү белән туры эфирлар оештырылды.

Күп нәрсәне, җаным теләгәнне, үзем дә төшердем, мәсәлән, «Инзер буйларында» фильмын. «Тәрекләр илендә», «Латвиядә татарлар тормышы» фильм-тапшырулары да минеке. «Без тарихта эзлебез», «Яшь йөрәкләр», «Нам, молодым», «Талир тәңкә», «Гөлбакча», «Мәдәни сәхифә», «Тормыш мизгелләре», «Откровенный диалог», «Оперативная сводка» ул еллардагы иң уңышлы тапшырулар исәбендә йөри.



«ЭШНЕ МЕНӘ ШУЛАЙ ОЕШТЫРЫРГА КИРӘК!»

Чаллы мэры Илдар Халиков безгә искергән аппаратураны яңартырга булышты. Мөмкинлекләр дә, сыйфат та шактый яхшырды.

2004 елда безгә Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев килде һәм эшебезне Казан телеканаллары җитәкчеләренә үрнәк итеп куйды:

– Эшне менә шулай оештырырга кирәк! – диде ул.

1992 елның маенда «Күңел» радиосы эшли башлады. Әлфия Шәрипова җитәкчелегендә «Күңел» радиосы тәүлек буе сөйли торганга әйләнде, аны Интернет аша бөтен дөнья татарлары тыңлады, без ел саен «Иң яхшы татар радиосы» дигән мактаулы исемгә лаек булдык. Тәүлегенә биш сәгать буе нәкъ менә үзебез әзерләгән тапшырулар яңгырады.

КЫЙБЛАДАН ТАЙПЫЛМЫЙЧА

Тамашачы әзер тапшыруны күргәнче, ул бик озын юл үтә. Аңа машина йөртүче, телеоператор, монтажлау остасы, журналист һәркайсы үз өлешен кертә... Эш циклы тулы бер чылбыр тәшкил итә. Вакыйга урынына вакытында барып җитмәсәң, чылбыр өзелә, яңалык искерә, тапшыру эфирга чыкмый кала...

2024 елның 2 июнендә миңа 75 яшь тулды. Дөресен әйтим, үз гомеремдә күпне күргән җитәкче буларак, мин үземне теләсә кайсы вакытта эштән җибәрү ихтималы булуын һәрвакыт белеп яшәдем һәм моңа әзер идем. Үземә лаеклы алмаш тәрбияләвемә горурланам. Телерадиокомпания, кыйбласыннан тайпылмыйча, үз халкы язмышына игътибарны гел арттырып, һәрчак алга барырга тиеш иде. Тарихта безгә бирелгән вакыт чикләнгән бит, шуңлыктан мин үзебезне һәр көнне, һәр минутта халык йөрәгенә иман, игелек, гаделлек нурларын сеңдерергә тиеш, дип санадым.

«ЗАБЫТЫЕ»*

бер сугыш турында документаль-уен фильмы

– Сугыш турында фильмнар төшерү хәзер нигә кирәк? – дип сорый журналистлар «Забытые» документаль-уен фильмын дөньяга чыгарган блогерлардан. Алар исә моңа үзләренең Бөек Ватан сугышы темасына төшерелгән биш новелласы белән җавап бирә.

«Мондый фильмнарны дәшми калмас өчен төшерү зарур!» – дип нәтиҗә ясый персонажлардан берсе.

Экраннан тамаша залына күчкән алкышлардан соң сәхнәдә әлеге сүзләрнең авторы – Башкортстаннан хәрби корреспондент Ильяс Батыргәрәев үзе пәйда була. Ул «Татарстан» журналын «Забытые» фильмын төшерү тарихы һәм үзенең әлеге проектка ничек килеп эләгүе белән таныштыра.

*«Онытылганнар»

ТОРМЫШНЫ ҮЗГӘРТКӘН КӨН

Ильяс Батыргәрәев үзен язмыш хәрби журналистика белән бәйләр дип беркайчан да уйламаган. Әмма махсус хәрби операция башлангач һәм танышлары, дуслары сугышка киткәч, моннан читтә кала алмаган.

– Беренче көннәрдән диярлек Севастопольдәге госпитальгә барып йөри, анда якташларыбыз белән аралаша, аларга гуманитар ярдәм илтә башладым. Аннары бер хәйрияче биргән броняны «Урал» һәм гуманитар ярдәмне алгы сызыкка илттем. Россия Оборона министрлыгында минем бу гамәлләремне күргәннәр һәм хәрби журналист сыйфатында аккредитацияләделәр. Һәм узган елның 22 маенда тормышым тулысынча үзгәрде – мин үземнең озак вакытлы беренче командировкама чыгып киттем.

ТӘҮГЕ РОЛЬ

– Ильяс, бу проектка ничек килеп эләктең? Синең анда катнашуың һәм фильмдагы ролең очраклы гынамы?

Фотолар Ильяс Батыргәрәев архивыннан

– Бер ел элек мин Казандагы «Инсайт люди» проекты резидентына әйләндем. Гәрчә теләсә кайсы шәһәргә бару мөмкинлегем булса да, мин Казанны сайладым. Чөнки минем язмышым Татарстан белән бәйле. Мин «Татарстан – яңа гасыр» каналының Мәскәүдәге корпунктында эшләгән идем. Бермәлне исә Казанда яшәп, Татарстанның халык артисты Гүзәл Уразова белән дә эшләп алдым. Ул чакта без гастроль, концертлар белән бөтен республиканы иңләдек. Алай гына да түгел, әле кызым да нәкъ менә Казанда тәпи йөреп китте. Бу минем өчен бик мөһим.

«Инсайт люди» проектының блогерлар бергәлегенә килеп элеккәндә, мин әле хәрби командировкаларга йөрми идем, күңел ачу контенты ясарга җыендым... Әмма тормышым 180 градуска борылгач, каналымда хәрби сюжетлар пәйда булды. Аларны караучылар, язылучыларым күбәйде, федераль канал һәм пабликлар мондый темаларга һәрчак игътибарлы бит. «Инсайт люди» блогерлар бергәлеге дә хуплады. «Забытые» – безнең күп проектларның берсе генә, ул бик җитди һәм колачлы, аны бөтен ил буенча кинотеатрларда күрсәтәләр. Анда элэгүемә мин бик горурланам. Бу минем кинода беренче профессиональ төшүем.

ДӘШМИ КАЛМАСКА!

– «Мондый фильмнарны дәшми калмас өчен төшерү зарур!» дигән сүзләрең сценарийда язылганмы, әллә бу инде шәхси миссияңме?

КАЗАНДА «ЗАБЫТЫЕ» КИНОАЛЬМАНАХЫ КҮРСӘТЕЛДЕ. РОССИЯ БЛОГЕРЛАРЫНЫҢ ӘЛЕГЕ ПРОЕКТЫ БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ КАҺАРМАННАРЫ ИСТӘЛЕГЕН САКЛАУГА ҺӘМ ТАРИХИ ФАКТЛАРНЫ БОЗУГА КАРШЫ КӨРӘШКӘ ЮНӘЛТЕЛГӘН.

– «Дәшми калмаска» – минем балачагымнан ук килә. Минем әнием журналист, ул бик озак еллар төрле матбугат басмаларында эшләде, һәм мин ММЧ ничек эшләвен балачагымнан ук күреп үстем.

Шул чакта ук минем төп принципларым – нәкъ менә гаделлек, хәбәрдарлык, ачыклык принципларына нигез салынгандыр. Әниемнең ничек эшләвен күреп, сеңдереп, мин балачагымнан ук инде үземнең барыбер әлеге һөнәргә бәйле булачагымны белә идем. Бөтен балачагым типографиядә үтте. Мәктәптә 8 сыйныфтан телевидение башланды. Аннары мин Санкт-Петербург дәүләт кино һәм телевидение институтында продюсер белгечлеген алдым, бер үк вакытта телерепортерлар курсларын да тәмамладым. Һәм нәкъ менә үзебезнең төбәк телеканалында эшләргә дип, өйгә кайттым. Мин үземнең республикамны бик яратам, андагы бөтен районнарда, бөтен сыер абзар-



ларында булдым. Мөгаен, бу минем шундый ватанпәрвәрлегемдер.

Һәм махсус хәрби операция башлангач, үземне шактый яхшы төбәк журналисты дип санасам да, баштарак бөтен вазгыятьне аңлап бетерә алмадым. Кызганыч ки, мәгълүмат бик аз иде. Һәм мин, намуслы кеше буларак, чынбарлыкны ничек бар шулай күрсәтергә тотындым. Минем сюжетларымда хәтта кадр артында сөйләү дә юк, мин кешеләргә үз фикерләрен белдерергә мөмкинлек бирәм.

«ЗАБЫТЫЕ» АЛЬМАНАХЫНЫҢ ТӨП ТЕМАЛАРЫННАН БЕРСЕ – ИНТЕРНАЦИОНАЛЬ ДУСЛЫК. ФИЛЬМ ВОЛГОГРАД, СТАРЫЙ ОСКОЛ, БАШКОРТСТАН, БУРЯТИЯДӘ ҺӘМ РОССИЯНЕҢ БАШКА ТӨБӘК ҺӘМ ШӘҺӘРЛӘРЕНДӘ ТӨШЕРЕЛГӘН.

Көннәрдән бер көнне безгә Луганскидан, Петровскийдан, Красный Лучтан балалар килде. Алар белән шәһәр буйлап йөргәндә, түбәдә кар чистартучылар зур өемне төртеп төшерде дә, кар гөрселдәп аска килеп төште. Без моңа игътибар да итмәдек, ә балалар шундук җиргә егылды, чөнки алар шартлау тавышларына шулай реакция бирергә күнеккән иде. Һәм менә шундый очраклардан соң мин, хәтта журналист сыйфатында да түгел, бәлки намуслы ир-ат буларак шушы юлны сайладым – барысын да үзем күрсәтергә, сөйләргә, алгы сызыктагыларга ярдәм итәргә булдым. Дәшми калмаска. «ДӘШМИ КАЛМАСКА!» – бу сүзләрне минем девизым дип тә әйтеп буладыр, мөгаен.

БУ ФИЛЬМ – БЕЗНЕҢ САЛЛЫ ДӘЛИЛ

– Ильяс, Россия блогерларының бу проекты тарихи фактларны бозуга каршы да юнәлтелгән, диелгән иде. Тик сезнең документаль-уен фильмы ничек итеп тарихи фактларның фальсификациясенә каршы көрәшә ала соң? Мәсәлән, тарихны белмәгән яшь буын аны бары тик уйлап чыгарылган сәнгать әсәре дип кенә дә бәяләргә мөмкин бит.

– Бу мәгълүматны кемнең ничек кабул итәсен мин белмим. Кем ничек аңлый инде. Безнең төп бурыч исә – тарихи фактларны, тарихи вакыйгаларны күрсәтү. Сценарий авторлары архивларда утырды. Безнең максат – игътибарны җәлеп итү, кемнең күбрәк беләсе килә – ул аннары үзе дә эзләнәчәк. Безнең бурыч – сораулар тудыру, кешеләргә нинди дә булса этәргеч бирү. Мультфильмдагы Леопольд кебек бөтен дөньяга мәхәббәт белдерер чак түгел шул бүген. Кызганыч ки, бу дөньяда безне яратучылар бик аз хәзер. Элек иңгә-ил торып уртак дошманга каршы көрәшкән халыклар хәзер һәйкәлләрне җимерә, яла яга, фактларны бозып күрсәтә. Бу инде – зур сәясәт, мин исә кечкенә кеше, һәм минем бурычым – кешедә нindидер сораулар тудыру гына.

Без бу фильм белән барлык сорауларга да җавап бирә алмыйбыз. Без әле бу юнәлештә бик аз эшләдек, әмма нәрсә дә булса эшләдек. Һәм мин моның белән горурланам. Төрле төбәкләрдән килүчеләр стратегик сессиядә төрле фикерләр әйтте. Мин нәкъ менә шуңа – үзебезнең контраргумент булдыра алуыбызга сөенәм. Безнең фильм – Россия мәдәниятен хурларга, совет халкының батырлыгын онытырырга тырышучыларга каршы саллы дәлил ул.

ГАИЛӘГӘ ЗУР БУРЫЧ ЙӨКЛӘНӘ

– Фильм бик көчле, кырыс булып чыккан, рәхмәт аның өчен. Әмма безнең көннәрдә Бөек Ватан сугышы каһарманнары истәлеген саклау һәм тарихи фактларны бозудан туктату өчен фильмнар гына җитәрме соң? «Забытые» фильмын балаларга күрсәтү тыела бит. Хәер, алар башка фильмнарны да карарга бик яратмый хәзер...

– Тулысынча килешәм, бер фильм гына җитәрлек түгел билгеле. Әмма бу безнең икенче фильмыбыз инде. Вакыт үткән саен, хәзер хәтта безнең резидентларның да фикере үзгәрә бара. Бер ел элек кешеләрнең сугышка мөнәсәбәте бөтенләй башка иде әле. Бүген вазгыять үзгәрәк. Җәмгыять үзгәрә бара. Мин үзем дә, яшь әти буларак, баламны тәрбияләүнең миңа нинди шәхси җаваплылык йөкләвен яхшы аңлыйм. Бөтен нәрсә гаиләдән килә. Безнең фильм – тәрбия чараларыннан берсе генә. Аны мәктәптә балаларга күрсәтсәләр бик яхшы булыр иде, әмма бөтен нәрсә гаиләдән килә. Гаилә нинди – балалар шундый, киләчәк буын шундый.

ТАНИТА

Чегән кызының искиткеч тарихы

Дмитрий Сивков

– Укый-яза беләсеңме? – Беренче тапкыр очрашканда ил күләмендә иң танылган чегән – «Ромэн» театрының сәнгать җитәкчесе Николай Сличенко Танитаны шулай каршы ала.

– Мин консерватория тәмамладым... – ди кыз кыяр-кыймас кына һәм шунда ук Казан опера театры сәхнәсендә «Сильва», «Баядера» һәм «Летучая мышь» оперетталарында төп партияләрне башкару кебек тәҗрибәсе бөтенләй бернәрсәне дә аңлатмавына төшенә.

Эш аны өермәдәй бөтереп ала.

АЛДАН КҮРҮЧӘНЛЕК ӨЧЕН «МИНУС»

Унөченче каттагы бер бүлмәле фатир кухнясы бизәлеше белән Александр Пушкин поэмасындагы шау-шулы чегәннәрнең Бессарабия буйлап күченеп йөргән арбаларын хәтерләтә. Сүз уңаеннан, хуҗалар белән сөйләшү вакытында «Цыганы» поэмасы күп мәртәбәләр искә төшеп-төшеп алды. Без утырган бүлмәгә килгәндә исә, ул гаҗәеп төрле әйберләр белән тулган.

Мондый бизәлеш авыл музейларын хәтерләтә: урын җитми, ә куяр, күрсәтер нәрсәләр бик күп, җитмәсә төрле-төрле. Монда да иконалар күрәзәченең амулет-атрибутлары, пычак һәм Убырлы карчык коллекцияләре беррәттән куелган, хуҗабикәнең танылган кешеләр белән фотолары һәм фронтовик бабаларының портретлары мактау кәгазьләре белән янәшә урнаштырылган...

Нәсел шәҗәрәсе турында сораугa табор тормышыннан кызыклы хикәя ишетергә теләп утырганда, алдан күрүчәнлегем өчен «минус» та эләктердем. Бөтенләй башкача булган икән бит!

– Әниемнең этисе Анатолий Федотов Мари АССРның авыл хуҗалыгы министры булган. Ә менә этием ягыннан – бездә ике буын табиблар: бабам Леонид Кириллов медицина хезмәте полковнигы булган, демобилизациядән соң Казанның 12 нче госпиталендә эшләгән; этием Анатолий Леонидович – нейрохирург, Горький паркы тирәсендәге 11 нче хастаханәдә бүлек мөдире иде, әнием Ирина Анатольевна – дерматолог, Болак буендагы косметология клиникасының баш табибы, – дип, нәселе белән

Фото автора

таныштырды Казандагы Nova Roma профессиональ чегән эстрада ансамбленең сәнгать җитәкчесе Танита Петрова.

«НОВА РОМА» ВОКЗАЛДА ТУПЛАНМАДЫ

– Күпләр сезнең милләт вәкилләренең эшчәнлеге турында бераз башкачарак уйлый.

– Әйе, без чегәннәр. Һәм үзебезгә ир итеп шулай ук чегәнне сайлыйбыз. Дөрес, паспорт буенча рус булырга да мөмкин. Әлеге дә баягы «бишенче пункт» ул чакта тормышыбызны бозарга мөмкин иде.

– Ә хәзер?

– Беләсезме, хәзер дә шулай. Чегәннәр арасында шәп табиблар, зәркәнчеләр, юристлар һәм башка һөнәр ияләре дә шактый. Ләкин безне барыбер юлбасар, алдакчы һәм карак кабиләсе дип кабул итүдән арына алмыйлар. Мин бөтен кеше шулай уйлый дип әйтмим, ләкин мондый хәлләр белән еш очрашырга туры килә. Гастрольләр вакытында, ниндидер тиен генә торган берәр әйберне урлауда гаепләп, чемоданнарыбызны тентүдән дә уңайсызланып тормыйлар. Әлбәттә, беркайчан да эзләгәннәрен тапканнары булмады.

– ЧЕГӘН СӘНГАТЕ – ЧЕГӘН КАНЫ ГЫНА ТҮГЕЛ, БӘЛКИ ЭЧКЕ БЕР ТАЯНЫЧ БУЛУ ДА, – ДИ ТАНИТА. – ЧЫН ЧЕГӘН БИЮЕ – САФ, САМИМИ, АНДА ИР-АТ БЕЛӘН ХАТЫН-КЫЗ БЕР-БЕРСЕНӘ КАГЫЛМЫЙ. ХАТЫН-КЫЗ – БУЙ ҖИТМӘСТӘЙ ЗАТ. КӨНКҮРЕШТӘ ДӘ БЕЗ БЕР ӨСТӘЛ АРТЫНДА УТЫРМЫЙБЫЗ.

– Шул ук вакытта берәүнең дә гафу үтенгәнен хәтерләмим, – дип сүзгә кушыла Танитаның ире Роман Николаев. – Ул вакытта әле ничектер аңлатырга тырыша идек, хәзер инде адвокатыбызның визиткасын гына бирәбез. Тормыш адвокат ялларга мәҗбүр итте. Шул ук вакытта безнең «Нова Рома» коллективын вокзалларда тупламадык, күбебез «Татарстан Республикасының атказанган артисты» исеменә ия.

ЧЕГӘН КЕМ ДӘ, РОМА КЕМ...

– Ике буын табиблар. Сезнең язмыш та алдан язылган кебек...

– Минем актриса юлын сайлавым гаиләм өчен фаҗигагә тиң булды. Әгәр дә мин баштан ук чегән ансамблендә җырлауны сайлаган булсам, әти-әнием беркайчан да, берничек тә ризалык бирмәс иде. Ләкин язмыш барысын да үзеннән-үзе хәл итте: башта музыка мәктәбе, ә һөнәр сайларга вакыт җиткәч, минем укол, кан һәм башка шундый нәрсәләрдән куркуым ачыкланды. Шул вакытта консерваториянең әзерлек курслары, югары уку йорты үзе, аннары опера театры пәйда булды.

– Ә чегән каны кайчан кайнап чыкты?

– Мин башлыча оперетталарда җырладым, шул исәптән төп партияләрне дә башкардым. Аннары минем белән контрактны озайтмадылар. Сез әйткәнчә, чегән каны, безнеңчә, романо рат* яхшы тормыштан кайнап чыкмады. Гомумән, без, ромалар, «чегән» сүзен бераз кимсетү кебек кабул итәбез. Хәер, көнкүрештә барыбер шулай булып кала.

ИКЕ ЯР УРТАСЫНДА

– Ансамбльне оештыруга мин Мәскәүдә иң-иңнәрдән фатиха алдым: Жемчужныйлар, Бессоновлардан... «Ромэн» ансамблендә озак җырламадым. Николай Сличенконы да беләидем. Бу минем тормышымның матур бер мизгеле булды, әмма ул чорны рәхмәт хисләре белән искә алырга теләмим. «Укый-яза беләсеңме?» – дип каршы алды Сличенко мине. «Консерватория тәмамладым...» – дияргә генә көч таптым. Чынлыкта чегәннәрнең күбесе хәзер дә укый-яза белми. Тугыз сыйныф тәмамласаң, син инде профессор.

Сличенко белән аралашу тормышының матур бер мизгеле була, әмма Танита ул чорны рәхмәт хисләре белән искә алырга теләми.

Сүз уңаеннан, Казанда чегән иҗтимагый оешмасын булдыруны да мәскәүлеләр тәкъдим итте.

– Ә нишләп әлегә кадәр бу оешма күренми?

– Ул вакытта Халыклар дуслыгы йортына да, җирле ромаларга да бу кирәк түгел булып чыкты. Кайберәүләр үз тирәләрендә шикле шәхесләр пәйда булуын өнәмәде, икенчеләре исә рәсми хакимият белән мөнәсәбәтләр урнаштырырга теләмәде.

Кайберәүләр: «Сезгә костюмнар кирәкме?» – диде. Юк, үзебезнекеләрне дә кая куярга белмибез!

«Тормышың тыныч бит. Җырлыйсың, менә шулай дәвам ит», – дип җавапладылар икенчеләре, оешма төзү өчен имзалар җыярга килгәч.

– Ике яр уртасында калдык, – ди ире дә. – Алайса хәзер, чыннан да, иҗат белән түгел, ә низагларны тикшерү, документлар җыю белән шөгыльләнер идек.

Күрәзәче атрибутлары – кешеләр үзләре тылсымга ышанырга тели.

АНСАМБЛЬ СОСТАВЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БИШ АТКАЗАНГАН АРТИСТЫ ЧЫГЫШ ЯСЫЙ.

Серафима исемле убырлы карчык Танитага яшь калырга булыша.

СЕРАФИМА УБЫРЛЫ КАРЧЫК ҺӘМ ЗЕМФИРА ӘБИ

Танита белән Роман ирле-хатынлы гына түгел, иҗатташлар да. Белеме буенча ире хор дирижеры һәм театр режиссеры. Әтисе чегән, әнисе исә рус милләтеннән.

– Башта аның үзебезнеке икәнен белми идем. Бергә эшләдек, аңа чегәнчә кычкыра башлаган идем, ул җавап бирде. Шул рәвешле үзенә каратты, – дип көлә хуҗабикә.

Танитаның беренче никахыннан туган улы Даниил да кайвакыт алар белән бергә чыгыш ясый. Ул үзе стюард булып эшли. Чегәннәргә хас сәяхәт кылу теләген шул рәвешле тормышка ашыра. Танита 36 яшьлек улы барлыгы турында әйткәч, ышанмадым.

– Менә мине яшь итеп саклаучы, – диде, Танита тәрәзә төбендәге убырлы карчыкка ишарәләп. Танышабыз, исеме – Серафима.

Ул хуҗабикә киемендә, аныңча итеп бизәндерелгән, гримланган, чөнки курчакка салынган «программа» шул рәвешле генә эшли икән. Шунда ук: пентакль, шәмнәр, күрәзәче карталары... Инде романо рат кайный башлаган икән, ул кайдадыр үзен сиздерергә тиеш бит. Әнә дәү әнисенең әнисе Зинаида, ягъни Земфира да танылган күрәзәче булган, һәм аңардан бөтен тирә-як өркеп торган. Әбисенә Пушкинның «Цыганы» поэмасы героинясының исеменнән башка башка исем килешмәс тә кебек тоела!

ЧЕГӘН ГИПНОЗЫ ТУРЫНДА

– Хәтерлим, бервакыт урамда бер чегән хатыны: «Әйдә, киләчәгеңне юрыйм!» – дип, юлыма аркылы төшкән иде...

– Туктый күрмәгез! Сөйләшеп тә тормагыз! Минем үземне дә яшь чакта таладылар. Гипнозга эләктем. «Цыган» фильмындагы Соня Тимофеева белән дә шундый ук хәл була бит. Транстан чыгып, кычкыра башлагач, барысын да кайтардылар. Каргыйм, диде. Чегән гипнозының тәэсире бик көчле, һәм бу күренеш әлегә кадәр галимнәр тарафыннан тулысынча өйрәнелмәгән. Чөнки бернинди дә техника да, методика да юк, без бу халәткә керә беләбез. Ул безгә кан буенча бирелә, башкача аңлатып булмый.

P.S.

Романо ратны совет чорында Тото Кутуньоның һәр телевизордан яңгыраган Italiano Vero җыры белән чагыштырып буладыр. Тик анда сүз аль денте спагеттие, кырыну өчен бөтнекле крем һәм буйлы-буйлы зәңгәр костюм турында барса, «Романо рат» җырын язарга алынган кеше стенадагы иконалар янәшәсендәге амулетлар, фронтовик бабайларның фотолары белән бергә урнаштырылган якты йөзле Сличенко портреты, күрәзәче карталары һәм ничек сөйләргә дә аптыраган башка бик күп нәрсәләр турында язар иде...

* Романо рат - чегән каны. Чегәнчәдән тәрҗемә.

ЧИСТАЙНЫҢ МӘШҺҮР ИШАНЫ

Илдус Заһидуллин

Традицион җәмгыять кысаларында яшәгән татарларның уй-фикерләре һәм эш-гамәлләренә мәхәллә руханиларының зур йогынты ясаулары мәгълүм. Ярымаграр өяз шәһәрләрендә башка дин һәм мәдәният вәкилләре белән ут күрше булып көн күргән татарлар өчен дини белем бирүдә, рухи-әхлакый тәрбиядә руханиның дәрәҗәсе һәрвакыт югары сакланган. Араларында мәчетләр салырлык бай сәүдәгәр, үз хисабына мәдрәсә тотарлык мөдәррис, атаклы шәех һәм мәхәлләнең бердәнбер әйдәманы булганнары бик сирәк. Шундый күренекле затларның берсе – Чистай шәһәре имам-хатыйбы Мөхәммәтзакир Камалов-Чистави.



Мул сулы Чулман елгасының сул як ярына урнашкан Чистай 1781 елда өяз шәһәре статусы ала. Пароходлар пәйда булгач, акрынлап илнең мөһим ашлык саклау һәм аны башкалага озату үзәгенә әверелә.

Татарлар Чистайга 1790 нчы елларда күченә башлый. Беренче буын шәһәр халкы яңа урында традицион яшәү рәвешен булдыра: намаз йорты һәм мәктәп ачыла. Чистайның беренче мөдәррисе, Сәмәрканд мәдрәсәләренең берсендә укып һәм укытып, 1813 елда туган иленә кайткан Исхак Сәгыйтов була. 1831 елны ул Казандагы Апанай мәчетенә күчкәч, имам-хатыйб вазифаларын Әхмәт бине Халит әл-Мәңгәри башкара.

ЧИСТАЙ МӘХӘЛЛӘСЕНЕҢ ЯҢА ӘЙДӘМАНЫ

Шәһәр татар җәмгыяте тормышында сәүдәгәр һәм эшмәкәрләр һәрвакыт мөһим роль уйнаган. Алар мәчетләр, мәктәп-мәдрәсәләр төзеткән, муллаларга йортлар салып биргән, дин кардәшләренең кайбер башка иҗтимагый чыгымнарын каплаган. Шуңа күрә мәхәлләдәге күп кенә мәсьәләләрне хәл иткәндә аларның фикере өстен чыккан.

Чистай мәхәлләсендә дә яшәп килгән бу тәртип янган мәчет урынына яңасын салгач үзгәрә башлый. 1854 елда, мәхәллә ышанычлысы буларак, 3 нче гильдия сәүдәгәре Мияссар Мәүлетов губерна хакимиятенә яңа гыйбадәтханә төзү турында гариза юллый. Ә яңа агач мәчет бинасын 1846 елның 17 сентябреннән Чистайда мулла булып торучы Мөхәммәтзакир Габделваһап улы Камаловның кайнатасы Хәсән Якупов 1859 елда төзетә. Урта Азиягә кәрван йөрткән бу бай сәүдәгәр, киявенә дип сатып алган йортны ремонтлап, аңа атап, мәдрәсә бинасы да салып биргән була инде.

Хәсән бай 1815 елда Вятка губернасы Малмыж өязе Сосна авылында туган кияве – атаклы көрәшчене үзенең кәсебендә аркадаш итә. Кайнатасы вафатыннан соң Камалов кулында бөтен мал-мөлкәт туплана. Ул, ил буйлап алыш-биреш итәргә хокук бирүче 2 нче гильдия сәүдәре булып язылып, чит төбәклердән арзан бәягә чәй һәм алтын әйберләр кайтару һәм шуларны табыш белән сатуны җайга сала. Шулай ук Әстерханга сал агызудан да керем кертә. Чистай базары янында төзегән йортын арендага биреп тә табыш ала. Мулланың тагын бер мөһим керем чыганагын сәдака тәшкил итә.

Фотолар автордан алынды

Шул рәвешле үзе мулла, үзе сәүдәгәр Мөхәммәтзакир хәзрәт, Чистай байларына матди яктан бәйле булмыйча, гаиләсенә яңа йорт җиткерә, утарын киңәйтә, мәчетне дә үз хисабына кайгырта, өч бинасы кирпечтән, бер бинасы агачтан салынган мәдрәсә комплексын төзү һәм карап тотуны да үзе башкара.

Хатыны Бибигасимә белән никахтан дүрт бала дөньяга килә. Бу никахтан туган бердәнбер улы Мөхәммәтнәҗип 1881 елда хаҗ сәфәрендә вафат була. Мөхәммәтзакир хәзрәт аксак һәм сәламәтлеге какшаган хатыны янына 1869 елны, никахлап, 15 яшьлек Бибифатыйма исемле кызны ала. Бу никахтан 14 бала туа, шуларның дүртесе сабый чакта вафат була. Хәзрәт хатынын һәм кызларын урамга чыгарып йөртми, алар торган өйнең бар тәрәзәләре дә урамга түгел, каршы йортка һәм бакчага гына карый.

Чистай татар җәмгыяте, традицион гореф-гадәтләрне һәм әхлакый кыйммәтләрне үзәккә куеп, зур авыл мәхәлләсе кебек яши. Әлбәттә, матди яктан мөстәкыйль хәзрәтнең сүзе һәм йогынтысы көчәя бару кайбер шәхесләрдә ризасызлык тудыра. Ләкин алар да күпчелек фикеренә буйсынып яшәргә мәҗбүр була.

Хәзрәт 1882 елда үз хисабына таштан икенче җәмигъ мәчет төзетә. Мәчеткә мулла итеп мәдрәсә хәлфәсе – 26 яшьлек Мөхәммәтшаһидне сайлаттыра. Аңа йорт төзеп, тол калган кызы Бибигандәлибне кияүгә бирә, сәүдә эшләре буенча аркадашы итә. Мөәзин итеп шулай ук «Камалия» мәдрәсәсендә укыган 22 яшьлек Мөхәммәтзакир Хәйретдинов билгеләнә.

1893 елны исә үзе янына икенче мулла итеп Казан шәһәре имамы Хөсәен Әмирханның улы Мөхәммәтнәҗипне куйдырта, аңа икенче никахтан туган Камиләтинниса исемле кызын кияүгә бирә. Кайнатасы Хәсән бай үзен ничек кайгырткан, яшь киявенә дә шундый ук кадер-хөрмәт күрсәтә. Шул рәвешле Чистай шәһәрендәге барлык руханилар арасында кемдер Мөхәммәтзакир хәзрәтнең «Камалия» мәдрәсәсе шәкерте яисә хәлфәсе, кемдер исә остазга кияү булып чыга.

НӘКЫШБӘНДИЯ ТАРИКАТЕ ШӘЕХЕ

Замандашлары Мөхәммәтзакир хәзрәтне куе түгәрәк сакаллы, матур йөзле, зур күзле, пәһлеван гәүдәле кеше итеп тасвирлый.

Риза Фәхретдин мәгълүматы буенча, башта – Таҗетдин Иштирәкидә, аннан соң Мәчкәрә мәдрәсәсе мөдәррисе Габдулла бине Яхья Чиртушида белем алган Мөхәммәтзакир хәзрәт яшь вакытында артык галим булмаган. Хаҗ сәфәреннән тансык китаплар алып кайтып, шуларны укып-өйрәнеп, дин гыйлемен үзлегеннән үзләштергән, тырышлыгы белән укуга мәхәббәте арткан.

Мөхәммәтзакир хәзрәтнең тирә-якта йогынтысы көчәюе аның, шәех буларак, үз тирәсенә чыгышлары белән Идел-Урал төбәгеннән, Урта Азия һәм Кавказдан булган күпсанлы мөридләр туплавына да бәйле.

Хакимияткә каршы чыкканы өчен Россия губерналарының берсенә сөрелгән Дагыстан мөршиде Мәхмүт Алмалы, 1863 елда хәзрәт чакыруы буенча аның авыру кызын дәваларга Чистайга килгәч, йорт хуҗасын зикергә өйрәтә. Хәзерге Азәрбайҗан территориясендәге Алмалы авылында туган Мәхмүт бине Мөхәммәт әд-Дагыстани әш-Ширвани әл-Хәнәфи ән-Нәкышбәнди әл-Мөҗәддиди – суфичылыкның Нәкышбәндия-Халидия тармагы шәехе була. Туган җиреннән аерылырга мәҗбүр булгач та, ул үз тирәсенә күп шәкертләр, фикердәшләр туплый. Аның йогынтысында Мөхәммәтзакир хәзрәтнең Нәкышбәндия тарикатенә караган Халидия тармагы шәехе булып китү вакыты төгәл билгеле түгел: якынча 1860 нчы еллар уртасы дип фаразлыйбыз. Ул Әстерхан каласында яшәгән остазы Мәхмүт Алмалы белән һәрдаим хатлар язышып, фикерләшеп тора.

Шулай да Риза Фәхретдин, «тәсаувыф белән шөгыльләнә башлагач, мөдәрриснең шәкертләр тәрбияләүдә тырышлыгы зәгыйфьләнде, дәрескә әһәмият бирми башлады, мәсләген яхшы гына үзгәртте; яшь шәкертләрен картлар рәвешендә тәрбия итү юлына керде», дип ассызыклый. Аның мәдрәсәсендә укучы мөридләр, башка шәкертләрдән аермалы буларак, һәр көн икенде һәм ахшам намазларына мәчеткә йөри, ахшамнан соң ишанның сөхбәтендә була.

Мөхәммәтзакир шәех, мөридләренә өйрәткән кагыйдәләрне тәртипкә салып, гарәп телендә «Табсират әл-мөршидин мин әл-мәшәех әл-халидийин» (Халидия тармагы шәехләреннән мөршидләрнең тоемлавы) исемле хезмәт яза. Хезмәтнең тарикатьнең әхлакый-концептуаль эчтәлеге

Мөхәммәтзакир Чистави хисабына 1874 елда төзелгән «Камалия» мәдрәсәсенең бинасы.

Мөхәммәтзакир Камалов яшәгән йорт. Чистай ш.

һәм кайбер ритуаллар башкару тәртибе хакындагы өлешләре 1890 елда Галимҗан Баруди тарафыннан аерым китап итеп Казанда нәшер ителә. Хезмәттә авторның фикерләре Коръән аятьләре, хәдисләр һәм күренекле галимнәрнең сүзләре белән ныгытылып бара. Китап авторы фикеренчә, шәех - фани дөньядан читтә торучы, җәмгыятьтәге бөек дәрәҗәләргә омтылмаучы, азга (ашау-эчүдә, гәпләшүдә, йоклауда) да шөкер итеп яшәүче, намаз укуда һәм хәер бирүдә зур тырышлык куючы һәм кылган гамәлләре сөйләгән сүзләре белән туры килүче зат. Шуны раслагандай, Мөхәммәтзакир ишан гади тормыш алып бара. Аның ишле гаиләсендә йорт эшләрен – хатыны, хуҗалык эшләрен кучеры башкара. Аны шәһәр буйлап бер ат җигелгән тарантаста кучеры йөртә. Кайбер сәүдәгәрләрнең көндезге ашларына баруны санамаганда, мәҗлесләргә йөрми. Аның ярдәмчесе – мөәзин исә яңа туган балага исем дә куша, никах йоласын да башкари, мәет тә тә озата, ашка да йөри.

«Изге» саналган хәзрәт йортына халык үгет-нәсихәт сорап та, хәер-сәдака эстәп тә килә, аның янында иман яңартып, ишанның фатихасын, рухи һәм матди ярдәмен ала.

«КАМАЛИЯ» МӘДРӘСӘСЕ ҖИТӘКЧЕСЕ ҺӘМ МӨДӘРРИСЕ

Мөхәммәтзакир Чистави, үзенә кадәр эшләгән мөдәррисләрнең эшен дәвам итеп, 1847 елда үз мәдрәсәсен ача.

1880 нче еллар уртасында «Камалия»дә нигездә Казан, Уфа, Самара губерналарыннан килгән 200 гә якын шәкерт һәм шәһәрдән килеп укучы 25 ләп малай белем алганы билгеле.

Мәдрәсәнең эчке тәртибе дини һәм әхләкый яктан кырыс оештырылган була, тәмәке тарту, исерткеч эчемлек эчү, шәһәр урамында хатын-кыз белән сөйләшеп тору кебек гамәлләр өчен шәкерт укудан куыла. Биш вакыт намаз җәмәгать белән укылган, ләкин берәр сәбәп белән укымый калган шәкерткә җәза бирелми. Рәсмилек җомга һәм тәравихта кулланыла.

Шулай да 1880 нче еллар ахырында мәдрәсәгә беркадәр аракы керә башлый, тыелган булса да, скрипкада уйнаган көйләр ишетелгәли. Шул елларда булса кирәк, ишан кияве Закир хәлфә йогынтысында, сыйныф бүлмәләренә кара такта куйдырып, башлангыч мәктәптә җәдит ысулы белән укыту тәртибен кертә. Барлык укучылар өчен бушлай булган кадим мәдрәсәдә уку-укыту һәм яшәү өчен шартлар бик уйлап оештырыла. Тәһарәтханә һәм кухня урнашкан махсус бинаны җылыту, анда аш әзерләү һәм самоварда чәй кайнату өчен утынны Камалов бирә. Ул шулай ук ел саен кием һәм ризык алырга шәкертләргә 3–5 сум акча да өләшә.

Мәдрәсәнең мунчасы булмау, ә шәкертләргә шәһәрнең җәмәгать мунчасына йөрү тыелган булу сәбәпле, Чистай кешеләре шәкертләрне һәр атна саен диярлек кунакка дәшә торган булалар. Аларны ашатып-эчертеп, ертылган киемнәрен ямап, киемнәрендәге өзелгән сәдәфләрен тагып җибәрәләр. Әгәр шәкерт чирләп китсә, сабакташларына авыру йоктырмасын өчен, шул ук йорт хуҗалары өйләренә алып кайтып дәвалыйлар. Шул рәвешле, чистайлылар мәдрәсәдә санитария һәм гигиена таләпләре үтәлүдә үзләреннән зур өлеш кертә. 1890–1893 елларда «Камалия»дә укыган Гаяз Исхакый үзенең истәлекләрендә кунак булуларны кырыс шәкерт тормышының иң якты һәм матур сәхифәләре дип атап, үзләрен кайгырткан шәһәр татарларын бик җылы хисләр белән искә ала.

1883–1891 елларда «Камалия»дә яшәгән Галиәсгар Гафуров-Чыгътай мәдрәсә шәкертләренең яшерен рәвештә генә җәдиди «Тәрҗеман» газетасын 6 нөсхә алдыруларын хәбәр итә. Шәкертләр шулай ук Төркиядән кайтарылган матур әдәбият белән дә танышып баралар.

Шул рәвешле, искиткеч зур дини абруйлы, гыйлемле, мөселманнарга үрнәк булырлык гамәлләр кылучы, мал-мөлкәтле һәм иганәче хәзрәт, тирә-як авылларга руханилар әзерләү өчен мәдрәсә тоткан мөдәррис һәм үз артыннан меңнәрчә мөрид ияртеккән ишан Чистай шәһәре халкына, патриархаль тормыш кагыйдәләре өстенлек иткән җәмгыять тәртипләрен алга куеп, вәгазьләр укый, халыкны диндар итеп тәрбияләргә омтыла.

СӘЯСӘТЧЕ ИШАН

Хөкүмәт, 1870 елның 26 мартында «Россиядә яшәүче инородецларга белем бирү чараларының кагыйдәләре» исемле канун кертеп, яңа мәктәп-мәдрәсәләр фәкать яннарында рус классы булганда гына ачылырга һәм анда 16 яшькә кадәр барлык шәкертләр дә укырга тиеш дип белдерә. Законда, киләчәктә муллалардан русча укый-яза белү таләп ителәчәк, дип әйтелә.

1859 елда Хәсән бай төзеткән, Мөхәммәтзакир Камалов имам-хатыйб булып торган беренче Җәмигъ мәчете. Чистай ш.

Чистай шәһәренең беренче татар зиратында шәех Мөхәммәтзакир Камалов төрбәсе.

Татарларга рус теле өйрәтүнең ахыргы максаты – руслаштыру һәм русларга кушу дип язылган бу рәсми документ 1870 елда «Известия по Казанской епархии» исемле вакытлы матбугат басмасында нәшер ителә.

1888 елның 16 июле канунында бу таләп 1891 елдан гамәлгә керә дип игълан ителә. Казан байлары 1870 елгы «Кагыйдәләрне», татарчага тәрҗемә итеп, муллаларга тарата. Мөхәммәтзакир ишан Россия хөкүмәте мөселманнарны руслаштырырга тели дигән нәтиҗә ясый һәм, мөселманнарны туплап, 1888 елның 16 июль законын юкка чыгару яки аның үз көченә керүен кичектерүне сорап, Мәхкәмәи шәргыягә (1888–1889) һәм императорга (1889–1890) петицияләр юллауны оештыра. Чулманда навигация башлангач Санкт-Петербургка барып түрәләр кулына әлеге петицияне тапшыру өчен, 1889 елның кышында чистайлылардан 4 кешелек депутация төзи, бу эшкә казанлылар да кушыла. Ахыр чиктә башкалага Казан вәкилләре бара.

Шуннан бирле Чистави 1881 елда шәһәр идарәсе хисабына ачылган рус классына карата кискен тискәре фикерен халыкка тарата башлый. 1891 елда рус теле укытучысы М. Юнысов, мәктәбе бушап калгач, Мөхәммәтзакир хәзрәтнең шәкертләрне рус телен өйрәнергә җибәрмәвеннән зарланып, хакимияткә шикаять яза. Ике арадагы каршылык турындагы хәбәр эчке эшләр министрына барып ирешә. Губернатор, ишанны 1892 елның 2 маенда Казан кирмәненә чакыртып, хакимияткә каршы эшчәнлеген туктатуны таләп итә һәм рәсми кисәтү ясый.

1893 елның 21 маенда өяз исправнигы аны кабинетына чакырта, шәкертләренең рус классына йөриячәге турында йөкләмә кәгазе (подписка) бирмәсә, мәдрәсә ябылачак, дип куркыта. Карт хәзрәт андый кәгазь бирүдән баш тарта.

1893 елның февралендә хәзрәтнең кызын Мөхәммәтнәҗипкә кияүгә бирү уңаеннан Чистайда туй мәҗлесенә Казан һәм Уфа губерналары руханилары һәм сәүдәгәрләре җыела. Мәҗлестә Россия мөселманнарының динимәдәни мәнфәгатьләрен яклау өчен эчке эшләр министрына гына түгел, ә төрек солтанына мөрәҗәгать кылу кирәклеге турында карар кабул ителә.

Спас өязе Ташбилге авылы мулласы А. Габбазов, өченче тапкыр хаҗ кылу сылтавы белән, Мөхәммәтзакир хәзрәт акчасына госманлы дәүләтенә китә, Мәккә һәм Мәдинәдә, мөфтиләрне җыеп, киңәшмәләр оештыра; Россиядә Коръән текстларын цензорның төзәтеп бастырганын хәбәр итә, тиздән мөселманнарның никах һәм аерылу эшләре православие руханилары кулына биреләчәк, дип сөйли. Бу киңәшмәләрдә катнашкан мөфтиләр кул куйган петициядә Россиядәге дин кардәшләренең хокуклары бозылуга тирән борчылу белдерелә. Габбазов петицияне госманлы хакимиятенә тапшыру өчен Истанбулга китә...

Хакимият, Чистай халкының рус теле укытучысын гаепләп язган шикаятен һәм мөфти М. Солтановның ишанны яклап язган хатын читкә куеп, Мөхәммәтзакир хәзрәтне Россия дәүләте өчен куркыныч шәхес дип атый, чит төбәккә сөрү турында карар әзерли. 1893 елның 28 маенда вафат булуы ишанны сөргеннән коткара.

Мөхәммәтзакир ишан вафатыннан соң мөридләре язган ике мәрсия бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән. Шуларның берсе – Мөхәммәтҗан улы Мөхәммәтшакир тарафыннан иҗат ителгәне – 1895 елда Казанда аерым китап итеп бастырыла.

ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНЫҢ ПРЕМЬЕР-МИНИСТРЫ

Айдар Шәйхин

Аны искә алу чараларының берсендә бөек шагыйрь Хәсән Туфан: «Галимҗан Ибраһимов безнең әдәбиятыбызның мәгънәви президенты булса, Гомәр Гали аның баш министры иде», – дип әйтә. Соңрак Рафаэль ага Мостафин аны «премьер-министр» ук дип атый. 1920–1930 нчы еллар әдәбиятының күгендә иң якты йолдызларның берсе булып балкыган, заманында искиткеч зур абруйга ия булган бу шәхеснең фаҗигале төстә һәлак булуына быел 70 ел.

«ДӨРЕС» БИОГРАФИЯ

Гомәр Билал улы Галиев 1900 елның 16 июнендә хәзерге Буа районының Иске Тинчәле авылында туган. Автобиографиясенә таянсак, булачак әдипнең пролетар язучы исеменә туры килгән тәрҗемәи хәлгә ия булуын күрәбез: ул чагыштырмача ярлы гаиләдә туып үсә, «мулла малае» тамгасы белән йөрми. Авылындагы мәктәптә белем алгач, ул елларга хас гадәт буенча, «бәхет эзләп», Донбасска китә. Ачлык-ялангачлык күпләрне шулай иртә өйдән чыгып китәргә һәм коточкыч авыр шартларда хезмәт юлын башларга мәҗбүр иткән шул. Гомәр бер ел ярым Крендичевка станциясе янындагы күмер шахталарында эшли. Аннан янә ярты еллап белем ала, туган ягындагы бер авылда мәктәптә эшли.

Гражданнар сугышы башлангач, Кызыл Армиядә хезмәт итә. Ул фронтка 1919 елның язында кушыла. Ул әзерлек үткән батальон Деникинга каршы хәрәкәтләрдә катнаша. Аларның II Сембер эшчеләр полкы чолганышта калып, 700ләп сугышчы, шул исәптән Гомәр дә әсирлеккә эләгә. Шулай итеп, аның киләчәк өчен мөһим «дөрес» биографиясенең бер пункты – акларда әсирлек вакыйгасы барлыкка килә. Тиздән ул әсирлектән кача, озакламый акларның Идел буенда гаскәрләре дә тәмам тар-мар ителә.

1918–1919 елларда Гомәр Гали Сембердә чыккан «Таң» газетасында язышa башлый. Әкренләп әдәбият дөньясында Гомәр Гали исеме барлыкка килә. 1921 елдан ул Казанда яши, мәкаләләре яшьләр өчен чыккан «Кызыл яшьләр» газетасы белән «Кызыл Шәрекъ яшьләре» журналының һәр санында диярлек басылып бара. Ә 1922 елда ул Казанда ачылган Татар коммунистлар университетының әдәбият бүлегенә укырга керә. Коммунистлар университеты яңа дәүләткә партия кадрлары тәрбияләү максатыннан оештырылган уку йорты була. Аның корпуслары хәзерге Ершов урамындагы КФУ дәваханәсе биналарында урнаша. Бу вуздан татар, рус, чуваш, мари, удмурт партия кадрлары үсеп чыккан. Әдәбият бүлегендә Галимҗан Ибраһимов та укыта. Бу шәхес Гомәр Гали язмышында зур роль уйнаячак, димәк, биредә аларның беренче очрашулары булгандыр. Гомәр ТКУда өч ел укый.

1925 ел җитә. Париж шәһәре халыкара чара – заманча декоратив һәм сәнәгый сәнгать күргәзмәсен кабул итә. Башка илләр еллар буена әзерләнә торган чарага советлар илен соңгы сәгать сукканда гына диярлек чакыралар. Әмма яшь дәүләт сынатмый. Шул елның 4 июнендә күргәзмәнең иркен биләмәләрендә СССР павильоны да ачыла. Әмма ул көн җиткәнче, шактый эшләр башкарыла, илнең казанышларына ревизия үткәрелә. Мәскәүдән милли республикаларга аерым күрсәтмәләр җибәрелә. Татарстанны тәкъдим итәр өчен кандидатларны ТАССР Халык мәгарифе комиссариаты каршындагы Академик үзәк барлый. Галимҗан Ибраһимов җитәкләгән оешма атаклы сәнгать белгече Петр Дульскийны һәм... беркем белмәгән яшь әдәбиятчы Гомәр Галине җибәрә.

Гомәр бу зур вакыйгада татар мәдәниятенең бер вәкиле буларак катнаша. Аңа остазы Галимҗан Ибраһимов конкрет күрсәтмәләр дә бирә. Аларның асылы шуңа кайтып кала: Гомәр юкка гына бармый, ул дөньяны күрергә,

Фотолар автордан алынды

яхшы үрнәкләрне үзләштерергә һәм тәҗрибәсен башка яшь язучылар белән уртаклашырга тиеш була. Бу командировканың бер нәтиҗәсе – «Чит илләрдә» исемле очерк. Заманында зур популярлык казанган, аерым китап булып та чыккан очеркта Гомәр Гали Латвия, Литва, Польша, Германия һәм Франция турында җентекләп яза.

ӘДӘБИЯТ МИНИСТРЫ

Париждан урап кайткан егетнең карьерасы бик тиз үсеп китә. 25 яшендә үк ул «Безнең юл» журналының җаваплы сәркатибе буларак эшли башлый. Бу журнал хәзерге «Казан утлары»ның «баба»сы. Ул көннәрдә әдәбиятчылар өчен чагыштырмача яңа булып тоелган әдәби журнал яшь һәм өлкән иҗатчыларны да берләштерә. 1927 елда журналның җаваплы мөхәррире итеп билгеләнә. Басманың исеме «Атака» дип үзгәртелеп, ике атнага бер чыга башлагач та җитәкчелекне дәвам итә.

Ниһаять, 1931 елның көзендә ул Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият секторы мөдире һәм баш мөхәррире итеп билгеләнә.

Замандашлары аны җитәкче һәм оратор сыйфатында да, редакция хезмәткәре буларак та югары бәяли. Мәсәлән, аның йогынтысында булган, шәкерте дип саналырга лаеклы Газиз Иделле болай дип искә ала: «Агымдагы әдәби хәрәкәтнең гел үзегендә була ул. Кайберәүләр кебек әкрен кыймылдауның нәрсә икәнен белми. Гел ашыга, алга иелебрәк, бик кызу атлап йөри, чаба, артыннан һич өлгерерлек түгел. Аның барлык хәрәкәтләре: сөйләве, язуы, чыгышлары – барысы да кызу, үткен, кискен һәм гадел».

Язучы Афзал Шамовның исә мондый хатирәләре сакланган: «Гомәр редакциягә кайчан гына килмәсен, аның бүлмәгә керүен сизми калмыйсың. Ул, пальто җапыйларын чишеп җибәреп, һәрвакыттагыча бүселеп торган кара портфелен култыгына кыстырган килеш, ашыгып, бераз алпан-тилпән атлабрак килеп керә, исәнләшә, өс киемен сала һәм шундук, хәтта ишектән кергәндә үк, урамда үзе тап булган берәр кызык хәлне сөйләргә керешә. Булмаса, яңа берәр анекдот сөйләп ала. Ничектер, аның белән бергә безнең караңгы бүлмәбезгә яктылык кергән, нур кергән, саф һава кергән сыман булып китә <...>.

Гомәр яхшы оратор да иде. Җыелышларда докладлар ясый, әһәмиятле мәсьәләләр каралган чакта чыгып сөйли, үз фикерен әйтмичә калмый. Аңа сүз бирелгәч, ул гадәтенчә трибунага ашыгып менә, алдан әзерләнгән тезисларын кесәсеннән чыгарып алдына куя. Сүзләре чишмәдәй агып чыга, җөмләләре, бау ишкәндәй, бер-берәнә тыгыз бәйләнеп бара, фикере тирәнәя, киңәя һәм залның игътибарын үзенә җәлеп итә».

Әдәбият турында фикер йөртер һәм башкаларга киңәш бирер өчен, үзеңә дә барыбер әдип булырга кирәктер. Гомәр Галинең 1920 нче елларда басылган хикәяләре аның реалистик проза вәкиле булуы турында сөйли. «Бу хикәяләр халыкка аңлаешлы гади тел белән язылганнар. Аларның сурәтләү чараларында «матур» язарга, купшыланырга омтылу юк», – дип бәя бирә Гариф Ахунов. Әйе, татар укучысының игътибарын җәлеп иткән әсәрләре бар аның. «Биктимер ничек эшче булды?», «Ат саклаганда», «Кубань буйларында», «Беренче мәхәббәт» хикәяләре аның тотрыклы каләм иясе булуын күрсәтә.

Шулай да Гомәр Галине әдәбиятның «премьер-министры» иткән хезмәте – оештыручы һәм лидер булуы. Яшь язучыларның иң беренче оешмасы – «Октябрь» берлеген Кави Нәҗми, Һади Такташ белән Гомәр Гали 1923 елда ук төзиләр. Әйе, бу берләшмә озак яшәми, әмма тиздән Татар пролетар язучылары ассоциациясе барлыкка килә. Анысында Гомәр Гали җитәкчелек итә, Мәскәүдәге РАПП белән аралаша. Ә инде 1934 елда Татарстан Совет язучылары берлеге оешканда, ул оештыру комитеты рәистәше буларак хезмәт итә. Бу елларда татар әдәбиятында аның белән аралашмаган, киңәш-табыш итмәгән язучы булмагандыр. Бик яшь булуына карамастан, аңа табигатьтән килгән ниндидер бер олпатлык хас була.

Яшьләр белән эшне ул искиткеч югарылыкка күтәрә. Шул ук Афзал Шамов бу хакта болай дип яза: «Нинди генә жанр вәкиле булмасын, чыннан да талантлы, өметле яшь язучы икән, аның иҗатына аеруча игътибар итә иде. Ул аның басылып чыккан әсәрләре белән генә түгел, язылу процессындагы әсәрләре белән дә, шулай ук яшь авторның җәмгыятьтәге урыны, үз-үзен тотышы белән дә кызыксына».

Гадел Кутуй, Гомәр Гали һәм Һади Такташ. Фото Шаляпин музееннан алынды.

Бу чыннан да дөреслеккә туры килә торган сүзләр. Гомәр Гали күреп алган һәм үстергән, иҗатка этәргән язучылар арасында Фатих Кәрим, Фатих Хөсни, Газиз Иделле кебек авторлар бар.

Әдәби берләшмә һәм журнал, нәшрият эше белән бергә, Гомәр Гали әдәби тәнкыйть юнәлешендә иҗатын дәвам итә. Бу өлкәдә хезмәте уңышлырак барсын өчен, 1935 елны партия обкомы бюросы аны «Совет әдәбияты»ның җаваплы редакторы итеп билгели һәм башка эшләреннән азат итә. Әмма ул язучылар берлеге идарәсендә тәнкыйтьчеләр секциясе җитәкләвен дәвам итә.

1920–1930 нчы елларда иҗат иткән шәхесләргә бертөрле генә бәя бирү, әлбәттә, бик авыр. 1920 нче еллар азагында киң таралган «вульгар социологизм» теориясе аркасында, Гомәр Гали дә Фатих Әмирхан, Тукай, Дәрдемәнд кебек шагыйрьләрне буржуаз әдип кенә бәяли башлый. Дөрес, 1930 нчы елларда карашлар инде үзгәрә, Гомәр Галинең дә әдәбият турында күзаллавы эволюция кичерә. 1950 нче еллардагы бер көндәлегендә ул «Кеше – шартлар җимеше» дип язып куйган. Бу гыйбарә аның үзенә дә бик туры килә. Кайчандыр «солтангалиевчелек»кә, «троцкизм»га каршы көрәш елларында ул, партия сәясәтен үтәп, мәкаләләр яза, «дошманнар»ны «фаш итә».

Гомәр Гали биографиясенең тагын бер мөһим штрихы: 1929–1934 елларда ул Казан медицина институтында татар теле кафедрасын җитәкли. Бу елларда институтта булачак табибларны татар телендә дә укытканнар. Соңыннан татар төркемнәре бетерелә, ә менә Гомәрнең үзенә мединститутта укыту елларының бер әҗерен репрессия вакытында күрергә насыйп булачак.

Гомәр Гали белән Галимҗан Ибраһимов, Ялта. Фото Шаляпин музееннан алынды.

«БУ КАРАҢГЫ ТӨН МИНЕМ ӨЧЕН КАЙЧАН БЕТӘР»

Гомәр Гали үзе дә, бөтен гаиләсе дә – репрессия корбаннары. Ул кулга алынгач, күпмедер вакыттан соң хатынын да алып китәләр, ә балаларын кайсын кая тараталар…

Хатыны Хәрирә Зиннәтулла кызы Биктаһирова белән ул атаклы 17 мәктәп директоры Габдрахман Рәфыйковның 40 еллык иҗат бәйрәмендә таныша. Тиз генә кавышмыйлар, чын-чынлап очрашу-танышу бер елдан соң була, шуннан соң гына алар өйләнешәләр. Хәрирә ханым финанс институтын тәмамлый һәм Казанда һөнәре буенча эшли. Гаиләдә ике кыз бала туа, 1931 елдан алар шәһәр үзәгендә яши. Бар да матур һәм күңелле дәвам итәргә тиеш була…

Татарстан язучыларына һөҗүм 1936 елның көзендә үк башлана. Натурализм һәм формализмга каршы игълан ителгән көрәштә кемне дә булса корбан итәргә тиеш булсалар да, язучылар берлеге җитәкчесе Кави Нәҗми тәнкыйтьне чамалап кына үткәрә, язучылар хаталары өстендә эшли, дип белдерә.

1937 елның 10 мартында Гомәр Гали кулга алына. Әлбәттә, ул үзенең «гаебен» танымый, арест вакытында ук тиздән өйгә кайтачагын әйтә. Тентү барышында бихисап кулъязмалар, хатлар, китапларны алып китәләр. Галимҗан Ибраһимов белән алышкан хатларны аеруча кызыксыну белән барлыйлар.

Аның кулга алынуы Казан җәмәгатьчелеге өчен аяз көнне яшен суккандай була. Моңарчы НКВД корбаны булган шәхесләр турында әле, ул тегеләр яклы булган дип, чыш-пыш килергә азмы-күпме нигез уйлап табыла алса да, Гомәр Галинең советка каршы эшчәнлегенә беркем ышанмый. Фатих Кәрим бу хакта кайсыдыр бер мәҗлестә кычкырып ук әйтә. Ни кызганыч, озакламый яшь шагыйрьнең үзен дә нахакка кулга алалар.

Гомәр Гали «троцкист-зиновьевчы» булуда һәм башка бихисап «гөнаһ»ларда гаепләнә. Казан төрмәсендә аны күп тапкырлар кыйныйлар һәм газаплыйлар. Аңа Г. Ибраһимов белән элемтәләре, Парижга 1925 елгы сәяхәте, Берлиндагы Галимҗан Идрисовны белүе, Фатих Кәрим, Кави Нәҗми кебек «халык дошманнары» белән дуслыгы өчен, гаеп өстенә гаеп ягалар, үзен пычрата торган гаеп тану кәгазьләренә кул куюын таләп итәләр. Әмма, ни гаҗәп, Гомәр Гали гаебен танымый. 1937 елның 15 августында «өчлек» аны 10 елга хөкем итә.

Владимир, Орел төрмәләрендә утырып алганнан соң, ул Норильскидагы хезмәт-төзәтү лагерена җибәрелә. Азат ителгәнчегә кадәр ул коточкыч шартлардагы лагерьда тотыла. Бу елларда аңа исән калырга ике нәрсә ярдәм итә: гаепсезлегенә бар җаны белән инанып, гаделлекнең кайтарылачагына ышануы һәм һөнәр үзләштерергә әзерлеге. Әйе, лагерьда ул медицина белемен үзләштерә

һәм хәтта гади генә операцияләрне башкара, медбрат булып хезмәт итә.

Көндәлегендә ул бервакыт «Бу караңгы төн минем өчен кайчан бетәр?» дип яза. 1947 елда аның җәза вакыты тәмамлана. Ул туган авылына кайтып егыла, бик олы яшьтәге эти-әнисе янында яшәп ала. Бераздан Казанга кайтырга да рөхсәт бирелә. Әлбәттә, элеккеге дәрәҗәле урыннарда эшләү инде мөмкин булмый. Ул үзе дә лагерьдан шактый үзгәреп, фикер сөреше ягыннан тирәнәеп, дөньяга аеграк карый торган кеше булып кайта. Көндәлегеннән күренгәнчә, ул «деколониаль» дискурста фикерли башлый, татар зыялыларының бөтен эштә рус интеллигенциясен үрнәк итеп куюын һәм татар тарихын объектив яктыртмаган совет тарих дәреслекләрен тәнкыйтьли. Дистә ел эчендә үсеш кичерергә тиешле татар әдәбиятының хәлен дә ул деградация дип кенә бәяли.

Шулай итеп, лагерьдан кайткан Гомәр Гали күпмедер дәрәҗәдә «уңайсыз» кеше дә булып чыга. Урнашырга яхшы эш табалмый, күпмедер вакыт медицина институтының «Иске клиника»сында статист булып эшләп ала, Горький музее белән «Шәриф Камал һәм Максим Горький» темасына эзләнү алып барырга килешү төзи. Әмма аның өстеннән кемдер инде шикаять язарга өлгерә. 1949 елның июнендә ул, кабат кулга алынып, гомерлеккә сөргенгә җибәрелә. Сөрген урыны – Красноярск крае.

Алга таба аның язмышы аеруча үкенечле ахырга якынлаша. Ул туктаусыз хатлар яза, әдәби тормыш белән кызыксынуын туктатмый, үзен аклау өчен көрәшә. Кабат сөргенгә җибәрү факты аңа аеруча нигезсез булып күренә, чөнки бу очракта беренинди яңа сәбәп һәм дәлилләр дә китерелми.

Сөргендә берничә тапкыр яшәгән урынын алыштырырга туры килә. Соңгы йорты – халык телендә «Лесоповал» дип йөртелгән Подпорожье авылы. 1954 елның 5 июлендә аның өенә Иванова фамилияле бер яшь хатын килә. Ул аңардан кассация шикаяте язарга ярдәм сорый. Укымышлыгы бөтеннәргә билгеле булганга, аның янына мондый үтенечләр белән күп кеше йөргәндер, күрәсең. Бу хатын чыгып киткәч, күп тә үтми, өйгә Ивановананың сөяркәсе, бандитизм өчен хөкем ителгән кеше килеп керә. Көнчелегеннән ул Гомәр Галигә балта белән сугып чыгып китә. Татар зыялысының гомере шундый үкенечле үлем белән өзелә...

«Гади, тыныч шәраитдә татар әдәбиятына хезмәт күрсәтә алырлык мәгърифәте бар иде». Гомәр Гали турында Бакый Урманче әйткән бу сүзләр югалган, һәлак ителгән зур потенциал турында сөйли кебек.

ГОМӘР ГАЛИ ҖИҢДЕ

1955 елның 24 августында СССР Югары судының Хәрби коллегиясе, Гомәр Гали эшен өр-яңадан карап, язучыны тулысынча аклый. Үлгәннән соң булса да, аның исеменә төшерелгән кара тап юыла.

1960–1970 нче елларда Казанда Гомәр Галигә багышланган истәлек чаралары да үткәрелә башлый. Ә 2000 елда аның 100 еллыгына зур тантаналар оештырыла. Бу вакытка туган авылы Иске Тинчәленең урта мәктәбендә Гомәр Гали әдәби музее да оештырыла. Казанда хәзерге К.Нәҗми урамында, Мергасов йортының кырында гына урнашкан йортта истәлек тактасы урнаштырыла, Гомәр Гали биредә 1931–1937 елларда яшәгән була. Бу тактаның да гыйбрәтле тарихы бар, ул ахыр чиктә өч тапкыр яңадан куела, караклар корбаны булып ала.

Казанда хәзер Гомәр Галине хәтерләткән мемориаль такта да, аның исемендәге урам да бар. Язучының мирасын туплау, таныту, тарихта калдыру эшен Гомәр Галинең апасының улы – журналист Мөбарәк Мусин башкарып чыкты. Ул һәм данлыклы нәселнең башка вәкилләре, шул исәптән язучының кызлары алып барган мирас саклау эше искиткеч зур әһәмияткә ия.

Озак еллар дәвамында Гомәр Гали җирләнгән зират Красноярск сусаклагычы төзелгән вакытта су астында калган дип санала иде. Бәхеткә, бу алай булып чыкмады. 2019 елда хәзер инде юкка чыккан Подпорожье авылы янындагы ташландык зират та, анда ятим булып торган Гомәр Гали кабере дә табылды. Дүрт ел элек бу каберлектә таш та, чардуган да барлыкка килде. Бу эшләрне оештыруда Красноярскиның «Яр» татар оешмасы җитәкчесе Вәгыйзь Фәйзуллин башлап йөрде.

Нинди генә чор булмасын, сәяси золымның төп максаты – исемне тарихтан җуйдыру. Тарих өчен көрәштә Гомәр Гали исеме җиңеп чыкты дип һич шикләнми әйтә алабыз-дыр. 2025 елда Гомәр Галинең тууына 125 ел булачак. Бу уңайдан Казаныбызда музей күргәзмәләре дә, истәлек чаралары да, фәнни конференцияләр дә үткәрелми калмас, дип ышанабыз.

Гомәр Гали белән Хәсән Туфан. Фото Милли-мәдәни үзәк музееннан алынды.

ГАЛӘМ БЕЗНЕҢ БЕЛӘН СӨЙЛӘШЕРГӘ УЙЛАСА... БЕЗ ӘЗЕРМЕ?

Луиза Янсуар

Галәм өчен көрәш һәм ярыш чорлары яңа форматта кабатланамы, әллә безне бу тема белән башка мәсьәләләрдән игътибарны читкә юнәлтеп торырга чакыралармы? Моңа җавапны тиз генә табып булмас кебек, әмма 2021 елда Юлия Пересильд космоста булып кайтып, экраннарга «Вызов» чыкканнан бирле, «Бөек Билгесезлекне» хатын-кыз күзлеге вә тойгылары аша ваемлау модага әверелеп килә, диярсең. Apple TV+ белән Netflix 2024 елда берьюлы ике галәми сериал тәкъдим итә, һәм аларның икесе дә бу темага үзенчәлекле якын килүе белән игътибарга лаек.

Фотолар: kinopoisk.ru, goodfon.ru

- Егерме бер...
...утыз...
...хәлләр мөшкелләнә.
Сез ник дәшмисез?
Тирә-якта – ут...
Ут! Ут!
Капсула яна.
Егерме бер...
Егерме бер...
...утыз, кырык, кырык ике...
Тирә-якта – ут...
Ут! Ут!
...утыз, кырык, кырык ике...
Мин пешәм... Миңа эссе!
Дөньяның асты-өскә килде.
Хәлләр мөшкелләнә.
Сез ник дәшмисез?!

ДӨНЬЯНЫҢ ИКЕНЧЕ ЯГЫНДА

Исеме: «Созвездие» (Constellation)

Иле: АКШ, Бөекбритания, Франция

Жанры: фантастика, триллер, детектив

Сценарий авторлары: Питер Харнесс, Шон Яблонски

Режиссерлары: Джозеф Седар, Оливер Хиршбигель, Мишель Макларен

Актерлар: Нуми Рапас, Джонатан Бэнкс, Джеймс Д'Арси, Рози Коулман, Давина Коулман, Джулиан Лооман, Уильям Кэтлетт, Барбара Зукова, Генри Давид, Чило Чанг һ.б.

Дөньякүләм премьерасы: 2024 елның 21 феврале

Сезоннары һәм эпизодлары: 1 сезон, 8 эпизод

Кино тәнкыйтьчеләре бу сериалны соңгы ярты гасырда фантастика жанрында дөнья күргән иң яхшы мисалларга таяна, дип исәпли. «Расёмон» белән «Гравитация»не искә алалар, «Живой» белән «Интерстеллар»га, «Проксима»га да ишарә ясыйлар, Харнесс белән Маклареннның бу өлкәдәге тәҗрибәсен ассызыклыйлар. Ләкин бу фантастика совет чоры белән «салкын сугыш» чорында экраннарга чыккан кайбер картиналардагы психологик элементларны да исәпкә ала, моннан тыш, нуленче елларга да сәлам бирә: ирексездән, «Сфера» искә килеп төшә. Триллер форматын да аклый.

Нуми Рапас психологик киеренкелекне яхшы тота: менә без кышкы төнге трасса буйлап баручы автомобильне күрәбез. Рульдә – Рапас героинясы, Джо, арткы урындыкта – аның кызы Элис. Магнитолада рус телендә кат-кат кабатлана торган сүзләр яңгырый, аларны ниндидер хатын-кыз кабатлый: «Капсулада – ут... Егерме бер... Дөньяның – астыөскә...» Бала, кызыксынып, сорый: «Нәрсә ди ул апа?» Джо аңа рус теленнән сүзләрне тәрҗемә итә: «Дөньяның асты-өскә килде, ди...»

Һәм менә алар урман эчендәге бер өйгә килеп җитә. Анда кереп урнашалар, һәм беренче сәерлекләр башлана: Джо Элисны йокларга сала, әмма шунда ук аны йокламаган халәттә күрә. Асылда, Элислар – икәү, һәм Джо кызына: «Әйдә, синең икенче синеңне эзләп табарга кирәк!» – ди. Баланы буран эченә урманга алып чыгып китә...

Дөньяның, чыннан да, асты-өскә килә, әмма без әле аңламыйбыз – бу бары тик әни кешенең психологик халәте генәме, әллә?

Ә аннан безгә флешбеэклар бирә башлыйлар, һәм картинаның тулы масштабы бераз ачыларак төшә: Джо – яңа гына МКС тагы миссиясен үтәп кайткан астронавт, ул посттравматик халәттән чыгарга тырыша, тикшерүләр һәм протокол өчен булган җыелышлар

аны тагын да ныграк талкый гына. Җитмәсә, ул җиргә исән-имин әйләнеп кайтканнан соң, Джо белән бергә галәм турында кайткан хакыйкать күпләр өчен уңайсыз, хәтта ки әйтергә ярамый торган булып чыга. Тора-бара ул бөтенләй аңламый башлый: кемгә ышанырга була да, кемгә – юк. Һәм бу – аның тормышымы? Бу – ул яшәгән чынбарлыкмы? Юк, юк, алай гына да түгел, бу – гомумән, чынбарлыкмы?!

NASA БЕЛӘН «РОСКОСМОС» ЯШЕРЕП САКЛАГАН МӘГЪЛҮМАТЛАР КЕШЕЛЕККӘ АЧАР ӨЧЕН ЯРАКЛЫМЫ? ӘЛЛӘ БЕЗ АЛАРНЫ БЕЛМӘСӘК, ТЫНЫЧРАК ЙОКЛЫЙ АЛЫРБЫЗМЫ?
Кинопоиск рецензияләреннән

Космосның һәрчак сәясәт белән турыдантуры бәйле булуы – аермачык билгеле факт. Бу тема һәм әдәбият, һәм кино сәнгате өлкәсендә дә күп тапкырлар чәйнәлде, манипуляцияләр өчен тәмле тәгам буларак файдаланылды. Монда да андыйга урын бар. Халыкара космик станциядә чагында Джо һәм аның белән бергә булган команда көтелмәгән хәлгә юлыга – аларга нидер килеп бәрелә. Аварияда астронавтларның берсе һәлак була, калган өчесе «Союз-2» корабына эвакуацияләнә. Тагын бер челнок – «Союз-1» – җитди зыян күргән булып чыга, Джо аны төзекләндерергә алына, һәм ахыр чиктә, тикшеренү капсуласын алып, аның белән Җиргә әйләнеп кайта. Аларның бит эксперимент нәтиҗәләрен югалтырга хакы юк...

Сериалның сюжет линиясендәге төп конфликт Джоның ачык галәмдә рус хатын-кыз космонавты җәсәде белән «йөзеп йөргән» капсулага юлыгуы һәм, кайткач, бу сенсацион, сәяси яктан берәүгә дә файдалы булмаган дөреслекне ачып салуы. NASA белән «Роскосмос» җитәкчелеге, яшерен махсус хезмәтләр, күләгәдәге инвесторлар гына түгел, ә аның белән бергә булган астронавтлар да төгәл белми: бу – чынмы?! Хәтта Джо үзе дә шикләнә – бәлки, ул галлюцинацияләрен чын дип кабул итә башлагандыр?

«Созвездие» кешеләрнең галәмне өйрәнүдә бары тик ресурс һәм теләсә кайсы моментта «сызып ташлау», ликвидацияләүгә дучар ителергә мөмкин ресурс булуы темасына аеруча басым ясый. Бу – асылда фән дә, тикшеренүләр, югары ниятләр белән максатлар өлкәсе дә түгел, ә әлеге дә баягы «яшерен көрәш»нең инде кат-кат корпорацияләр, магнатларга сатылган вариациясе. Әмма бу сату-алуларның бәясе бардыр бит, дип сорыйсы килә кино геройларының да, безнең, караучыларның да.

Анысына җавапны чираттагы сериал бирәдер, бәлки...

БЕЗ КЕМГӘ НӘРСӘ ИСБАТЛЫЙБЫЗ?!

Исеме: «Сигнал» (Das Signal)

Иле: Германия

Жанры: фантастика, триллер, драма, детектив

Сценарий авторлары: Флориан Давид Фиц, Ким Циммерман

Режиссерлары: Себастьян Хилгер, Филипп Лайнеман

Актерлар: Флориан Давид Фиц, Пери Баумайстер, Юна Беннетт, Хади Ханъянпур, Шиба Чадха, Катарина Шюттлер, Нилам Фарук, Мерет Беккер, Михаэль Кранц, Уве Пройсс һ.б.

Дөньякүләм премьерасы: 2024 елның 7 марты

Сезоннары һәм эпизодлары: 1 сезон, 4 эпизод

...Һәм менә көннәрдән бер көнне иксез-чиксез галәм билгесез, дөресрәге, инде «салкын сугыш» чорыннан бирле кулланылмый торган искергән бер канал аша безгә сигнал җибәрә. Инглиз телендә чатнатып «Сәлам!» – ди ул һәм... бала тавышы белән сөйләшә башлый. Бу очракта нишләргә?!

Флориан Дэвид Фитц «Сигнал» мини-сериалының сценариен язганда, иҗтимагый темаларга, социаль яктан борчып торган сорауларга ничек итеп уен киносы, асылда, мейнстрим аша җавап эзләргә икәнен анык күздә тоткан – әнә шундый тәэсир кала. Әмма ул бер үк вакытта интеллектуаллар өчен дә актуаль, мавыктыргыч була алырдай сценарий тудырган.

Дөрес, биредә космоска әзерлек белән анда барып-кайтулар күршедәге Европа иленә йә булмаса штатка (безнең очракта – районга була инде) чыгып керү кебегрәк кенә тоела... әмма теләсә кайсы кинода, бигрәк тә профессиональ өлкәләрне чагылдырганда, була торган чатаклыклардан кала, «Сигнал» бик кызыклы, сыйфатлы эшләнгән һәм киеренкелекне ахыргача яхшы тота. Асылда, ул үз алдына астронавтларның космостагы тормышын һәм һөнәри эшчәнлеген яктыртуны үзмаксат итеп куймый да. Бу картинаның төп фикри һәм психологик

лейтмотивы – без, үзебезнең җиребездә яшәешне тәртиптә тота алмаганны, космоска чыгып китеп һаман да ни эзлибез һәм кемгә нәрсә исбатлыйбыз?

Галәмнең «Сәлам!» диеп, бала тавышы белән эндәшүе астронавт Паула белән аның үзе кебек үк фән белән шөгыльләнә торган ире Свен тормышын баштанаяк әйләндереп ташлый. Бу сәламләү бигрәк тә үзәк өзгеч тоела, чөнки Свен белән Пауланың 10 яшьлек бик акыллы кызлары Чарли – саңгырау. Ул колак аппараты аша гына ишетә. Әмма Чарлида башкаларны гына түгел, дөньяда булачак хәлләрне дә алдан сиземләү сәләтенә тартым нидер бар... Ул әнисенең чираттагы космик очышының да гадәти генә очыш булмавын алдан ук тоемлап куя. Астронавтлар, үз миссияләрен башкарып, җиргә кайтканнан соң, аларның кайтуын МКС зур экраннарда күрсәткәндә, әниләрен көтеп торган Чарли, иң беренче булып, әтисенә сак кына пышылдый: «Әни бик сәер... ул үзен башкача тота, һәрвакыттагыча түгел...»

Станциядә астронавтларны һинд миллиардершасы, Көнбатыш һәм Көнчыгыш гаммәви мәгълүмат чараларында дөньякүләм билгеле фәнни ачышларга, социаль проектларга ярдәм күрсәтүче филантроп, «күләгәдәге спонсор» булган Бениша Мудхи каршы ала. Аларның бу миссиягә баруын, космоска очуын нәкъ менә ул финанслый. Әмма галәмдә бала «сәлам»ен тотып алган Паула белән икенче астронавт Хади арасында киеренке тартыш башлана: кем шифрны

> БУ СЕРИАЛНЫ «ИНТЕРСТЕЛЛАР» ФАНАТЛАРЫНЫҢ ҺӘРБЕРСЕ ДӘ КАРАРГА ТИЕШ.
>
> **Киноафиша сайтыннан**

беренче булып чишә дә, координаталарны белә... Пауланың кайтканда протоколны тиешенчә үтәмәве дә МКСта зур гауга кубара һәм тикшерү эшләре башларга, җинаять элементын ачыкларга зарурлык тудыра.

Пауланың ире Свен белән кызы Чарлига әниләрен экраннан тыш күрү инде насыйп булмый. Аэропортта АЕ 7606 рейсын зарыгып көткән 170 кешегә туганнарын, якыннарын каршыларга да... Башта рейс кинәт, уйламаганда, радарлардан юкка чыга, аннары аның шартлавы һәм барлык пассажирларның да һәлак булуы турында хәбәр итәләр. Әмма Чарли өйләрендә көне-төне космостагы әнисе белән сөйләшә торган прибордан бер адым да читкә китәргә ризалашмый, ул аның үлеменә ышанмый.

Сериал Мёбиус тасмасы кебек эффектка ия: без дә колакта туктаусыз яңгырап торган «сәлам»нең тора-бара әллә чынлап та Чарли тавышымы дип шикләнә башлыйбыз... Һәрхәлдә, режиссер бу гаҗәеп эффектны ахыргача саклый, шул рәвешле фильмның драматик тирәнлеген дә билгели. Колакка саңгырау баланың, өйләрен репортерлар уратып алып, әниләрен җинаятьче дип гаепләп, ишекләрен йолыкканда да, космоска күз текәп, әнкәсен ишетергә өметләнеп утыруы, һәрхәлдә, безнең амбицияләр белән җинаятькә корылган чынбарлык белән тагын кайсы чиккә барып җитәргә мөмкин икәнлегебез хакында уйланырга чакыра түгелме?..

«Сигнал» сериалының азагы – үзе бер сюрприз һәм десерт. 4 эпизод дәвамында барлык сәяси һәм көч структуралары, ГМЧ вәкилләре Свен белән Чарлины эзәрлекли, биктә тота. Алар Паула алган сигнал чит планета вәкилләре төшәчәк дата белән координаталарны билгеләгән һәм аны ире белән кызына хәбәр иткән дигән позициядә тора. Чарлиның кулына кара шариклы ручка белән язылган координаталар буенча консилиумнар җыела, әгәр космостан ниндидер «килү» була калса, дөнья державаларының инде карары анык: шунда ук һөҗүм итәргә һәм объектны юкка чыгарырга. Югыйсә Чарлиның иреннәре үзен уратып алган өлкәннәргә гап-гади бер хакыйкатьне пышылдый: «Ул бит безгә сәлам бирә, янамый...»

Әмма бу акыллы кыз белән аның этисе әниләренең серен барыбер саклап кала ала. Финалда алар икәүләп очрашу көтеп атлаган буш чүлнең атмосферасы «Нәни принц» манзараларын хәтерләтә, ә Чарли үзе – Бәләкәч Төлкене.

Әниләре аларны гына кайгыртып калмаган, барысын да исәптә тоткан булып чыга, әмма барыбер дә бер нәрсәне оныткан – 1977 елда «Вояджер-1» белән «Вояджер-2» аппаратларына беркетеп Галәмгә җибәрелгән алтын пластинкаларны... Т

> «Вояджер-1» һәм «Вояджер-2» аппаратларына беркетелгән пластинкалар – Космос тузанына эләккәч эрозиядән саклансын өчен алтын йөгертелгән һәм алюминий футлярга урнаштырылган аудио-, видеоязмалар. Пластинка белән бергә футлярга фонографик капсула белән язманы тыңлар өчен энә дә беркетелгән, шулай ук – куллану инструкциясе.
>
> Пластинкаларда 55 актуаль һәм үле телдә сәламләү яздырылган, шул исәптән – шумер, аккад, хет, арамей, борынгы грек, латин, әрмән, Азия телләрендә, 4 Кытай диалектында. Аудиоязмаларның 78% төрле мәдәниятләрнең төп шедеврларын үз эченә ала. Биредә Бах, Бетховен, Моцарт, Стравинский, Луи Армстронг, Чак Берри һ.б. бөекләр белән берррәттән, Һиндстан, Ява, Япония, Кытай, Перу, Африка, Яңа Гвинея, Азәрбайҗан, Америка индеецлары һ.б. культураларның музыкасы да бар.
>
> Калган 22% язмалар төрле кешеләрнең тавышларыннан гыйбарәт: БМО генераль секретаре сәламләве, төрле ил вәкилләренең яздырылган сүзләре, океан белән Җир һәм анда яшәүче җан ияләренең авазлары. Аудиосигнал буларак кодлаштырылган 116 сурәт.
>
> Бортларына урнаштырылган алтын пластинкалар белән бергә әлеге аппаратлар, рәсми чыганаклар буенча, ел саен Кояштан 3,6 һәм 3,3 атмосфера берәмлегенә ераклашуын дәвам итә. Аларның хәзерге вакытта кайсы урында икәнлеген белергә теләүчеләр космик зондларны NASA сайтында реаль вакытта күзәтә ала.

Татарстан авылары

ИСКЕ КАМКА: ЧИШМӘ АГЫШЫНА КУШЫЛЫП...

ИСКЕ КАМКА

Фото: Лилиана Вәлитова

Әлки районының Иске Камка авылы. Киң урамнар ямь-яшел булып утыра. Һәм ник бер чүп үләне булсын! Хәтта кеше яшәмәгән йортлар тирәсе дә ялт иткән. Урамнар болын уртасына урнашкан диярсең: күзне иркәли. Күрәсең, мал асрамый халык, дип уйлаштык. Ялгышканбыз, асрыйлар икән, йорт саен кимендә икешәр сыер. Алайса сәбәп нәрсәдә соң?

Руфия Фазылова

ТУГАН ТУФРАКНЫҢ ТАРТУ КӨЧЕ

Иске Камка җирлегенә тагын ике авыл керә: Яңа Камка, Карамалы. Шуларның иң зурысы Иске Камка. Бирекдә 198 кеше яши, 66 хуҗалык бар.

Авылның яшел киң урамнары бер гаҗәпләндерсә, чишмәләре янә шаккатырды: алар барысы да каралган, матур итеп эшләнгән. Авыл эчендәгеләре дә, читтәрәк урнашканнары да «өйле» булган. Алай гына да түгел, ял итү өчен өстәл-урындыклар ясалган. Бу иганәче ярдәме белән башкарылган изге эш икән:

– Хөрмәтле авылдашыбыз, Иске Камкада туып үскән, берара бирекдә совхоз бригадиры булып эшләгән Ришат Хатыйпов авылыбыз чишмәләрен шулай карап, барлап тора, – диде Иске Камка авыл җирлеге башлыгы Фәргать Әкбәров. – Бездә халык суны чишмәдән ала, гомергә шулай булган. Шәһәрдән кайтучылар да суны авылдан алып китә.

1

Агач-куак арасында калган, кереп булмаслык хәлгә килгән чишмәнең тирә-юнен тотып алып, Ришат Хатыйпов ял итү урыннары ясаган.

Чишмәләр ял итү урыны да икән. Җәен атна саен мәҗлес үткәрәләр, хәтта күрше авыллардан да киләләр.

– Ял итүчеләргә бер генә таләп – үзләреннән соң җыештырып калдыру. Чүп өчен махсус зур савыт куйдык,– диде Иске Камка авыл җирлеге башлыгы. – Матурлыкны булдыру гына түгел, сакларга да кирәк, монысы инде үзебездән тора.

Әйткәнемчә, биредә һәр чишмәнең «өе» бар. Янына матур итеп язу да эленгән: «Мәктәп чишмәсе», «Катык чишмәсе», «Әниләр чишмәсе»... Ә менә авыл башындагысын «Ришат чишмәсе» дип атаганнар. Сәбәбе бик гади: Ришат Сәхабетдин улы, агач-куак арасында калган, кереп булмаслык хәлгә килгән чишмәнең тирә-юнен тотып алып, ял итү урыны ясаган. Чишмә чыганагын башта чистартып, аннан соң тимер-бетон бождралар төшергәннәр. Саркып кына яткан чишмә бер мизгелдә зураеп, киңәеп киткән. Бүген ул – халыкның иң яраткан урыны.

– Бу чишмә күңелгә аеруча якын, чөнки шуның суын эчеп үстем. Печән өсте вакытында шифалы сулары сусауны баса, беләккә көч өсти иде, – диде иганәче Ришат абый. – Туган авылыма хөрмәтем бик зур. Инде әти-әни исән булмаса да, еш кайтып йөрибез. Тамырлар биредә бит. Авыл җирлеге башлыгы Фәргать Әкбәров белән гел элемтәдә: берәр киңәш, ярдәм кирәк булса, мөрәҗәгать итә. Кое-чишмәләрне дә бергәләшеп төзәттек. Авылдашлар белән дә мөнәсәбәт бик җылы. Кеше кайда гына яшәсә дә, туган туфрак иң кадерлесе, иң газизе була икән...

«ЕЛЫНА УНБИШ-ЕГЕРМЕ ЙОРТ САЛЫНДЫ»

Иске Камкада башлангыч мәктәп, балалар бакчасы бар. Тегесендә дә, монысында да алтышар бала. Әлбәттә, авыл халкы моңа борчыла: белем-тәрбия үзәге ябылса, авыл ятим

2

Клуб хезмәткәрләре авылның токтасы: мәдәни чараларны оештыру, өмә ясау, башка эшләр – барысын да карап, барлап торалар.

3

«Татарстанның атказанган механизаторы» исеме булган Әсгать Гыйбадуллин 77 яшен тутырган.

кала. Дөрес, киләсе өч-дүрт елда андый куркыныч янамый, әмма авылда ел саен бер бала тууны исәпкә алсак, барысы да аңлашыла...

2004 елда төп белем бирү мәктәбе дип ачылган бина бүген дә бер дигән. Мәктәп һәм бакчадан тыш, биредә хәзер китапханә, ФАП, авыл җирлеге идарәсе урнашкан. Ә менә клуб аерым, ул яңа, заманча. Аны 2017 елда дәүләт программасы нигезендә салганнар. Биредә эшләүчеләр авылның токтасы: мәдәни чараларны оештыру, өмә ясау, башка эшләр – барысын да карап, барлап торалар.

Авылның хөрмәтле кешесе Әсгать абый Гыйбадуллин белән дә авыл клубында очраштык. «Татарстанның атказанган механизаторы» дигән мактаулы исеме булган Әсгать абый 77 яшен тутырган. Улы, килене, оныклары белән бергә яши. Кызганычка, гомер иткән җәмәгате мәрхүм булган.

– Колхозлашу чорында, ягъни 1930 нчы елларда Иске Камкада өч йөздән артык йорт була, 1 меңгә якын кеше яши, – диде Әсгать абый. – Бөек Ватан сугышыннан соң авылда халык саны бик кими, йөзгә якын кеше фронттан кайтмый, читкә китүчеләр дә күбәя. Без исә менә шулай гомер буе туган авылда яшәдек. Күп вакыйгалар әле дә истә. 1957 елда безнең «Нептун» колхозы «Энергетик» совхозына керде. Менә шуннан соң тормышлар күзгә күренеп яхшырды. Безне тулысынча хөкүмәт кайгыртты. Төзелешләр башланды: Иске Камкада гына да өч төзелеш бригадасы бар иде. Ел саен авылда унбиш-егерме йорт салынды. 1964 елда авылга электр керде. Зур шатлык иде ул. Бөтен яшьләр авылда калды, күпләр фермада эшләде. Хәтерлим, апам Казанга барып сыерлар куып кайтты.

Төрле сәбәпләр аркасында Иске Камка 1983 елда совхоздан чыга һәм янә колхоз оеша. Ул «Кызыл байрак» исемен йөртә. Аннары тагын «Камка» совхозына берләшәләр. Бүген биредәге җирләр «Кызыл Шәрык Агро» акционерлык җәмгыятенә карый.

– Кырык ел колхозда эшләдем, – дип дәвам итте Әсгать абый. – Сагынам шул чакларны. Безнең авыл тырыш, эш сөючәнлеге белән аерылып торды. Авылларның бетә баруына бик борчылам. Ничек булса да яшьләрне калдырасы иде. Дәүләт тарафыннан берәр программа, кызыксындыру чарасын уйлап тапсыннар иде. Шулай дип яз әле. Менә мин 1963 елда, Болгар авыл хуҗалыгы училищесын тәмамлап, совхозга эшкә кайттым. Өр-яңа трактор бирделәр, соңрак йорт салырга ярдәм иттеләр. Хезмәт хакыбыз яхшы иде, яшь кешегә тагын ни кирәк? 2007 елга кадәр шулай тракторда эшләдем...

Татарстанның атказанган механизаторы бүген дә хәленнән килгәнчә улы, килененә булышырга тырыша. Бу гаиләдә гомергә күп итеп мал асраганнар, бүген дә җиде-си-

3

4
Зәйтүнә белән Фәргать Сәгыйровлар икесе дә лаеклы ялда, шуңа да карамастан ихата тулы мал-туар асрыйлар.

гез баш сыер, сарыклар, тавык-чеби... Кыскасы, алма алмагачыннан ерак китмәгән, тырыш гаилә һаман да сафта.

АШЛЫ ДА, ЭШЛЕ ДӘ...

Иске Камкада мал асраучылар күп. Берничә гаилә шәхси ярдәмче хуҗалык булып теркәлгән. Үзе өчен генә биш-алты сыер асраучылар да байтак. Шундыйларның берсе – Сәгыйровлар. Фәргать абый белән Зәйтүнә апа икесе дә лаеклы ялда, шуңа да карамастан ихата тулы мал-туар: ике сыер, үгезләр, кырыкка якын сарык, тавык, чеби... Өч кыз үстергәннәр, өчесе дә кияүдә, алты оныклары бар.

– Чебиләрне гомер буе бер тәүлеклекләрне алабыз. Быел алтмышны алып кайттык, йөзәр баш чеби үстергән еллар да була, – диде Зәйтүнә апа. – Авыл җирендә ничек терлек асрамый, кош-корт үстерми яшисең инде?! Кыз-кияүләр, оныкларыбызны да сыйлыйсы килә.

Танышкач та игътибар иттем: ир белән хатын, аңлашып, бер-берсен тулыландырып яши. «Без» дип сөйләшәләр, бер-берсенә елмаеп карыйлар...

Йорт-җирләре төзек, бакчаларында ниләр генә үсми. Барысын да икәүләп эшлиләр икән. Җәен иртәнге дүрттә торалар, кичке унга кадәр бакчада, маллар янында.

– Алтмыш бишне тутырсак та, һич кенә дә картаясы килми, – диде гаилә башлыгы. – Гомергә хезмәт яратып яшәдек. Кайда гына эшләмәдем: зур йөк машинасын да йөрттем, электрик та булдым, пилорама, ягулык станциясе – эшләмәгән җир калмады бугай. Берьюлы өчәр җирдә хезмәт куйдым. Андый кеше лаеклы ялга чыккач та тик утыра алмый икән ул...

Тик утыра алмаучы тагын бер гаилә – Ләйсән белән Радик Сәгетдиновлар. Биредә дүрт ир бала үсә: Самат, Әмир һәм игезәкләр Дамир белән Данир. Зурраклары мәктәптә укыса, игезәкләргә әле ике яшь тә тулмаган. Авылда яшәүче биш-алты яшь гаиләнең берсе. Сәгетдиновлар дәүләт программасы нигезендә мини-ферма салган. Аның өчен 600 мең сум грант биргәннәр. Гаилә башлыгы Радик авылдагы агрофермада тракторда эшли, Ләйсән әлегә балалар белән өйдә.

– Барысын да җәмәгатем белән бергә эшлибез, – диде Радик. – Терлек саны да күп, сигез савым сыерыбыз бар. Бозауларны үстереп тә, кечкенә чагында да сатабыз. Менә җиребез юк. Документ эше күп, шуның өчен артыннан йөрергә куркып торабыз. Алга таба уйлыйсы булыр, район администрациясе каршы килмәс, дип уйлыйм.

– Улларыбыз бик зур ярдәмче, – дип сүзгә кушылды Ләйсән. – Бөтен эшне беләләр. Җәй көне этиләре кырда, терлекләрне күбрәк Самат карый. Әмир исә энекәшләре янында. Миңа ашарга пешерергә, бакчаны карарга кирәк. Кыскасы, безнең гаиләдә бөтен кешегә эш җитә.

Чынлап та шулай: ишегалды тулы тавык, каз, күркәләр... Чын мини-ферма бу! Өйләр салып, Сәгетдиновлар шулай хәләл көч белән яшәп ята. ШЯХ булып теркәлгәннәр. Киләчәктә тагын да зураерга ниятлиләр.

«ХӘЛДӘН КИЛГӘНЧӘ ТЫРЫШАБЫЗ!»

Чираттагы гаилә – Сафиннар белән соңрак таныштык. Авыл җирлеге башлыгы Фәргать Әкбәров бу гаиләнең тарихын сөйләгәч, үзләрен бик күрәсе килде.

Ирле-хатынлы Бриллиант белән Рамил Сафиннар ике ир бала үстерә. Олы уллары Ранилга егерме өч яшь, төпчекләре Рәзилгә ун тулган. Авылдашларыннан аермалы буларак, Рамил Сафин сөтне көн саен район үзәге Базарлы Матакка алып барып сата. Сөтен генә түгел, эремчек, кортын, катыгын да – аларын җәмәгате Бриллиант ясый. Барысы да гадәти кебек, тик ир белән хатын икесе дә тумыштан церебраль паралич диагнозлы. Шуңа карамастан сау кешеләрне уздырып яшәп яталар. Капка төбендә өч җиңел автомобиль, трактор, печән җыя торган җайланма, сука, чәчкеч тора, кыскасы, авыл хуҗалыгында кирәк булган бөтен әйберләрне сатып алганнар. Утыз сигез гектар җирләре бар. Печәнен, игенен чәчәләр. Үзләреннән арткан иген, печәнне авылдашларына да саталар. Боларның барысын да олы уллары Ранил эшли икән.

– Улыбыз иртә яздан кара көзгә кадәр кырда инде, – дип сөйләде ата кеше бер горурлык белән. – Дүрт ел автотранспорт техникумында укыды. Хәзер безнең янда яши, шәһәрне яратмады. Рәсми рәвештә ул безнең опекун санала. Аллаһка шөкер, Бриллиант белән хәлдән килгәнчә тырышабыз. Әле өйдә эни дә бар, 88 яшен тутырды. Узган ел сукырайды, урын өстендә инде. Җәмәгатем аны да карый...

Ул да түгел Бриллиант үзе дә килеп чыкты: шат күңелле икән. Көн дә биш сыер сава, әле ел саен йөзләп чеби, бәбкәләр үстерә. Ике ел элек 250 каз үстереп, хуҗа аларны Казанда ярминкәдә сатып бетереп кайткан.

– Казларны кайнанам белән йолкыдык, ул чагында энинең күзләре күрә иде әле, – диде Бриллиант.

5

Сафиннар гаиләсе. Сау кешеләр зарланышып яшәп ятканда, ДЦП диагнозлы кешеләр бер диган итеп тормыш алып бара...



– Ничек таныштыгыз? – дим ир белән хатынга.

– Лениногорск якларына шифаханәгә барган идем, – диде гаилә башлыгы. – Шунда миңа Бриллиант турында әйттеләр. Өйләренә барып таныштым, бик ошаттым. Аннары өч ел буе хат алыштык. Лениногорскида никах укытып, Бриллиантны үзебезгә алып кайттым.

– Кулымны сорарга Рамил әнисе белән килде, – дип дәвам итте Бриллиант. – Балдаклар да алган иде. Монда кайткач, зурлап туйлар да ясадык. Егерме өч ел узып киткән инде, Аллаһка шөкер, матур яшибез. Иң мөһиме – ике улыбыз сау-сәламәт һәм бик акыллы. Ранил да, инде хәзер Рәзиле дә кечкенәдән мөстәкыйль булды. Бөтен эшне беләләр. Безнең төп ярдәмчеләр, бервакытта да каршы килгәннәре дә юк.

– Икенче балагызны кырык дүрт яшендә тапкансыз икән. Табиблар нәрсә диде? – дим.

– Нәрсә дисен, куркып калдылар инде. Ә мин курыкмадым. Без бит икебез дә туганда гарипләнгәнбез, нәселдән килгән чир юк. Шуның өчен улларыбыз да сәламәт.

Ранил белән танышып булмады, ә менә Рәзил белән күрештек. Кем әйтмешли, мондый балалар да булыр икән. Олылардан акыллы сөйләшә: өйдә кайда нәрсә ята, барысын да белә. Ихаталары буенча экскурсия үткәрде. Әле безгә кисәтү ясады:

– Апа, электропастухка орына күрмәгез, ток тотмасын. Каты чеметтерә ул.

Бу малайның үткенлегенә, белдеклелегенә ис китте...

– Рамил белән бер класста укыдык, – дип сүзгә кушылды авыл җирлеге башлыгы Фәргать Әкбәров. – Башта сигез ел үзебезнең авылда белем алдык, аннары ике ел Алпар мәктәбенә йөрдек. Рамил көн саен биш чакрым безнең белән укырга йөрде. Әле алай гынамы, сигездә укыганда ук, Чистай базарына барып, сарык йоны сата иде. Яшьтән шулай үткен булды. Әниләре Зәйтүнә апа гомер буе фермада сыер сауды. Бу нигездә гел шулай күп итеп мал асрадылар, булдыклы гаилә. Районга җыелышларга баргач та, аларны үрнәк итеп китерәм. «Сау кешеләр зарланышып яшәп ятканда, ДЦП диагнозлы кешеләр бер дигән итеп тормыш алып бара. Ышанмасагыз, килеп күрегез», – дим.

6

Иске Камка авылы китапханәсе мөдире Гөлнур Вәлиева.

...Җирле халык белән танышкач, Иске Камка авылындагы чисталыкның серен белдек: тырышлык. Беренчедән, чүпләмиләр, икенчедән, һәр кеше үзенең капка, койма буйларын чистартып, үләнен чабып тора. Монда халык тик утыра белми... Әнә, май чүлмәге тышыннан билгеле: урамнан ук ялт иткән.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

– Авылда сакланган риваять буенча, Камка исемле әби, бу якларны күргәч: «Менә ул Камка», – дип әйткән. Камка исеменең мәгънәсе – «көнчыгыш халыклар арасында киң кулланыла торган нәфис бизәкле ефәк тукыма». Шушы матур исем авылыбызга да бирелгән. Рәсми документларда Камкага 1611 елда нигез салынган дип язылган.

Камка исемле авыллар бер Татарстанда гына түгел. Аның берсе Нижгар ягында, Сергач районының Пьяна елгасы буенда урнашкан, икенчесе – Мордовия Республикасында, Сатис елгасы буенда һәм өченчесе – Татарстанның Әлки районында. Бу өч авыл да үзара бәйләнгән булырга тиеш. Биредә яшәүчеләр Нижгар һәм Мордовия якларына барып урнашкан һәм яңа җирләргә дә Камка исемен биргән, дип фаразлана.

Гөлнур Вәлиева, Иске Камка авылы китапханәсе мөдире.

Татарстан юбилярлары

ЯҢАНЫ БУЛДЫРУ КЫРЫНДА

Марат Җәббаров,
Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры

Туксанынчы еллар ахырының без эшләгән тармак өчен нинди авыр сынау чоры булганын авыл хуҗалыгы ветераннары хәтерлидер әле. 1998 елгы корылыкны чираттагы тагын бер корылыклы ел алмаштырды. Колхозлар тарихка күчте, ә яңалары, хуҗалык алып баруның социалистик формада булмаганнары, әле үзләренә юл ярмаган иде. Хезмәт сөйгән, эш белгән халкы булган авыл үзенең тормыш рәвеше белән кинәт беркемгә дә кирәксезгә әйләнде һәм акрынлап сүнә барды. Республика хакимияте ярдәме белән Татарстанда хәлләр беразяхшырак иде, ләкин монда да авыл халкы алга таба ничек яшәргә дигән сорау алдында калды. Шөбһәләр үз көчеңә ышанмауга китерә. Менә шундый катлаулы вазгыятьтә республиканың авыл хуҗалыгы тармагы җитәкчелегенә Марат Әхмәтов басты.

Аннан соңгы вакыйгалар күрсәткәнчә, Татарстан Республикасының беренче Президенты Минтимер Шәймиевнең исәбе дөрес булып чыкты. Дәвер алмашынганда авыл хуҗалыгы белән идарә итүне яхшы белгечкә генә түгел, авыл халкы өчен җаны авырткан кешегә ышанып тапшырдылар. Марат Готыф улы эшли башлагач, авылларда өмет барлыкка килде. Югарыдагы җитәкче белән дә, гади хезмәт кешесе белән дә тыңдәш булып сөйләшә алган министр ышандыра һәм уңышка юнәлтә белүе өстенә, әйткән һәр сүзе өчен җавап та бирде, вәгъдәсендә дә торды.

Җайлы булды дип әйтү – берни дә әйтмәү. Бердәм тотынсак, авырлыкларны җиңеп буласына нәкъ менә Әхмәтов ышаныч уята алды. Семинар-киңәшмәләр үткәрү тәҗрибәсе ул эшләгәндә барлыкка килде. Бу семинарларда түрәләр һәм авыл хуҗалыгы белгечләре проблеманы хәл итү юлларын бергәләп эзләде. Ә алар, күчеш чорындагы проблемалар, – зурлары һәм кечкенәләре – күпме иде! Хәзер бу хакта хәтерләүчеләр аз, ләкин шундый вакытлар да булды: чәчүлек бәрәңгегә дә кытлык иде, бөртекле һәм башка төрле культураларның элиталы орлыгы турында әйтеп тә торасы юк. Элиталы орлык, бәрәңге, күпьеллык азык үләне, азык чөгендере үстерүчеләр ассоциацияләре – болар барысы да авыл хуҗалыгы тармагы белән Марат Готыф улы идарә иткән вакытта барлыкка килде.

Зур агрокомплекслардан башка гына булмасын аңлаганнан соң, инвесторлар эзләү тагын? Бу масштаблы бурыч та Әхмәтов министр чакта уңышлы тормышка ашырыла башлады. Ә сезонлы авыл хуҗалыгы ярминкәләре? Алар да тормышыбызга Марат Готыф улының җиңел кулы белән кереп китте. Карар кабул иткәнче кешеләрне тыңлый һәм ишетә белү – алмашчыларга Әхмәтовтан тагын бер сабак. Халыкны азык-төлек белән ничек тәэмин итәргә, перспективада әлеге тармакның сәясәте нинди булырга тиеш? Хәтердә әле: бу мөһим сорауларга җавап табар өчен, Марат Готыф улының инициативасы белән, 2000 нче еллар башында бик зур агроконференция оештырылган иде. Анда 700 дән артык кеше катнашты. Шул конференциядә яңгыраган кайбер идея һәм тәкъдимнәр әле бүген дә эшли.

Хөрмәтле Марат Готыфович!

Сезнең туган ягыгыз – икмәкле Арча ягы. Бу як борын-борыннан үзенең язучылары, сәнгать эшлеклеләре, галимнәре, мәгърифәтчеләре, эшсөяр халкы белән данлыклы. Якташларыгыз, авылдашларыгыз Сезнең белән ихластан горурлана. Без дә, Сезнең белән бер дәвердә яшәп, Сезнең кул астында эшләп, Сездән күп нәрсәгә өйрәнергә тырышабыз. Сездән тәҗрибә туплыйбыз, Сез салган сукмактан тайпылмыйча, аны заман таләп иткәнчә киңәйтеп алга барырга омтылабыз.

Бүген республикабызның авыл хуҗалыгы сәнәгате комплексы, аның төрле тармаклары илебездә алдынгы урында тора. Монда Сезнең шәхси өлешегез бәяләп бетергесез зур. Икътисадый яктан авыр һәм катлаулы чорда авыл хуҗалыгы тармагын җитәкләп, республикабызны ил күләмендә лидер итәр өчен никадәр көч куйдыгыз.

Бүген авыл хуҗалыгы тармагы барлык юнәлешләрдә тотрыклы үсә. Нинди генә урында һәм вазыйфада булсагыз да, административ район башлыгы булсынмы ул, авыл хуҗалыгы министрымы яки халык сайлап куйган депутатмы, Сез һәрвакыт кешеләр арасында, күп йөрисез, аралашасыз, халыкның ничек яшәгәнен, ниләр белән кызыксынганын, аларга нәрсә кирәген ишетеп кенә түгел, аларның теләкләрен үзләрен тыңлап беләсез, аларга булышырга тырышасыз. Әти-әниләрегездән күчкән югары әхлак сыйфатларына ия кеше буларак, авылдагы тормышны югары дәрәҗәдә тотарга тырышасыз. Җир-Анага һәм хезмәт кешесенә хөрмәт Сезнең каныгызда.

Ә бүген Сез парламентта эшләп, авыл хуҗалыгы белән бәйле законнар, төрле дәүләт программалары кабул итеп, авыл тормышын яхшы белгән кеше буларак һәм үзегезнең бай тормыш тәҗрибәгезгә таянып, авыл халкы өчен файдалы үтемле тәкъдимнәр кертәсез.

Бүген Сез татар халкы өчен туган телне һәм мәдәниятне саклауга кагылышлы иң мөһим мәсьәләне хәл итәргә алындыгыз. Бу юнәлештә уңай нәтиҗәләр дә күренә.

Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне чын күңелдән зур юбилеегыз – 70 яшьлек гомер бәйрәмегез белән котлыйм. Халкыбызның бүгенгесен һәм киләчәген кайгыртып кылынган күпкырлы һәм бик тә җаваплы игелекле эшләрегез дәвам итсен һәм уңыш китерсен. Чын күңелебездән Сезгә бәрәкәт һәм иминлек телибез. Һәр туар таң Сезгә бик күп шатлык, сәламәтлек, күңел көрлеге алып килсен һәм күркәм исәлекләргә бай булсын.

РЕСПУБЛИКАГА БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР

Югары һөнәри осталык, иң күркәм кешелеклелек сыйфатлары һәм шул ук вакытта һәр яңалыкны кабул итә белү сәләте... Болар чын идарәче өчен кирәкле сыйфатларның кайберләре генәдер әле. Марат Әхмәтов әнә шундый чын идарәчеләрнең бер вәкиле. Моны аның туган төбәге Татарстанга багышланган бөтен хезмәт юлы раслый.

Рафаэль Юнысов,
«Чаллы икмәге» АҖ генераль директоры, РФ азык-төлек сәнәгатенең атказанган хезмәткәре

Марат Готыф улы гомерлек эше итеп сайлаган тармак – авыл хуҗалыгы иң авырлардан санала, кешедән тырыш хезмәт куюны, авыл җиренә тугрылыкны таләп итә. Шуңа күрә Марат Готыфовичның хезмәт эшчәнлегенең һәр этабындагы зур авырлыкларны җиңүе, җаваплылыкны күтәрә белүе белән бергә, күркәм нәтиҗәләргә ирешүе дә сокландыра.

Татарстанның авыл хуҗалыгы тармагын үстерүгә Марат Әхмәтов бөтен тырышлыгын, оештыру осталыгын, киләчәкне күрә һәм тоемлый белү сәләтен җикте. Болар барысы да болгавыр 90 нчы еллардагы кыенлыкларны мөмкин кадәр азрак югалтулар белән җиңеп чыгу гына түгел, ә алга таба нәтиҗәле үсеш өчен этәргеч алырга да мөмкинлек бирде. Инновацияле технологияләр кертү, матди-техник базаны яңарту, киләчәккә йөз тоткан бурычларны уңышлы тормышка ашыра алырлык квалификацияле кадрлар әзерләү – авыл хуҗалыгы тармагында бу юнәлешләрдә җитди адымнар белән нәкъ менә Марат Готыф улы идарә иткән чорда ясалды. Күп яктан аның дөрес җитәкчелек итүе нәтиҗәсендә тармакны үстерүнең өметле программалары тормышка ашырылды. Бүген авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм сату буенча Татарстанның Россиядә иң алдынгы төбәкләрдән берсе булуында Марат Әхмәтовның өлеше саллы. Яуланган бу үрләрнең хәзерге вакытта шәкертләре һәм эшен дәвам итүчеләр тырышлыгы белән тотрыклы калуында, алга таба үсүендә дә аның өлеше шиксез.

Хөрмәтле Марат Готыфович!

«Чаллы икмәге» компанияләр төркеменең зур коллективы исеменнән юбилеегыз белән чын күңелдән котлыйм!

Фидакарь хезмәтегез, Сез турыдан-туры катнашкан тиңсез инновацияле проектларны тормышка ашыруда «Чаллы икмәге» күптармаклы компаниясе белән нәтиҗәле хезмәттәшлегегез өчен рәхмәтебезне җиткерәбез. Тормышыгыз, әлбәттә, ихластан горурланырлык. Җиңү һәм уңышларыгызның нигезе – эшлеклелек сыйфатларыгызда, хезмәткә һәм кешеләргә мөнәсәбәтегездә. Ул елларда бик күп нәрсә эшләнде. Алга таба Сезне республиканы тагын да үстерү максатында Татарстанның Дәүләт Советында мөһим һәм җаваплы эш көтә иде.

Сезгә чын күңелдән сәламәтлек, күңел көрлеге телибез. Әле алга таба да армый-талмый озак еллар хезмәт итәргә насыйп булсын! Тормыштан ямь-тәм табып яшәгез, һәр яңа көн шатлык-куаныч китерсен! Һәм, әлбәттә, янәшәгездә тугры дусларыгыз, фикердәшләрегез, якын кешеләрегез булсын! Сезгә имин, мул, тыныч һәм бәрәкәтле тормыш телибез!

Фото: tatar-congress.org, «Чаллы икмәге» АҖ тарафыннан бирелде. РЕКЛАМА

ҺАМАН ЗУРЛАП ИСКӘ АЛАЛАР...

Балтач районының «Алга» хуҗалыгы: мәгърур таулар уртасына җәелеп утырган Югары Шубан авылына килеп туктадык. Язгы чәчү тәмамланган, бакча эшләре дә беткән – авыл кешесенең аз гына сулу алган мәле... Төзек урамнар аша атлыйбыз. «Заманында әлеге өч урамны Марат Готыф улы салдырды», – диде каршыга очраган ак яулыклы апа. Гаҗәп тә, түгел дә, 40 елдан артык вакыт узган, ә элеккеге колхоз рәисен бирегә һаман зурлап, сагынып искә алалар.

Руфия Фазылова

> Балтачлылар авыл хуҗалыгы өлкәсендә даими тотрыклылык күрсәтә. Балтач республиканың башка районнары өчен үрнәк булды һәм шулай булып калачак.
>
> **Марат Готыф улы Әхмәтов**

«БЕР ЯШЬ КЕШЕ ДӘ АВЫЛДАН КИТМӘДЕ!»

Марат Әхмәтов «Алга» колхозына рәис итеп 1978 елда билгеләнә. Әле егерме бише дә тулмаган егет була ул. Тик авыл кешеләре аны беренче көннән үк якын итә. Ни өчен дигәндә, яшь җитәкченең әти-әнисен яхшы беләләр: авыл мәктәбенең абруйлы мөгаллимнәре бит. Андый тәртипле гаиләдә үскән егет начар да, булдыксыз да булмас...

Һәм алар дөрес уйлый да. Шактый артта баручы хуҗалыкны яшь рәис санаулы вакыт эчендә алдынгылар сафына чыгара. Ә биш ел эшләү дәверендә «Алга» колхозын республикада үрнәк итеп куя башлыйлар. «Марат Готыф улы рәислектән киткәндә, без аны елап озаттык», – ди шубанлылар.

Кырык ел узса да, Югары Шубанда Марат Әхмәтов калдырган эзләр әле дә ярылып ята. Ул салдырган ферма биналары һаман сафта, дөрес, аларга капиталь төзекләндерү ясалган. Әйткәнемчә, авылның урамнары ялт иткән. Ә иң сөенечлесе – Марат Готыф улы белән эшләгән кешеләр исән-сау, алар аңа бүген хәер-догада.

– 1978-1983 елларда авыл чын мәгънәсендә үсте, дөньяга чыкты, – диде Рафаэль абый Хәйретдинов. – Марат Готыф улы килгәндә токарь булып эшли идем, аннан ул мине гаражлар җитәкчесе итеп куйды. Яңа рәис колхозны бик мөшкел хәлдә кабул итеп алды. Җитәкче башта иске ферма биналарын төзекләндерде, техниканы ремонтлаттырды. Иң беренче чиратта колхозда тәртип урнашты. Яңа рәис бөтен нәрсә белән кызыксынды: авылда узган бер концертны да калдырмый иде. Безнең инде ис китте, мондый җитәкче күрмәгән бит. Көн саен иртәнге биштә җыелыш. Һәркемгә сүз бирә, эшен сорый, ләкин бер генә кешене дә кимсетми. Һәм үз дәрәҗәсен дә төшерми иде. Марат Готыф улы бездә биш елдан артык рәис булып торды, бер тапкыр да тавыш күтәргәнен хәтерләмим. Моны мин генә түгел, башкалар да шулай дип әйтә.

Марат Әхмәтов «Алга» колхозына билгеләнгәндә, авылда салам түбәле өйләр дә була. Колхоз рәисе аларны шифердан яптыра. Һәм бер-бер артлы йортлар салдыра башлый! Гаҗәп хәл: 1978–1983 еллар эчендә бөтен яшьләр диярлек авылда кала. Ник дигәндә, колхоз яшь гаиләләргә йорт салып бирә башлыйлар. Бушка!

– Шул чорда авыл бермә-бер артты, – дип, истәлекләре белән бүлеште Рафаэль абый. – Яшәргә урыны, эшләргә эше, яхшы хезмәт хакы бар. Шулай булгач, яшьләр ник читкә китсен? Иң кызыгы: авыл егетләренең күбесе Шубан кызларына өйләнде. 80 нче елларда авылда балалар саны да кисәк кенә артты. Башлангыч мәктәп кенә булган авылда соңрак төп белем бирү мәктәбе ачылды. Әйе, Марат Готыф улы эшләгән вакытлар авылның чәчәк аткан чоры иде.

КИЧӘ КҮҢЕЛЛЕЛЕК...

«Алга» колхозы дәүләт йөкләмәсен икеләтә арттырып үти башлый. Сөт саву буенча ике ел эчендә районның иң алдынгы хуҗалыклары сафына баса. Нәтиҗәдә, яшь колхоз рәисенә яңа эш урыны тәкъдим итәләр – партия район комитетының икенче секретаре итеп сайлыйлар. Марат Әхмәтов тулаем районның авыл хуҗалыгы өчен җаваплы була.

Ике елдан, ягъни 1985 елның гыйнварында Балтач район партия комитетының беренче

Колхоз рәисе яңа өч урам салдыра.

Фото: Лилиана Вәлитова

секретаре – район башлыгы итеп сайлана. Нәкъ Марат Готыф улы килгәч, район тулысынча табигый газ белән тәэмин ителә, барлык авыллар диярлек асфальт юллар белән тоташа. Күп яңа социаль объектлар төзелеп сафка баса... Ундүрт елдан соң Балтачның данлыклы район башлыгын ТР Премьер-министрының беренче урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры итеп билгелиләр. Марат Готыф улы монда да сынатмый – Татарстан авыл хуҗалыгы Россиядә беренчеләр рәтендә була.

Бүген инде Балтач районының горурлыгы булган Марат Готыф улы яңа вазыйфа били: ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыкларның туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре буенча комиссия рәисе ул. Бер карасаң, авыл хуҗалыгы юнәлеше дә түгел... Тик Марат Готыф улын якыннан белүчеләр әйтер: ул чын милләтпәрвар, җыр-моңга гашыйк кеше. (Үзе дә җырлый, гармунда уйный.) Аның өчен «кече Ватан» төшенчәсе буш сүзләр генә түгел.

– Марат Готыфович Балтач, Югары Шубанга эзне беркайчан суытмады, – диде «Алга» авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерү кооперативы җитәкчесе Рәис Әнәс улы Гыйльмуллин. – Хәзер дә шулай: туганлык җепләрен дә нык тота. Авылда юлына очраган кеше белән исәнләшмичә, хәл-әхвәл сорашмыйча китми. Зыялы да, кече күңелле дә ул. Шуның өчен авылда гына түгел, районда да бик хөрмәт итәләр Марат Готыфовичны. Ә без исә ул башлаган эшне лаеклы дәвам итәбез: Балтач районында авыл хуҗалыгы тармагы көчле, колхозлар, хәзергечә әйтсәк, кооперативлар нык...

Рамил Нотфуллин, Балтач районы башлыгы

– Районыбызның бүгенге икътисады нык, һәм аның үсешендә Марат Готыф улы җитәкчелек иткән чор аерым урын алып тора. Уңышларыбыз белән горурланабыз икән, бу җитәкчеләребезнең халык белән аңлашып эшләве нәтиҗәсе, ә аның нигезе нәкъ менә Марат Әхмәтов тарафыннан салынды, дисәк тә ялгышмабыз. Без бүген дә аның саллы киңәшләренә таянып эш итәбез, күмәк хуҗалыкларыбызны таратмадык, аларның киләчәгенә ышандык. Менә бүген районыбызда тәүлегенә 500 тоннага якын сөт савыла, бу бит акча, авыл халкының мул тормышы, дигән сүз. Республикада күрелмәгән хәл: шәхси хуҗалыкларыбыз көн саен 100 тоннага якын сөт тапшыра! Заманында күп районнарда терлекләрнең баш санын киметә башладылар, ә Марат Готыф улы: «Сез ашыкмагыз, хәзер авыр булса да, терлек асрауның файдасы әле булачак», – дип, безгә үзенең дөрес киңәшен бирде. Шул киңәшне тотып, районыбызда ел саен терлек санын арттыра бардык, нәтиҗәсе менә хәзер күренә. Бу очракта да Марат Готыф улының алдан күрә белү сәләте безгә ярдәм итте.

Хуҗалык үзәкләре урнашкан һәр авылга асфальт юл түшәтү, социаль объектларга, шәхси хуҗалыкларга табигый газ кертү, дистәләрчә мәктәп-бакча, мәдәният йортлары, сәүдә үзәкләре салдыру – бу ул район башлыгы булып эшләгән чорның кайбер эшләре генә. Иң мөһиме – ул гади халык белән дә, җитәкчелек белән дә уртак тел таба белде. Күпмилләтле район халкын куелган максатларга ирешү өчен туплый алды. Шуның өчен дә Марат Готыф улын без, балтачлылар, һәрвакыт бары тик хөрмәт хисләре белән генә искә алабыз. Халык мәхәббәтен яулаган җитәкчебезгә бүгенге көндә дә милләтебезнең киләчәге белән бәйле мөһим бурычларны үтәүдә уңышлар, сәламәтлек, тигез гаилә бәхете, бәрәкәтле озын гомер телибез.

КӨЧЛЕ ШӘХЕС – КИҢ КОЛАЧЛЫ ГАМӘЛЛӘР

Рөстәм Равилов,
Н. Э. Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе ректоры, ветеринария фәннәре докторы, профессор

Хөрмәтле Марат Готыфович! Безнең академия коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән ихлас котлыйм!

Безнең арада студент Әхмәтовны хәтерли торган мөгаллимнәр дә бар әле. Безнең уку йортын уңышлы тәмамлаганнан соң, Сез ветеринария табибы һәм район җитәкчесеннән алып, Татарстан Республикасының Дәүләт Советы Рәисе урынбасарына кадәр олы хезмәт юлы уздыгыз.

Татарстанда Сезне барысы да тәвәккәл һәм зирәк җитәкче буларак белә. Республиканың агросәнәгать комплексы үсешенә Сезнең керткән өлешегез бәһаләп бетергесез. Нәкъ менә Сезнең җитәкчелектә Татарстан аграрийлары зур уңышларга иреште: җир эшкәртү өчен шартлы рәвештә тотрыксыз дип санала торган төбәк бүген ил күләмендә авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү буенча алдынгыларның беренче бишлегенә керә, без кайбер көньяк төбәкләрдән генә калышабыз, ә сөт һәм сыер ите җитештерү буенча республика Россия Федерациясендә беренче урында бара.

Сезгә хас хезмәт сөючәнлек, үзегезгә һәм ярдәмчеләрегезгә карата таләпчәнлек, принципиальлек һәм игелеклелек, җаваплылык, зирәклек, һөнәри осталык һәм фикер сөрешенең киңлеге барыбызда да ихтирам-хөрмәт уята, авыл хезмәтчәннәре, авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләре һәм белгечләре арасында Сезнең абруй бик зур.

Безнең академиягә төрле яклап ярдәм итүегез, эшләребезгә теләктәшлек күрсәтүегез өчен Сезгә аерым рәхмәтләремне җиткерәм.

Шушы истәлекле көндә Сезгә ныклы сәламәтлек, һөнәри эшчәнлегегездә уңышлар, күңел күтәренкелеге, иминлек һәм бәхет телибез!

Фото: kazanveterinary.ru, tatarica.org

ТУГАН ҖИР КӨЧЕ

Айрат Вәлиев,
Казан дәүләт аграр университет ректоры

Фото: kazgau.ru, msu.tatarstan.ru

Хөрмәтле Марат Готыфович!

Сезнең хезмәт юлыгыз авыл хуҗалыгы үсешенә фидакарьләрчә хезмәт итүгә, Россия Федерациясенең аграр фәненә һәм мәгърифәтенә, Татарстан Республикасының милли мәдәниятен һәм милли үзенчәлеген саклауга багышланган.

Казан дәүләт ветеринария институтын уңышлы тәмамлап, ветеринария табибыннан башлап Премьер-министр урынбасары – Татарстан Республикасының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрына кадәр якты һәм уңышлы юл узып, бүген Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәисе урынбасары һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президумы әгъзасы буларак, Сез Татарстанның үсешенә, иминлегенә, уңышларга ирешүенә үзегезнең гаҗәеп зур өлешегезне кертәсез.

Сезнең профессиональлегегез, хезмәт сөюегез, икътисадтагы, авыл хуҗалыгындагы, АСК кадрлар белән тәэмин ителешендәге, Татарстан авыл хуҗалыгы территорияләренең социаль-мәдәни үсешендәге зур бурычларга һәм проектларга яңача карашыгыз күпләр өчен үрнәк булып тора. Эшегезнең гимны булырдай сүзләрегезне яхшы хәтерлибез: «Җир минем өчен – язмыш... «Җир» дигән төшенчәгә «басу-кыр» мәгънәсен генә кертмим, аның мәгънәсе зуррак – җир үзе дә, анда эшләүче кешеләр дә керә бу сүзгә!»

Хөрмәтле Марат Готыфович! Сез озак еллар дәвамында Россия һәм Татарстан Республикасы өчен бөтен көчегезне, белемегезне һәм тәҗрибәгезне биреп эшлисез, күркәм эшләр максатына башкаларны да үз артыгыздан иярту сәләтенә ия. Сез татар мәдәнияте һәм теле язмышына карата зур кайгыртучанлык күрсәтәсез, бу бүген Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыкларның туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре буенча комиссия рәисе вазыйфасында башкарылган җитди эшләрегез белән дә раслана. «Үз илем», «Tatar сүзе», «Милли мультфест» һәм сезнең химаядә уздырылган башка иҗади бәйгеләр, татар теленең матурлыгын, байлыгын күрсәтеп, аның популярлашуына ярдәм итә.

Нинди генә урында эшләсәгез дә, безнең университетка, студентларга терәк булганыгыз өчен рәхмәт әйтәсем килә. Уй-ниятләребезне һәм тәкъдимнәребезне тормышка ашыруда, университетның матди-техник базасын ныгытуда, яңа лабораторияләр һәм уку бүлмәләре ачуда Сез күрсәткән ярдәмне бик югары бәялибез.

Хөрмәтле Марат Готыфович! 70 яшегез тулу уңаеннан, Казан дәүләт аграр университеты коллективының һәм шәхсән үземнең котлауларымны кабул итегез!

Тәҗрибәгез һәм максатчанлыгыгыз алга таба да уңыш гаранты булсын, якташларыгыз өчен түккән көчегез үзегезгә өчләтә әйләнеп кайтсын. Үзегезгә һәм якыннарыгызга нык сәламәтлек, тыныч, имин һәм бәрәкәтле тормыш телибез.

САБАН ТУЙЛАРЫ ГӨРЛИ

Июнь ае кәефен, әлбәттә, Сабан туйлары билгели. Ай башында авыл-район Сабан туйлары гөрләп үтте. Милли бәйрәмебезнең, республика чикләрен узып, татарлар күпләп яшәгән башка төбәкләрдә дә уздырылуы традициягә әйләнде.

Алар арасында иң колачлылары, әлбәттә, Федераль Сабантуй белән Бөтенроссия авыл Сабан туе. Соңгысы, сүз уңаеннан, быел 15 июнь көнне Пермь краеның тарихи яктан татар районы саналган Бардада узды. Исәп буенча 14 нчесе. Быел Барда районы үзенең 100 еллыгын да бәйрәм итә икән. Сабан туена Россиянең 50 ләп субъектыннан 70 меңгә якын кунак килде. Әлеге бәйрәм кысаларында биредә Бөтендөнья татар конгрессы тарафыннан төбәкчеләрнең «Тулба, Сылва-Ирен, Шаква һәм Мулла елгалары бассейны татарлары. Барда районы: тарих һәм хәзерге заман» дип аталган Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе дә оештырылды. Туган як тарихын өйрәнүчеләр җыелган бу фәнни чара Сабан туена кушылып китте. Традицион авыл бәйрәменә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәм Пермь крае губернаторы Дмитрий Махонин да килде. Сабан туе ачылышы алдыннан Рөстәм Миңнеханов татар халкының герой-шагыйре Муса Җәлилнең быел Бардада ачылган бюстына чәчәкләр салды. Губернатор белән бергә бәйрәм ярминкәсе, презентация мәйданчыклары белән танышты. Татарстан Рәисе кунакларны, Барда халкын милли бәйрәмебез белән котлады, ике төбәк арасындагы үзара файдалы элемтәләр турында сөйләде. Аннан соң Сабан туеның төп уеннары башланды. Кунакларга рәхәтләнеп ял итәргә, күңел ачарга, уеннарда катнашырга, ярышучылар өчен җан атарга эссе кояш нурлары да комачаулый алмады. Татар милли бәйгеләрендә җиңүчеләр кыйммәтле бүләкләрне, әлбәттә, ТР Рәисе кулыннан алдылар.

Басмабызның бу санында күңелле бәйрәм мизгелләре чагылыш тапкан фотосурәтләрне тәкъдим итәбез.

Фотолар «Татар-информ» МАнан алынды

Пермский край,
с. Барда

2024 ЕЛДА ИЛ КҮЛӘМЕНДӘ ҮТКӘРЕЛӘЧӘК ТӨП САБАНТУЙЛАР